КАЛӘМ ИЗГЕГӘ ТАРТЫР

Мәдәни Җомга

№ 12
6 октябрь
1995 ел

1995 елның июленнән
башлап чыга

Атналык әдәбият һәм сәнгать газетасы

БҮГЕНГЕ САНДА:

2 *Мәхмүт* ӘХМӘТҖА-*НОВ.* Мең еллар буена авызына хәмер алмаган татар кешесе, «коммунизм төзүдә актив катнашып», димәк, күршеләр арбасына утырып, динсез, денсезгә әйләнде, аракы чөмерүне көндәлек шөгыле итте.

5 *Фатих СИБАГАТУЛ-ЛИН.* Моңарчы миннән моң турында сораучы булмады.

13 *Гурий ТАВЛИН.* Акылы камил 78 яшьлек хуҗабикә бөтен калган гомерен щгә-нц торып үткәрерлек ир очратырга хыяллана.

14 *Мәгъсүм НАСЫЙ-БУЛЛИН.* Гаепле кешене, тыштан нинди батыр күренергә тырышмасын, һәрвакыт курку биләгән була.

18 *Марсель ӘХМӘТ-ҖАНОВ.* Тарихи чыганакларда сәйедләр татар ханлыкларында мөселманнарның иң өлкән дини җитәкчеләре итеп күрсәтелә.





Илыбызга салкын тичигэн көз,
ә безнең җыр-сөю хакында...

МӨХӘРРИР МӨНБӘРЕ

Дөньяда киек-җанварларга да һәйкәлләр куела... Ка-
зан дәүләте корбаннарының каны урамнар тулып
аккан, аяк асты бихисап мәетләр белән түшәлгән.
Нинди миһербансызлык: һәлак булган туганнарыбыз
истәлегенә әлегәчә ядкәрташ куя алмыйбыз. Икъ-
тисади яктан иң-иң көчлеләрдән саналучы җөм-
һүриятебезнең Кремль итәгендә һәйкәл торгызырлык
мөмкинлеге юкмы?! Оят, бик оят...

Мансуров

Зиннур МАНСУРОВ

МИН ӘЙТТЕМ

Мөхмүт ӘХМӘТҖАНОВ

ХЫЯЛЫЙЛАР ИЛЕ,

яки Коммунизм кыры нигә кысыр?

Кеше шәхесен мохит формалаштыра, диләр. Мәсәлән, мең еллар буена авызына хөмер алмаган татар кешесе, «коммунизм төзүгә актив катнашып», димәк, күршеләр арбасына утырып динсез, денсезгә әйләнде, аракы чөмерүне көндәлек шөгыле итте... Боларны әле аңларга була... Ләкин моңа кадәр галимнәр өзеп кенә җавап бирә алмаган бер өлкә бар. Бу — ми эшчәнлеге. Мәскәүдә бөтен дөньяга атаклы «Ми» («Мозг») фәнни-тикшеренү институты бар. Аның лабораторияләрендә бөек, атаклы кешеләрнең мие саклана. Галимнәр ул миләрне еллар буе өйрәнәләр. Ләкин теге яки бу шәхеснең уйлау «технологиясе»н ача алганнары юк. Бөек урыс физиологы И Павловның ми авырлыгы — 1100 грамм, бөек урыс язучысы И Тургеневныкы 4500 грамм булган. . (Минең уртача авырлыгы 2600-2800 грамм дип исәпләнә).

Тарихны кире сүтеп, яңадан төзеп булмый. Бөек кешеләрнең ни өчен башкача түгел, нәкъ шулай фикер йөртүен аңлаучы да юк. Бу җәһәттән утопист-социалистларның дөньяга карашларын искә төшереп булыр иде. Җыеп кына әйткәндә алар җиңел генә итеп дөньяда оҗмах корырга мөмкин дип уйлаганнар һәм шуңа ышанганнар да. Янәсе, «җир оҗмахы»нда кеше көненә 2-4 сәгать кенә эшләр дә, калган вакытын белемен үстерүгә, ял итүгә багышлар. Томас Мор (1478-1553) Англиянең иң зур җәмәгать эшлеклеләреннән берсе булган (король тарафыннан җәзалап үтерелгән). Ул үзенең уй-фикерләрен «Яңа утрау — Утопия хакында... алтын китап» әсәрендә бәян иткән. «Утопия утравындагы һәммә кеше бәхетле һәм сау-сәламәт. Эш көне 6 сәгатьтән артмый. Физик эш тансык. Аның белән физкультура урынына абруйлы кешеләр генә шөгыльләнә. Фән, белем алу чәчәк атачак». Кампанелла («кыңгырау» дигәнне аңлата) Томмазо (чын исеме Джованни Доминико, 1568-1639) үзенең «Кояш шәһәре» китабында түбәндәгеләрне яза: «Киләр бер көн, бөтен нәрсә дәүләтнеке булыр. Халык үз хуҗалыгын булдырмас. Кешегә бөтен нәрсәне дәүләт бирер. Халык бай, кайгысыз һәм озак яшәр». Франсуа Мари Шарль Фурье (1772-1837) тәгълиматы болай: «Кешене җәмгыять кенә боза, шуңа күрә әйбәт җәмгыять төзергә кирәк. Төп хезмәт формасы фаланга (оешма) булачак. Кеше бер көн эчендә эшен берничә мәртәбә алмаштыра, шуңа күрә хезмәттән ләззәт ала, тәм таба». Клод Анри Сен-Симон (1760-1825): «Дәүләтнең төп көче — эре промышленностьта, ә ул югарыдан төшерелгән план нигезендә эшли». Роберт Оуэн (1771-1858) — бай инглиз фабриканты. Аның төп идеясе: «Дәүләт кечкенә үзидарә башлангычларыннан (300-2000 кешедән) тора һәм шулардан федерация (дәүләт) төзелә. Идеясен тормышка ашыру теләге белән, Р Оуэн Америкага күчеп китә һәм анда «Яңа гармония» дигән хезмәт колониясе төзи. Эшчеләргә, аларның гаиләләренә, балаларына эшләү, яшәү, уку, ял өчен уңай шартлар тудыра. Әмма рәхмәт әйтү урынына, эшчеләр бөтен нәрсәне урлап качалар. Чөнки «Үзем тапкан мал түгел, өтинеке җәл түгел».

Укучыда утопистлар турындагы белешмәләр нигә китерелде икән, дигән сорау туарга мөмкин. Җавап шул: үзләрен социалистлар дип атаган утопистларның теләге-тәкъдиме чынбарлыктан ерак тора. Аларча тормыш көтеп булмый. Социализм дип аталган җәмгыятьтә эш стимулы («ачтан үлү куркынычы») бетә. Бу — кешенең тумыштан бирелгән психологиясенә бәйләнгән. Ләкин утопистлар мондый «вак-төяк»кә әһәмият бирмәгән. Алардан соң яшәгән француз метафизиклары дөньяны динчеләр генә боза, дин бетү белән кешеләр уңай якка үзгәрәчәк дигән. Күренекле философ һәм педагог Жан Жак Руссо (1712-1778) балаларны җәмгыятьтән аерып, урманда укытырга һәм тәрбияләргә өндәгән. Болар да — утопия...

Билгеле булганча, «фәнни коммунизм тәгълиматы»на Маркс, Энгельс нигез салган. Алар революция яклы түгелләр, дип, социал-утопистларны тәнкыйтьләгәннәр. Ләкин, үкенечле ки, аларның тәгълиматы да утопиядән ары китмәгән... СССР дип аталган урыс империясенең 70 елга сузылган «тәҗрибәсе» әнә шул хакта сөйли. Сүзне шуннан башлыйк: ни өчен «социалистик революция» башка илләрдә түгел (Маркс теориясе буенча, революция цивилизация нык алга киткән илдә җиңәргә тиеш), — нәкъ Русиядә җиңгән? Бу сорау урынлы һәм җавап та ап-ачык: «Работа дураков любит», «Работа — не волк, в лес не убежит», «По щучьему велению, по-моему хотению» кебек гыйбарә-әйтемнәрне тормыш принцибына әйләндергән халыкка, аз гына эшләп (4-6 сәгать), бай яшәү теләге (коммунистлар шуны вәгъдә итәләр ич), әлбәттә, бик ошаган һәм шуңа күрә ул большевиклар утопиясенә ышанган. Кайчак мин беркатлы гына итеп уйлап куям: комсомолның III съездында ясаган чыгышында Ленин, яшьләргә мөрәҗәгать итеп: «Сезнең буын коммунизмда яшәячәк», — дигән. Урыс әйтмешли, чистейшей воды утопия...

«Большевиклар ала алмаган крепость (кальга) юк» — дигән ялган принциптан чыгып, урыс коммунистлары шуны эшләделәр. Мәсәлән, капитализм формациясен үтмәгән Монголиядә, Урта Азиядә, аннан соң Әфганстанда, Сомали, Эфиопия һ.б. илләрдә социализм төзү уе белән яндылар. Моның өчен «үз халкының» җиде кат тиресен тунадылар. Дөньядагы барлык компартияләр дә диярлек Мәскәүдән күпләп акча алдылар. Алар бөтен Җир шарында «социалистик революция ясау» өчен «көрәштеләр».

Большевиклар — шул ук урыс шовинистлары. Шуңа күрә алар, бөтен дөньяда революция ясап, «бөек урыс дәүләте» төзергә хыялланмадылар микән? Болар буш сүз түгел. Мәсәлән, 50 нче еллар башында Болгария һәм Чехословакиянең җитәкчеләре СССРга союздаш республика булып керергә теләүләрен белдерделәр. Ләкин империя зур булган саен, аның таркалу ихтималы көчәя. Шовинистлар үзләренчә моңа да «рецепт» таптылар: ачыктан-ачык, «тимер куль» белән илдә бер халык калдыру сәясәтен үткәрделәр. Шуның аркасында СССРда 50 ел эчендә 194 милләтнең 93е юкка чыкты.

Утопист-социалистлар, тыныч юл белән «яңа җәмгыять төзеп», халыкны бәхетле итәргә хыяллана, ә урыс коммунистларының «бәхет юллары» гел канлы эзләрдән генә тора. Алар оештырган гражданнар сугышында кимендә 4-5 миллион кеше һәлак була. Сугыш тәмамланган елда илнең сәнәгать дәрәҗәсе, 1913 ел белән чагыштырганда, 3 процент кына тәшкил итә. Нәкъ шул шартларда 1921 ел ачлыгы тагын миллионнарның гомерен кисә. Әлеге хәлләрне булдырмый калырга да була, ләкин большевиклар ул хакта уйламыйлар (бу хакта чит илләрдә китаплар чыкты...)

Продразверстка, продналог, НЭП, ниһаять, колхозлашу, авылның иң тырыш кешеләрен, «кулак» мөһере сугып, илдән сөрү, урындагы хакимияткә люмпен-батракларның килүе — сугышка кадәр большевикларның «коммунизм төзүдәге» «уңышлары» әнә шул була. Авыл малае буларак (өстәвенә әткәй колхоз рәисе иде), шуны хәтерлим: сугышка кадәр дә, сугыштан соң да (бигрәк тә Сталин үлгәнче) авыл искиткеч хәерче яшәде. Өс киемнәре кибете һәрчак буш булды. Ашамлыклар кибетендә тоз, очсызлы сасы тәмәке һәм серкәдән башка нәрсә юк иде. Армиядән кайткан кызылармеец өс киемен (һәммәсен дә!) район хәрби комиссариатына тапшырды. Әнә шулай итеп «бөтендөнья империализмына каршы» сугышка хәзерләндек. Колхозчы үз авызыннан өзеп дәүләткә ит, сөт, йомырка, йон, тире (теләсә каян тап, әмма ике тире тапшыр!) тапшырды. Хезмәт көненә 300-400 грамм икмәк бүленә иде. Моны тәгаенләсәк, уртача 7-10 кешедән торган гаиләгә елына 6-7 пот ашлык бирелә иде. Бер сыер (ул да ач, арык), ике сарыктан башка мал тотарга ярамады. Әнә шул шартларда, 1936 елда, «бөек Сталинның җиңгән социализм конституциясе» «кабул

(Ахыры 8 нчы биттә).

Җидегән
вакыйгалар
хәбәрләр
яңалыклар
5 6 7 1 2 3 4

«Катыр киткән»нәрне хәтерли бу авыл

Карадуган авылында (Балтач районы) моннан дистә еллар элек җәлилчеләр музее оешкан иде Музей әйбәт кенә эшләп китте һәм яшь буынны, мәктәп балаларын тәрбияләүдә бүген дә байтак эшләр башкара. 12 октябрьдә Карадуган авылында тагын бер зур вакыйга билгеләп үтелә «Сәүдә юллары чатында» дип исемләнгән яңа музей ачыла Карадуган авылы борынгы сәүдә юллары чатына урнашкан. Бу юлны «Себер тракты» дип тә йөрткәннәр Авыл уртасындагы чәйханә китапханә революциягә кадәр үк күп еллар буе юлаучыларга хезмәт күрсәткән. Авылның хәтта төрмәсе («острог») дә булган Соңрак телефон да кертелеп, дистәгә якын телефон эшләгән Себер трактыннан «Себер киткән», «катыр киткән» кешеләр (ул бәхетсезләр арасында татарлар да булган) узып торган Шул заманнардан калган әйберләрне берничә ел бөртекләп җыеп (аларга дәүләт музее да ярдәмгә килгән), ниһаять, җәлилчеләр музее бинасының икенче катында яңа музей ачарга булганнар. Моңа авыл халкы да теләп ярдәм иткән.

12 октябрьдә Казаннан килгән кунаклар катнашында шушы музейны ачу һәм берочтан авыл мәктәбенең 70 еллыгын билгеләп үтү тантанасы булачак

«Ике гражданлык» хикмәтләре

Матбугат хәбәрләренә караганда, Татарстан Президенты киңәшчесе Тимур Акулов Казан-Шаржа-Кандагар һава юлында йөрүен дәвам иттерә. Сәфәренең берсендә ул, Исламабадка сугылып, Илбашыбыз Минтимер Шәймиевнең Кандагарда әсирлектә тотыла торган очкыч экипажының язмышына кагылышлы шәхси мөрәҗәгатен Беназир Бхуттоның үзенә ирештерде. Мондый үтенеч талибларга да тапшырылгач, шура әгъзалары эчке канәгатьлек белән гаҗәпләнгәннәр: Казан мөселманнары шундый җылы хат җибәрсеннәр әле... һәм алар дустанә Татарстан гражданнарын азат итү турында карарга килгәннәр. Әмма, хәерчегә җил каршы дигәндәй, янә бәйләнерлек сәбәп килеп чыккан: әлеге тоткыннар бер үк вакытта Русия гражданнары да бит. Ә Русия, күрәбез, аларны коткарырга бик үк ашкынып тормый.

Менә бит ул, шайтан алгыры, «ике гражданлык»ның хикмәтләре. Бу әле «баласы» гына. Алданиләр күрергә язгандыр?!

Сезне Сара Садыйкова хоры көтә!

Җыр сөюче дуслар! Җырларга яратучы егетләр, кызлар! Элекке елларда Казанның М.Горький исемендәге мәдәният йортында хорда җырлаган һәвәскәр ветеран җырчылар! Сара Садыйкованың мәдәни-хәйрия фонды һәм М.Горький исемендәге мәдәният йорты сезне 1950-70 елларда халкыбызның күренекле композиторы Сара Садыйкова җитәкләгән, соңгы елларда туктап калган, әмма ләкин быел яңадан эшли башлаган хорда җырларга чакыра.

Күпләр хәтерлидер, бу хор шәһәребездә гаять популяр, тамашачылар яраткан данлыклы хор иде. Яңадан эшли башлаган коллектив белән татар үзешчән сәнгатендә озак еллар эшләгән, тәҗрибәле хормейстер, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре Суфия Шаһиева җитәкчелек итәчәк һәм ул Сара Садыйкова исемен йөртәчәк.

Милләтебезнең җырга һәвәс яшьләре! Үзешчән җырчылар! Сезне Сара апабыз Садыйкова хорына көтәбез!

Репетицияләр атнага 2 тапкыр — дүшәмбе һәм чәршәмбе көннәрне үткәрелә һәм кичке сәгать 6да башлана.

Белешмәләр өчен телефоннар: 32-66-14 һәм 32-58-96.

Сөйләшсәк тә төрле телләрдә...

12 октябрьдә Чепья авылында (Балтач районы) халыклар дуслыгы музееның 30 еллык юбилее билгеләп үтеләчәк. Музей экспонатлары Идел буенда гомер-гомергә аралашып яшәгән татар, урыс, удмурт халыкларының тормыш-көнкүрешен, икътисади, мәдәни бәйләнешларын яктырта.

Татар-мөселман дөньясы

● Львовтагы «Туган ил» татар җәмгыяте оештырылуга 3 ел тулды. Аның хәзергә кадәр махсус бинасы булмаса да, башкарган игелекле эшләре җитәрлек. Җәмгыятьнең «Шәфкать» фонды шәһәрдәге өлкән яшьтәге ялгыз мөселманнарга хәленнән килгәнчә булышлык күрсәтә, татар һәм гарәп телләрен өйрәнү курслары оештыра Гарәп телен һәм Ислам нигезләрен мөселманнарга милләте буенча украинлы, әмма Ислам дине тотучы Я.Полотнюк өйрәтә. Хәзерге вакытта ул Коръәнне украин теленә тәрҗемә итә.

● Харьковның Трактор заводы районына урнашкан татар зиратында 150 кабернең туфрагын таптап, аларга куелган ташларны ватып киткәннәр. Украина мөселманнарының Бәйсез дини үзәге президиумы рәисе Рәшид Брагин һәм Харьков шәһәре мөселман җәмәгатьчелеге фикеренчә, бу — татарларга каршы махсус рәвештә эшләнгән провокация.

● Киев шәһәренең «Ләйсән» татар яшьләре ансамбле артистлары, Украинаның Төркиядәге илчесе А.Герман тырышлыгы белән, Төркиядә халыкара яшьләр лагерында ял иткәннәр. Яшь башкаручылар Төркиядә яшәүче татарлар һәм җирле халык өчен берничә концерт та куйганнар. Татар җырларыннан тыш, тамашачыларга яшьләрнең мөнәҗәт әйтүләре аеруча ошаган.

Төркиядә «Ләйсән» ансамбле җырчылары Премьер-министр урынбасары Шәүкәт Кунтай (чыгышы белән татар) һәм башка дәүләт, дин эшлеклеләре белән очрашканнар. Төркиядә яшәүче татарлар очрашу истәлеге итеп телевизор һәм видеомагнитофон бүләк иткәннәр.

● 70 меңнән артык татар яшәгән шахтерлар шәһәре Донецкида мәчет төзелә башлады. Аның беренче каты салынып бетү уңаеннан, анда җомга намазы укылды

● Төркиянең Украинадагы илчелеге булышлыгы белән Киевта урнашкан төрки халыклар китапханәсе бинасы төзекләндерелде һәм яңартылды Биредә яшәүче татарлар исә Төркиянең матди ярдәме белән яңа мәчет салырга ниятлиләр.

Татарстанның күптән түгел генә Украинада ачылган вәкиллеге дә нәкъ шундый игелекле эшләр башкарып, биредә яшәүче татарлар өчен терәк ролен үтәсен иде.

● Татарстан Республикасы дәүләт киносында «Таң батыр» дигән татар халык әкияте мотивларына нигезләнеп эшләнгән беренче милли мультфильмны монтажлау эшләре тәгәлләнеп килә

Сәнгатькәрләр ришвәт ала

«Эхо Москвы» радиостанциясе хәбәр иткәнчә, С.-Петербургның Мариинский театры директоры А.Мальков һәм баш балетмейстер О.Виноградов 10 мең доллар күләмендә ришвәт алган вакытта оешкан җинаятьчелеккә каршы көрәш идарәсе хезмәткәрләре тарафыннан тоткарлана.

Шөкер, безнең М.Җәлил исемендәге Татар дәүләт академия опера һәм балет театры җитәкчеләренә мондый куркыныч янамый. Беренчедән, соңгы елларда бу театрда безнең хәзерге композиторларыбызның яңа әсәрләре бөтенләй куелмый диярлек Икенчедән, куелган сурәттә дә, опера-балет авторлары театр башлыкларына 10 мең доллар (безнеңчә 50 млн сум чамасы) ришвәт бирә алмас иде, мөгаен.

Әлмәттә Алла Пугачеваны Алла урынына күрәләр

Дөнья шаулаткан эстрада йолдызы Алла Пугачева, ел ярым сәхнәгә аяк басмаячакмын, дигән нәзерен бозар, ахрысы Чөнки ул шушы ай азагында Әлмәт шәһәрендә бердәнбер концерт бирергә җыена Хикмәт шунда ки, җырчының кызы Кристинага Әлмәт һәм аның халкы ошап калган Ник алай Әлмәт шәһәре яшь ханымның күңеленә хуш килгән икән, дисәгез. Кристина Әлмәттә булган көннәрдә шәһәр байлары аны бик җылы кабул иткәннәр, аңа БМВ машинасының рулен ышанып тапшырганнар, хәтта машинаның бер ягын яньчүен дә елмаеп кына үткәреп җибәргәннәр.

Өстәвенә, Әлмәткә Бөгелмәдән кул сузымында гына, ә анда Алла ханым бер предприятиедән саллы гына дивиденд ала Шуңа күрә Алла Пугачева Әлмәт сәхнәсендә үз «театрын» күрсәтергә ашкынып тора Дивидендларга концерттан килгән табыш та иш янына куш... Чөнки ул концертны тамаша итәсе кешә 100 меңнән 500 меңгәчә билет хакы түләп кенә, концерт залына үтә алачак Урындагы «Луч» телекомпаниясе күптән түгел үткәргән сорашып белешү дә Пугачева-Пресняков-Киркоров кланының Әлмәт элитасы каршында абруе зур икәнен күрсәтте. Яңа байларның да үзләрен меломан итеп күрсәтәселәре бик килә шул.

Җомгадан — җомгага

Җөмһүрият елъязмасына язмалар

Мәскәүдә үткәрелгән киңәшмәдә Татарстан Премьер-министры Ф.Мөхәммәтшин Татарстанда урнашкан хәрби-промышленность комплексы предприятиеләренең финанс-икътисади хәле бик авыр булуы турында анализ белән чыгыш ясады. Русия хөкүмәте Рәисенең беренче урынбасары О.Сосковец федераль министрлыклар һәм ведомство җитәкчеләренә килешүләрне тиз арада тормышка ашыру буенча конкрет күрсәтмәләр бирде.

Башкортстан һәм Татарстан Республикаларының балалар һәм яшьләр Дәүләт комитетлары арасында яшьләр сәясәтен тормышка ашыру өлкәсендә хезмәттәшлек итү буенча килешүгә кул куелды

Муса Җәлилнең көрәштәше Абдулла Алишның туган авылы Каекта (Спас районы) мәдәният йорты һәм Абдулла Алишның музей бинасы төзелеп бетте. Аларны тантаналы рәвештә ачу өчен... тамаша залында урындыклар һәм музыка кораллары сатып алырга акча булмау гына тоткарлап тора.

Г.Ибраһимов исемендәге Тел әдәбият һәм тарих институтында танылган татар драматургы Таҗи Гыйззәтнең тууына 100 ел тулуга багышлап гыйльми конференция булды

Танылган драматург Туфан Миңнуллин рәислегендәге татар язучыларының ПЕН үзәген — Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы теркәде. Хәзер ПЕН үзәкне рәсми төстә Лондонда теркәргә генә калды. Чөнки ЮНЕСКО составына керүче Халыкара язучылар ассоциациясенең штаб-квартирасы Лондон шәһәрендә урнашкан.

Малайзия Федерациясе белән Татарстан Республикасы арасында икътисади фәнни һәм мәдәни элемтәләр урнаштыру өчен Малайзиянең Русиядәге илчесе Датук Яхъя Баба Татарстанга киләчәк Бу хакта Татарстан Республикасының Русия Федерациясендәге вәкаләтле вәкиле Ф.Мөхәммәтшин белән Малайзия илчелеге киңәшчесе Сәед Хөссәен киңәшләште

Төркиянең Чишмә шәһәрендә үткәрелгән төрки халыкларның III Корылтае үз эшен тәгәлләде. Анда барган Татарстан делегациясенә академик Индус Таһиров җитәкчелек итте.

Татарстанда бу елның сигез аенда яшүсмерләр арасында җинаять кимегән әмма 21 районда балигъ булмаганнар арасында җинаятьчелек арткан Бу мәсьәлә Премьер-министр урынбасары И.Хәйруллин рәислегендә республиканың балигъ булмаганнар эше буенча комиссиядә каралды

Түбән Камада Мәскәү гуманитар-икътисад институтының филиалы ачылды.

Кама Аланы эшчеләр бистәсендә җирле телевидение эшли башлады

Төркиянең Измир шәһәрендә төрки халыкларының дуслык һәм хезмәттәшлек фестивале тәмамланды. Анда Халыкара төрки яшьләре берләшмәсе башлыгы Тәлгать Әхмәдишин җитәкчелегендә Татарстан делегациясе дә катнашты.

Республика Дәүләт Советының парламент контроле комитеты Татарстан Әйләнә-тирә мохитне һәм табигый ресурсларны саклау министрлыгының һәм республика экология фондының акча средстволарын файдаланудагы җитешсезлекләрен тикшерде

Татарстан прокуратурасы карар итә

Шушы көннәрдә Татарстан Республикасы прокуроры С.Нәфиев рәислегендә ТР прокуратурасы коллегиясенең киңәйтелгән утырышы булды. Коллегия, Актаныш районы прокуратурасы эшчәнлегенә җентекле анализ ясаганнан соң, Ә.Батаевны янә Актаныш районы прокуроры итеп калдыру турында карар кабул кылды. Шунысын да әйтик, Ә.Батаев кеше ашаучы Суклетин турындагы китапның авторы да.

Утырышта шулай ук Казан шәһәренең Авиатөзүчеләр районы прокуроры А.Минһаҗевнең алдан уйланылган кеше үтерү белән бәйле җинаятьләрне тикшерү һәм ачуны оештыру эшчәнлеге тикшерелде. Коллегия, әлеге район прокурорының шушы юнәлештә алып барган эшчәнлегендә җитди кимчелекләр булуга ишарә ясап һәм аларны кичекмәстән төзәтү максатында, Татарстан Республикасы прокурорына махсус фәрман чыгару турында тәкъдим кертте.

Яхшылык эшләсәң, халык белер

8 октябрьдә борынгы тарихлы Олыяз авылында (Мамадыш) мәчет ачу тантанасы була. Шул ук вакытта 35 ел буе колхозны җитәкләгән һәм күркәм эшләре, игелеге белән халык күңеленә кереп калган Галимҗан Җиһаншинның вафатына бер ел тула икән. Шул уңайдан әлекке колхоз рәисенең якты исемен мәңгеләштерү ниятеннән, ул яшәгән йортка истәлекле такта кую тантанасы булачак һәм яңа мәчеткә дә Галимҗан исеме биреләчәк. «Яхшылык эшлә дә суга сал, халык белер. Халык белмәсә, балык белер», ди халык. Игелекле эшләр онытылмый ул.

■ **14 октябрьдә** Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында яңа сезон ачыла.

■ **12, 13, 14 октябрь** — Казан сәнгать училищесы өчен бәйрәм көннәре. Күпсанлы рәссамнар, дизайн осталары, сәнгать белгечләре тәрбияләп чыгарган училище үзенең 100 еллык юбилеен билгеләп үтә.

■ **28 октябрьдә** К.Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театрында республикабызда яшәүче фин-угор телле мари, мордва, удмурт халыклары вәкилләренең сәнгать фестивале үткәреләчәк.

Язучылар хисап тота

28 сентябрьдә Татарстан Язучылар берлеге идарәсенең чираттагы утырышы булып узды. Утырыш күптән түгел вафат булган язучылар Мөхәммәт Мәһдиев, Ибраһим Нуруллин, Фәнил Мансуров, Мисхәт Хәбибуллинның изге рухын хөрмәтләп искә алу мизгелләреннән башланды.

Идарә әгъзалары татар халкының мәдәни хәятендәге олы яңалык — «Мәдәни җомга» исемле атналык гәзит чыга башлавын зур канәгатьләнү белән билгеләп үттеләр.

Татарстан Язучылар берлеге идарәсе рәисенең ярдәмчесе итеп Рәмис Аймәт билгеләнде. Рәмис Чүпрәле төбәгенең Мунчәли авылында туган, Казан дәүләт университетын тәмамлаган журналист, аспирантураның икенче сыйныфында белемен күтәрә.

«Идел кызы» әсәре һәм соңгы елларда язылган публицистик язмалары өчен язучы Гариф Ахунов Гаяз Исхакый бүләгенә тәкъдим ителде. Утырыш Туфан Миңнуллин, Гариф Ахунов, Мәдинә Маликова кебек танылган язучыларның түгәрәк бәйрәмнәрен уздыру тәртибен раслады.

Һәм тагын күп кенә мөһим мәсьәләләрне караганнан соң, идарә Якуб Зәнкиев (Себердә яши), Мөҗәһит Әхмәтҗан (Мәскәү), Зәһид Мәхмүди (Казан), Роза Мулланурова (Казан), Ләлә Сабирова (Казан), Мөхәммәт Мирза (Актаныш) һәм Апаста яшәүче Мәрди Рәфиковны Язучылар берлегенә әгъза итеп алды.

Казандагы Е.Завойский исемендәге физика-техника институтының оешуына 50 ел тулды. Шул уңайдан 1991 елда булдырылган Е.Завойский исемендәге Халыкара бүләк АКШ профессоры Джеймс Хайдка тапшырылды.

● В.Лихачев (сулда) Джеймс Хайдка бүләк тапшыра.

М.КОЗЛОВСКИЙ фотосы.

Мәйсез чәй мәҗлесе

«Мәдәни җомга» чәйханәсендә өлкәннәрне хөрмәтләү мәҗлесе булып узды. Гәзитебезне чыгаруда зур хезмәт куйган һәм куючы мөхтәрәм өлкәннәребез Гурий Тавлин, Касыйм Тәхау, Саимә Ибраһимова, Салисә Гәрәева, Шәех Зәбир һ.б.ларга чәчәкләр вә истәлекле бүләкләр тапшырылды.

Бу кичәдә мәшһүрә җырчыбыз Вафирә Гыйззәт белән танылган музыкант Лариса Маслова да катнашты.

Кичәдә җырлар, такмаклар, Сәйдәш, Чайковский көйләре яңгырады.

Мәҗлестән таралганда кунакларның берсе, шаяртып:

— Карале, мәйсез дә күңел ачып була икән, — диде.

— «Җомга» исеме катнашкан гәзиткә мәй килешми! — диде икенчесе.

Кияү кала кардәшләребезгә ачык чырай күрсәтеп ала

Украина Министрлар Кабинеты «Кырым автономияле Республикасында сәяси-хокукый, иҗтимагый-икътисади мәсьәләләрне хәл итү чаралары турында» карар кабул итте. Анда мондый юллар да бар: «Кырым татар халкы Милли Мәҗлесе статусын законлы төстә билгеләү өчен эшче төркем төзергә. Эшче төркемгә Украина Президенты хакимияте, хөкүмәт, «Корылтай» фракциясе, бу эш белән кызыксынган министрлыклар һәм ведомстволар вәкилләрен кертергә». Шулай итеп, Кырым татар халкының Милли Мәҗлесе статусын билгеләүгә тагын бер адым ясалды. Соңгысы гына булмасын.

«Нур» өстенә нур

Санкт-Петербургта Русия күләмендә татарча чыга башлаган иң беренче гәзит – «Нур» гәзитенең тәүге санын нәшер ителүгә 90 ел тулу уңае белән гыйльми-гамәли конференция булып үтте.

Конференциядә Казаннан Бөтендөнья татар конгрессының башкарма комитеты рәисенең беренче урынбасары, «Ватан» җәмгыяте президенты Римзил Вәлиев, «Чаян» журналының баш мөхәррире Рәшит Зәкиев катнашты.

Конференция Санкт-Петербургның «Нур» татар мәдәният үзәге тырышлыгы белән оештырылды.

Кырым татарлары яңа фиркагә берләшә

Симферопольдә Кырым татарларының «Адаләт» дип аталган яңа милли фиркасенең оештыру корылтае булып узды. «Безнең теләкләребез Милли Мәҗлес теләкләреннән һич кенә дә аерылмый, әмма максатларыбызны тормышка ашыру өчен без тагын да катгыйрак чаралар кулланачакбыз», — дип белдерде фирканең рәисе Сәрвәр Кәримов.

«Адаләт» фиркасенең төп бурычлары — Кырым татарларының үзбилгеләнү хокуклары сакланган хәлдә милли дәүләтчелеген торгызуга, Кырым дәүләт органнарында, Кырым татарларының 40 процент тәшкил ителүенә, туган җирләреннән куылган вакытта югалткан мал-мөлкәтләре өчен тулысынча компенсация алуга ирешүдән гыйбарәт.

Аллаһы Тәгалә рәхмәтен салып, шуларга ирешергә язсын! Амин!

Урысның мәңге картаймас шагыйре

«...Кешеләрне ярат һәм кызган, җинаятьчеләрне дә, алдакчыларны да, җәфа чигүчеләрне дә, хыянәтсез яшәүче тәкъваларны да. Син шуларның һәркайсы хәлендә булырга мөмкинсең — изүче-залимнәрне дә ярат һәм хурлык баганасына тәрәмә, ә наз-союы белән кешеләрнең тереклек чирләрен ачып сал. Барлык кешеләр дә уртак җан-рухка тоташкан...»

Мәшһүр урыс шагыйре Сергей Есенин үзенең бер хатында әнә шулай искәрткән. Әүлиячә әйтелгән хак сүзләр. Безгә калса, изүче-залимнәрне яратырга чакыру гына аңлашылып бетми. Хәер, анысы шагыйрь инануында калсын. Ә бүгенге моңсу һәм үзенчә ямьле көзге көннәрнең берсендә — 3 октябрьдә Сергей Есенинның тууына 100 ел тулды.

СЕРГЕЙ ЕСЕНИН

* * *

Үкенмим дә, дәшмим, еламыйм да,
Томаннарда йөзәр ак алмам.
Гомер көзен алтын-сары сарыгач,
Сула баргач, мин яшь булалмам.

Элеккечә дәртле тибә алмас
Тәүге кыраудан соң йөрәгем.
Ялантәпи йөр, дип чакыралмас
Ак каеплы якты төбәгем.

И зимагур рухым, нигә сирәк
Ялкынлана сүзләр фәрманың.
Кая югалды соң саф яшьлегем,
Даулы караш — хисләр дәрманы.

Теләкләр дә саран. Төшкә кердә —
Язмышыммы, синме бер тапда?!
Әйтерсең лә язгы яз иртәсе,
Чабып уздым алтын толпарда.

Барыбыз да бу дөньяда фани,
Фатихалы булсын килгәннәр;
Бакыр яфрак койган чаган кебек,
Орлык сипкән, җиргә иңгәннәр.

Разим ВӘЛИУЛЛИН тәрҗемәсе.

Казан фаҗигасе һәм аның сабаклары

Бүген Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитеты, Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты, Бөтентатар «Мәгариф» берләшмәсе «Казан» милли мәдәният үзәгендә 14 сәгатьтә «Хәтер көне»нә багышлап «Казан фаҗигасе һәм аның сабаклары» дигән фәнни бәхәс үткәрә.

Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры, вице-премьер Фатих СИБАГАТУЛЛИННЫҢ тынгысызлыгы ит, сөт, җир, авыл белән генә бәйләнмәгән, аны Җәлил шигырьләре дә, Туфан Миңнуллинның Әлмәндәре дә уйландыра. Бу һәм башка мәсьәләләр хакында ул гәзит укучыларыбыз белән тәүге тапкыр ачыктан-ачык уртаклашырга булды.

Фатих СИБАГАТУЛЛИН:

Моңарчы миннән моң турында сораучы булмады

— Сезне, Фатих әфәнде, авыл хуҗалыгы белән бәйле мәсьәләләрне оста хәл итүче, әлеге тармактагы авыр йөкне карусыз тартып баручы киң күкрәкле, тимер бәдәнле ир, булдыклы җитәкче, министр вазифасын башкарып кабинет кысаларында яшәүче зат буларак та күз алдына китерергә мөмкин. Һәрхәлдә, гәзит-журналларда, радио-телевидениедә бирелгән интервью, язмаларда Сезнең тормыш берьяклы гына яктыртыла кебек. Укучы буларак, әйтик, мине, әдәбиятка, сәнгатькә, авыл кешесенең бүгенге халәтенә булган мөнәсәбәтегез дә кызыксындыра. Сезне җырга, моңга гашыйк кеше дип белүчеләр дә бар. Әгәр шулай икән, моннысы да безгә сер булып кала...

— Һич тә сер түгел! Моңарчы миннән бу турыда сораучы булмады, хикмәт шунда гына. Җыр-моңга, гомумән, әдәбиятка, сәнгатькә чыннан да гашыйкмын. Халкыбызның популяр җырларын беләм, байтак җырларның авторлары белән якыннан танышмын. Кызганыч, үземне матур җырлаучы дип әйтә алмыйм. Мәгълүм ки, район хакимияте башлыклары арасында үзәкләрне өздереп гармунда, баянда уйнаучылар, җырлаучылар бар. Авыл галантларга бай. Аннан никадәр җырчы, шагыйрь, язучы, рәссам, галим чыккан. Аларның һәркайсы игътибарга һәм ихтирамга лаек.

— Белгечлегегез һәм биләгән урыныгыз белән Сез әдәбият, сәнгать әһелләреннән читтә торырга тиеш кеше кебек. Һәрхәлдә, алар белән аралашырга вакытыгыз калмыйдыр?..

— Кешене кем булып эшләве билгеләми. Аның күңеле ничек яралган бит әле. Мин үзем даһи Тукай ягыннан, авылдан Язучы булмасам да, бик күп язучыларны, шагыйрьләрне якыннан беләм. Әдәбиятыбыз аксакалы Гомәр ага Бәширов, халык язучыларыбыз Гариф Ахунов, Аяз Гыйләҗев белән аралашып яшәвемә шатланам, мәрхүм әдибебез Мөхәммәт Мәһдиев белән якыннан аралашып, аны күреп калуым белән дә бәхетлемен. «Кто есть кто» китабында кемнәрнең иҗатына өстенлек бирүемә игътибар итүчеләр булгандыр. Дөрес, ул исемлек үзгәрергә, тулыланырга мөмкин. Һич тә яшермичә әйтә торган исемнәр бар. Ренат Харис, Равил Фәйзуллин, Роберт Миңнуллин, Разил Вәлиев, Рабит Батулла иҗаты күңелемә якын. Ринат Мөхәммәдиев кебек Төркия җөмһүриятендә татар исемен яңартып торучы язучыбыз булуына да сөенәм. Заманында тыелып килгән Гаяз Исхакый кебек язучының халкыбыз күңеленә кире кайтуы шатландыра. Язучы белән, аның әсәрендәге каһарманнар белән күпмедер вакыт бер мохиттә яшәү тормышны тирәнрәк аңларга, безгә Ходай тарафыннан җибәрелгән гомерне дөрес бәһаләргә ярдәм итә, дип уйлыйм.

— Бу очракта Сез кайсы язучыбызны аерып әйтер идегез?

— Татарның әдәби мирасы искиткеч бай. Һәм ул һаман тулылана бара. Туфан Миңнуллинның «Әлдермештән Әлмәндәр», «Авыл эте Акбай» спектакльләрен карагач, моңа кабат инанасың. Әлмәндәр белән беренче тапкыр очрашуда ук ул үзенә җәлеп итте, спектакль тәмамлангач та аңардан аерылуы кыен булды. Бу образ ни өчен тамашачы күңелен үзенә әсир итә соң?

— Үлемгә каршы тора алучанлыгы беләндер...

— Чыннан да, Әлмәндәрнең башыннан ниләр генә узмаган. Ул һаман исән, әле дә булса шат күңелле, бу дөньялыктан һич тә китәргә уйламый. Әлмәндәр образы гадәти дә түгел, шул ук вакытта тормышчан да. Минемчә, вакытлар узу белән бу әсәрнең әһәмияте, бәясе тагын да артачак. Үземә килгәндә, Әлмәндәр белән ничә тапкыр очраштым, әмма спектакльне караган саен карыйсы килә.

Тамашачыны «Авыл эте Акбай» да битараф калдыра алмый. Балаларның да, өлкәннәрнең дә бу спектакльне җылы кабул итүен сизмисең. Этләр тормышы, этләр образы аша авторның тамашачыга, халыкка нәрсә әйтергә теләгәнен яхшы чамаларга була. Образларны ачып бирүдә артистлар да бөтен осталыкларын, талантларын эшкә җигәләр.

— Игътибар итәсездер, язучы, шагыйрьнең һәркайсы үзе бер дөнья, бер-берләрен кабатламаган шәхес...

— Әйе, ни өчен безнең халык, шул исәптән мин дә, безнең бөек Тукай, Сәйдәш. Илһамыбыз бар, ди Чөнки алар — кабатланмас, халкыбызның рухи дөньясында тирән эз калдырган шәхесләр Иҗатлары да, эчке дөньялары да үзенчәлекле, кызыклы.

Алда әйтелгән мөхтәрәм язучыбыз Туфан Миңнуллинны да гадәти кеше димәс идем Ул авылдан чыккан, Союз күләмендә депутат булган, республикабыз Язучылар берлеген җитәкләгән, инде кабат, халык депутаты буларак, изге эшләр хакында борчылып, көенеп йөрүче кеше Нинди уйлар яшәтә аны, нәрсә өчен борчылып гомер итә ул?! Туфан Миңнуллинның әсәрләре белән танышкач, аның үзе белән булган очрашулардан соң, бу сорауга күпмедер дәрәҗәдә җавап табасың. Туфан үзе генә дә олы әсәрнең олы образы була алыр иде!

Менә миңа эшкә барган саен Кремль янәшәсендәге Муса Җәлил һәйкәле яныннан узып китәргә туры килә. Күңелдә мәктәп елларында ук ятланып, үз урынын тапкан шигырь яңара:

«Кайгырма дус, яшьли үләбез дип,
Без алмадык сатып гомерне.
Үзебезчә яшәп, үзебезчә
*Без чиклибез аны түгелме?»**

«Кем сокланмас көчкә, тимер сынса,
Һәм су чыкса баскан эзеннән.
Тик ни файда, көчең филдәй булып,
*Эшең булса чыпчык тезеннән»..***

Нинди тирән мәгънә! Әлеге шигъри юлларны кабатлаган саен уйлап куям: бу дөньяга ни өчен яралганмын, ни өчен яшим, ничек гомер итәм?!

— Яшәлгән гомер, башкарган эшегезгә ишарә ясадыгыз кебек... Башкалар ял иткәндә дә бүгенгедәй, Сез эш урыныгызда. Җитди киңәшмә, очрашулардан соң мин дә Сезне ялыктырып утырам.

— Киресенчә, әдәбият, сәнгать турында сөйләшеп утырып ял итәм, хәтта әңгәмәне өзәсе килми. Яшермим, алда әйтелгәнчә, гомерем буе уйлап эш иттем. Моңарчы матур гына яшәлде. Башкарган эшләрем — хезмәттәшләрем, авыл кешеләренең күз алдында. Бәяне алар бирер.

— 25 яшьтән колхоз рәисе булуыгыз да, район җитәкчесе, министр вазифасын башкарып нинди нәтиҗәләргә ирешүегез дә күпләргә билгеле. Ләкин ачыкланмаган бер әйбер кала.

— Нәрсә икән ул?..

— Киләчәктә Сезнең турыда берәр документаль әсәр иҗат итәргә алынучы язучы, министр Фатих Сәүбән улы Сибагатуллинның хезмәте ничек билгеләп үтелгән икән, дип кызыксынып, Сезгә «Атказанган авыл хуҗалыгы хезмәткәре» исеме дә бирелмәгәнлеген белеп тукталып калса?!.

— Минемчә, образны тудыру өчен мондый детальләрнең кирәге шуның кадәр генә. Кешенең кемлеген исеме, титулы түгел, эше билгели. Җәлил шигырендә мондый юллар да бар:

«Мин күп күрдем филдәй кешеләрне,
Киң күкрәкле, тимер бәдәнле.
Тик күрәсе иде эше белән
Кеше булган иң чын адәмне»

— Сезнең дә буй-сыныгыз көрәшчеләрнекеннән ким түгел. Хәтта көрәш мәйданына яшьләрне тартып чыгарырга да көч таба аласыз.

— Нинди авыл малае мәйданга чыгып бил алышырга теләми икән?! Миндә дә андый теләк булды, өкренләп аны тормышка ашыра

(Ахыры 6 нче биттә).

* «Дуска» шигыре.
** «Бер үгет» шигыре.

Моңарчы миннән моң турында сораучы булмады

(Ахыры. Башы 5 нче биттә).

бардым Тагын бер теләгем спортның милли төрләре буенча ярышлар уздыру. аңа күбрәк яшьләрне тарту иде Мәгълүм булганча. спортның милли төрләренә көрәштән тыш. ат чабышы. гер күтәрү (элек аны чуен. таш күтәрү дигәннәр). бау. таяк тартышу. кул көрәштерүдә керә Бу ярышны без берничә еллар элек ат спорты белән башлап җибәргән идек һәм ул зур үсеш алды Спортның милли төрләре буенча республика федерациясе рәисе буларак. мин әлеге ярышларның әһәмияте зур дип саныйм Берәүләр анда катнашып көчен сынаса, осталыгын чарласа, икенчеләр исә мондый спорт бәйрәмнәрендә рәхәтләнеп ял итеп китә. Матур гадәт буенча. көрәшчеләр янында җырчысы, баянчысы. биючесе дә була һәм спорт белән шөгыльләнүчеләрнең тагын бер өстен ягы бар шагыйрь әйтмешли. андыйлар «киң күкрәкле. тимер бәдәнле» булып үсәләр Яман гадәтләр. аракы эчү. тәмәке тарту башкаларны кыерсыту да чын спортчылар өчен ят күренеш. Андый ата булган гаиләдә балалар да таза. сәламәт акыллы булып тәрбияләнә һәрхәлдә. яшьләребезне. ир-атларны шундый итеп күрергә теләр идем.

— Үзегез спортның кайсы төрен өстенрәк саныйсыз?

— Ат спортын. Атта йөрергә бик яратам.

— Мал врачы булып китүегезне дә шуның белән аңлатмыйсыздыр бит?

— Хайваннарны яратмый. аларның җанын аңламый торып. врач булып эшләүчене күз алдына китерүе дә кыен Хайваннар җәнлекләр кешене аңлый. ләкин сөйләшә генә алмыйлар. Хайваннар. җәнлекләр дөньясы миңа бик тә якын. бик тә кадерле. Этне. мәчене генә алып карагыз? Ничек инде аларга карата явызлык кыласың?!

— Фатих әфәнде, әңгәмә башында Сез. авыл талантларга бай, дигән идегез. Аның өчен җирлекнең дә уңдырышлы булуы кирәк бит әле.

— Авыл элек-электән уңдырышлы булды. Алда телгә алынган язучыларыбыз каладан чыкмаган бит. Челтерәп аккан чишмәләре. чәчәкле болыннары. куе урманнары булган. үзләренә хас гореф-гадәтләре белән яшәгән авыл хозурында тәрбияләнгән алар һәр төбәкнең үз таланты бар Бер төбәк үзенең язучысы, икенчесе — җырчысы. үзешчәннәре белән, өченчесе — шагыйрьләре белән горурланганда, Татарстан бөтенесен бербөтен алмадай, матур чәчәк бәйләме кебек кабул итә.

— Чәчәк сулмасын, алма бөрешмәсен дисәк, аларны яшәртү чыганагы табарга кирәк. Урыннарда мәдәният учаклары сүнеп бара түгелме?

— Өлкәннәр «без яшь чакта » дип әйтергә яраталар Клубы да булмаган. әмма алар вакытны күңелле итеп уздыра белгәннәр Кичләрен су буенда, болында җырлы-биюле уеннар уйнаганнар Ә хәзер авыл саен заманча мәдәният йортлары тергезелде. ул үзенә яшьләрне дә тарта башлаган иде кебек Кино, концертлар. төрле тамашалар күрсәтелде, авыл үзешчәннәре бер-берләренә йөрешә иде Бу матур гадәт, чыннан да, соңгы вакытларда онытыла бара шикелле. Кешеләр үз гаиләләренә, үз эчләренә кереп бикләнә сыман. Аларны телевизор, видеофильмнар ныграк тарта. ахрысы Әмма халык бөтенләй үк мәдәният учакларыннан читләшә димәс идем Концерт тамашалар буласы хакында ишетүгә, алар мәдәният йортларына ашыга Димәк. хикмәт — оештыручыларда Ә оештыру дигәнең матди чыгымнарга бәйләнгән. Миңа калса, иң уйландыра торганы шул Ләкин. мин ышанам, кыенлыклар артта калыр. талантлы яшьләребез үз юлын табар. алар без сокланган чәчәкләргә сулырга, алмаларга бөрешергә юл куймас.

— Талантлы яшьләрне күрә белергә, хезмәтләрен бәяләргә дә кирәк бит әле. Аерым җырчыларга кыйммәтле истәлек бүләкләре, хәтта машиналар. мактаулы исемнәр бирелү шуның башлангычы сыман. Әмма бөтен тамашачылар да. башкаручылар да моның белән килешеп бетми. Сезнеңчә ничек?

— Мин үзем артистларга да көрәшчеләргә дә дәүләт. оешма хисабыннан зур бүләкләр, шул исәптән машиналар бирдерү ягында түгел. Ә. гомумән. андый бай химаячеләр табыла икән хуплыйм Сабан туенда «Салмачы» агрофирмасы җырчы Зәйнәп Фәрхетдиновага җиңел машина бүләк иткән иде Башка андый очрак булмады

Базар шартларында язучыларыбызның. сәнгать әһелләребезнең матди хәлен яхшы аңлыйм Аларга да бик кыенга туры килә Китап бастырып чыгару. йә булмаса, җырчыга чит республикага гастрольләргә. җыр конкурсларына барып кайту никадәр чыгымнар сорый. Ә ул соңыннан үзен аклыймы әле?! Элек китабы өчен кем әйтмешли уч тутырып гонорар алган дәүләт бүләгенә паек табылган язучыдан да бәхетле кеше булмагандыр. мөгаен...

— Әдәбият, сәнгать ул безнең халкыбызга кирәк, ул безнең өчен рухи азык дип зурдан кубып сөйләшәбез. Соңгы елларда Сезгә чит илләрдә еш булырга туры килә. Эшлекле сәяхәтегезнең максаты авыл хуҗалыгы белән бәйле булса да. башка халыкларның яшәү рәвеше, мәдәни тормышы белән дә кызыксынмый калмагансыздыр?

— Алардагы фермерлар безнеңчә. авыл хезмәтчәне бит инде, үзләре әйтүенчә, концерт-тамашаларга музейларга сирәк йөри Аңлашыла булса кирәк. анда бездәге кадәр кинотеатрлар юк Тагын бер нәрсә игътибарны җәлеп итә бездә баланы һәр яктан белемле итеп тәрбияләргә омтылыш бар Шуның өчен дә урта белем бирү каралган Ә анда тар белем бирелә Әйтик. фермер булачак бала биш ел укый. программасы да үзенчәлекле. Тарихны безнең кебек өйрәнү юк, фермерлык тарихын гына укыйлар.

Әлбәттә, чит ил халыкларының яшәү рәвешен аңлау, аны кабул итү өчен шул җирдә туып-үсәргә, шундый шартларда тәрбияләнергә кирәктер. мөгаен

— Тормыш бер урында тормый, җәмгыятебез, авылларыбыз, мәктәпләр дә үзгәреш чоры кичерә. Аның ахыры ничек тәмамланыр? Бу чор әдәби, йә булмаса, тарихи-документаль әсәрләрдә чагылыш табармы икән?..

— Киләчәк хакында өздереп кенә әйтергә кем алыныр — анысын әйтүе кыен. Без бит хәзер җирнең яңа хуҗасын булдыру хакында сүз алып барабыз, шуны тормышка ашырырга омтылабыз Әйтик, бүгенге чорны чагылдырырга алынган язучы демократик процессларны нинди чаралар ярдәмендә тасвирлар икән? Андый әсәрнең әһәмияте. әлбәттә, объектив язылган очракта. еллар узган саен арта гына барачак Татар-болгар бабаларыбызның тарихы һәркайсыбызны кызыксындырган кебек

— Болгар-татар тарихын күпләребез белеп бетерми шул әле. Инде ата-бабаларыбыз нигезе дә югала, туган, кардәшлек җепләре дә өзелә бара. Заман җилләре татар кешесен кай тарафларга гына илтеп ташламады да ничек кенә сынамады. Язучы, шагыйрьләребез әсәрләрендә дә милләттәшләребезнең сагышы, моңы, туган җирләрен сагынуы сизелә...

— Ата-баба нигезен. туган җирен ташлап китүчеләр байтак шул Әмма чит-ятлар арасында үз ояңны кору җиңелдер дип әйтә алмыйм. «Матур булса да торган җир. сагындыра туган ил», — дип юкка гына әйтмиләр бит Ярый әле халкыбыз үзенең ул-кызларын онытмый Бәхет эзләп читтә йөрүчеләргә, туган авылларында, республикабызның һәр төбәгендә капка ачык. Кайтсыннар гына. үзләре булмаса балалары, балаларының балалары кайтып төпләнсен! Андыйларга җыр аша дәшәсе килә.

Юксынам дисең син. нигә соң?
Гомерең узмаган бит әле.
Туган як туфрагын сагынып,
Әйләнеп авылга кайт әле.

Саф чишмә сулары, һавасы,
Тугае болыны. урманы
Кочаклап алырлар үзеңне —
Әйләнеп авылга кайт әле.

Күзләрең ямансу, боеклар.
Алар да авылны сагына
Кайгырма моңайма юксынма.
Әйләнеп кайт кына авылга.

Юксынам дисең син. нигә соң?
Гомерең узмаган бит әле.
Туган як туфрагын сагынып,
Әйләнеп авылга кайт әле.

— Әйе. Бу җырны Марсель Гыймазетдинов шигыренә Илгиз Закиров иҗат иткән. Һәм ул «Әйләнеп кайт әле авылга» дип атала. Халык аны бик җылы кабул иткән иде.

— Әлеге җырның һәр сүзе күңелнең иң нечкә кылларына килеп кагыла Кызганыч, авторы Марсель генә безнең арабызда юк, вакытыннан алда гүр иясе булды. Шәхсән минем хәтердә ул авыл. аның киләчәге өчен янып, борчылып эшләүче күмәк хуҗалык җитәкчесе буларак та кереп калды. Туган нигез, изге туфрак аның өчен аеруча кадерле иде. Халык телендә Марсель Гыймазетдинов шигыренә иҗат ителгән башка җырларны да ишетергә туры килә. Шуннан соң ничек инде, халкым талантлы. моңлы, нурлы кешеләргә, шәхесләргә бай, дип әйтмисең!

— Фатих әфәнде, әйдәгез, әңгәмәне шушы рухта һәм алда китерелгән җырның потасы белән тәмамлыйк. Һәм, әлбәттә, моңдый очрашулар киләчәктә дә булыр дигән өметтә калабыз. Эшләрегез имин булсын!

Әңгәмәне **Альберт САБИРОВ** үткәрде.





* * *

Кояш чыгар,
Сулар сулкылдашыр,
Еракларга сузылып җил исәр...
Искән җилдә, исән җыялмыйча,
Иләсләнеп йөрер бу исәр:
Тауга менәр,
Үзәннәргә төшәр,
Урманнарга кереп югалыр...
Юкка гына,
Юкка гына йөрер, —
Әйталмаслар икән шуңа бер!

Иләс-миләс килеш китеп барыр,
Өсләренә кыргый гөл үсәр...
Акыллылар арта барган саен,
Шул исәрне эзләп җил исәр...

1995.

* * *

Тартылган кыл сыман зыңлап тора
Шыр ялангач калган бу киңлекләр.
Ямансудыр... Бәйрәм түгел инде
Җир йөзенә килгән ятимлекләр.

Кими бара дөнья:
Арабыздан
Җелек кебек замандашлар китә.
Кителә чор...
Бөтенлектән безне
Нигә болай иртә мәхрүм итә?!

Сагыш арта. Чаларадыр чәчләр.
Олыгая адәм балалары.
Киткәннәре — җилдер,
Шул җилләрдә
Саргаялар икән калганнары.

Бер-бер артлы замандашлар китә,
Өлгералмыйсыңдыр кул болгарга.
Карап торасыңдыр
Күз алдында
Бетә барган фани дөньяларга...

1995.

Сабый чактан бер күренеш

... Усак яфраклары лепердәшә.
Кичке кояш нуры. Кемдер дәшә...
Онтылган да булыр иде инде,
Сабый хәтер шулай сеңдермәсә.

Иң беренче истә калган мизгел...
Күптән төтен инде усаклары,
Әллә кайчан таралгандыр җилдә...
Һай бу гомерләрнең шул чаклары!

Усак яфраклары лепердәшә —
Ишетелә төтен арасыннан.
Сабыр гына карап ята дөнья
Без янганны,
Сабый бала сыман.

Кичке кояш нуры...
Иртәнгесен,
Карап тормый-нитми, илгә чәчтек.
Илгә түгел бугай, җилгә китте, —
Әллә исәрлек булды, әллә яшьлек.

Кемдер дәшә...
Газиз башкайларның
Кайда яшәгәнен белә бит ул!
Эндәш аңа,
Кыл өстендә чакта
Яннарына тизрәк кайтып котыл.

Иң беренче истә калган мизгел.
Яндыралмадылар бу рәсемне!
... Бишегемдә чактук күрсәткәннәр
Гомер буйларына күрәсемне...

1995.

И эзләрсез әле...

«Кара урман»ны тирән моң белән башкаручы хезмәттәшем Харис Әшрәфҗановны тыңлаганда туган уй.

«Кара да гына урман, караңгы төн...»
Кем баласы урман эчләрендә?
Төнгә каршы кая бара болай?
Ни гомерләр җырга күчкәнендә!

Урман эчләрендә кем ярасы? —
Кагылмагыз берүк, сорамагыз.
Ил кадерле ил имгәнгән чакта
Бер ялгызы сызлар бу балагыз...

Җан ачысы белән кычкырасы —
Урман эчләрендә урман икән.
Карурманнар булып,
Башкайларны
Заманалар көтеп торган икән!

Агачлардан-агачларга сугыл,
Тып-тын калып тыңлар алар сине.
Булыр микән илләрнең дә шулай
Үз баласын бирәр аңлар көне?

Төнгә каршы кая бара болай,
Китәбезме бергә, калабызмы?
... И эзләрсез әле
Урманнарда
Адаштырып киткән балагызны...

1995.

Кайсыгыз?

... Көккүк, чыпчык,
Тәрәзәдән очып чык...
Бала уйнату.

Тәрәзәдән очып чыкмады ул.
Белалмадым каян килгәнен:
Пыялага бәрелде дә чыпчык,
Егылып төште...
Тагын кемнәрнең
Хәбәрләрен алып килүедер...
Илдә чыпчык үлми иде дә,
Нинди гөнаһ шомлыклары икән,
Ни булды соң әле иленә?!

Харрас ӘЮП

Илдә чыпчык үлми иде дә бит
Кырылса да асыл ир-аты.
Башкайларын юкка ташка ормас —
Шул кошларда мәллә чираты?!
Пыяланы ваталмады мескен...
Чыпчык кына бит ул димәгез,
Кемнәр өчен шушы чыпчыклардан
Кадерлерәк әле илдә без?

— Көккүк, чыпчык, — диеп, кулларында
Сикертерләр инде ул кемне дә.
Каян белсен сабый болай да бер
Калачагын чыпчык көненә!

Тәрәзәдән очып чыгасы юк,
Алданмагыз, кирә кайтыгыз!
... Танымыйча калдым:
Пыяланы
Ваталмады бүген кайсыгыз?!.

1995.

Арыш басуында

Кыштыр-кыштыр арыш башаклары...
Күзгә яшьләр килә кайчакларны.
Басуларга чыксаң ялгызың.
Уракларны тынган өнкәйләрнең...
Шул малайга бер сүз әйталмадым
Сослан төпләрендә калдырдым.

Арыш арасында — зәңгәр чәчәк.
Дәшәлмичә тора җилдә чәчәп,
Төсмерләдем шундук, таныдым:
Юк, кермәгән иде искә бер дә
Басу уртасында чәчкәләргә
Әйләнәсе сабый чагымның.

Арыш башаклары пышылдаша...
Искән җилгә алар кушылмаса,
Бу чәчкәнә кемнәр юатыр?
Башлар чайкап, хәлләренә кереп,
Синең өчен саргаядыр кебек:
Басуларга чыксаң, уй артыр...

1995.

* * *

Мактаналмыйм:
Кар өстендә
Мин гөлләр үстермәдем.
Эреттем бары бәгырьдә
Кайгысын кешеләрнең.

Гөл булып тамалмадылар..
Күздән гөл тамамыни?
Безгә килгән тәкъдирләргә
Карлар түзәламыни?!

Андый кар табалмадым мин
Карлар тулы дөньядан.
Ә гөлләре...
Ә гөлләре җаныгызда
Шытар әле берзаман...

1995.

* * *

Замананың шакшысына
Батасең дә буялып,
Яшисең гомер буена
Үз-үзеңнән оялып.

Чыгарга кыенсынасың
Кешеләр каршысына:
Тәртеп күрсәтер шикелле
Аларның барсы сиңа.

Кайберәүләргә килешкән
Битлек бирәләр — алмыйм:
Битлек инде — читлек бит ул,
Ничек читлектә калыйм?

Карыймын да бер як-якка,
Бер алдыма, бер артка,
Дөньяга куям йөземне, —
Киндерне туң агарта...

1995.

* * *

Гасырларга кушып җырламаслар
Синең белән минем исемне:
Гөле шулдыр... Әмма яланнары,
Заманнары бөтен ич инде!

Җандагыны чыгып кычкырмадык.
Ә каеннар барыбер сизенгән:
Боларны да күреп калыйк диеп,
Юл буена чыгып тезелгән.

Ил күзеннән нәрсә яшерәсең! —
Таң җилләре искән чакларда
Мәңгелекнең ап-ак каеннары
Пышылдарлар бәзнең хакта да...

1995.

* * *

Йөрәгемдә йөрткәнгәме —
Гөл дидәләр ярамны.
Гөл дидәләр...
Алсуланып,
Яраннарга таралды.

Минем генә ярам түгел,
Тимәгез яраннарга:
Ал буласылары бардыр
Заманнар каралганда...

1995.

* * *

Су буенда казлар тәзәтенә,
Уйнап туйганнар да инештә.
Ап-ак булып әзерләнә алар,
Әзерләнә туйлар килешкә.

Агымсуда таллар чәч юалар...
Усакларда — алсу намазлык:
Гамәл-гыйбадәткә талганнардыр,
Илгә-көнгә теләп тазалык.

Ындыр артларында йокымсырап,
Кибән-кибән җәйләп утыра.
Күчмә кошлар күккә шигырь яза,
Яза алар, —
Укы-укыйма!..

Ә мин каләмемне куеп торыйм
Акын барда телең тый, диләр..
Сыңамы соң инде бу дөньяда
Ул көзләргә җиту, и юләр!..

Бәрәкәтле сулыш таралыдыр
Дулкын-дулкын булып инештә.
Мәңге шулай әзерләнә җиһан
Яңа җаннар җиргә килешкә...

1994.

Сәхнә биеклегендә калу

Утыз биш кешедән торган коллективның Себер ягына юл тотуы матди кыенлык кичергән чор өчен шактый гайре табигый хәл булып тоела. Шулаймы, К.Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры чыннан да сәяхәткә җыенамы? Әнә шундый сорау белән театр директоры Роберт Шәрифҗан улы Әбелмәмбәтовка мөрәҗәгать иттек.

Әйе, нәкъ шулай. Әмма әлеге сәяхәт хакында сөйли башлаганчы, театрның көнкүрешен, соңгы сезон эшчәнлеген һәм яңа спектакльләр әзерләнүен искә алып үтәргә кирәктер. Коллектив дистә еллар дәвамында бинасыз да, режиссерсыз да яшәде. Сөенечкә дисәм дә була, хәзер бинабыз да. Мәскәүдә режиссерлык һөнәрен үзләштереп кайткан белемле егетебез дә бар. Өч сезоннан бирле режиссер Рәшит Заһидуллин театрда яңа спектакльләр әзерли, тамашачы игътибарына тәкъдим итә. Элек һәр килгән режиссер үзенчә үзгәртеп карый, коллективны бер-ике елга артка тарта да, китеп бара иде. Хәзер ышанып, җигелеп йөкне тарта ала торган кешебез бар. Театрның репертуары нык үзгәрде. Соңгы сезонда Н.Фәттахның «Итил суы ака торур», И.Грекованың «Тол хатыннар көймәсе...» әсәрләрен куеп, без театр сәнгатендә көчебезне күрсәттек, эшкә сәләтле икәнлегебезне раcладык. П.Бомаршеның «Шау-шулы көн, яки Фигароның өйләнүе» спектаклен караган Франция делегациясе бу тамашага югары бәя бирде һәм коллективны үз илләренә гастрольгә чакырды.

Тамашачы дигәннән, без яшьләрне дә онытмыйкуябыз. Мәсәлән,
быз, алар өчен спектакльләр нәниләр дә,
«Баһадурның бәхете» дигән спектакльне
өлкәннәр дә яратып карый. Яңа сезонда без аның
икенче өлешен куярга исәп тотабыз. Гомумән, быел
өр-яңа биш спектакль куярга җыенабыз.

Авыр ел дип тормадык, 15 майда сезонны ябу белән, республикабыз районнарына гастрольләргә чыгып киттек, 12 районда булып, 88 спектакль куйдык.

Шөкер, сәнгатьне ихластан аңлаган җитәкчеләр, эшмәкәрләр саны да арта бара. Моны көндәлек эш дәверендә Казаныбызда да, гастрольләргә чыккач, Татарстан районнарында да күрергә туры килә. Хәтта ерак Сургутта шундый дустанә, җылы мөнәсәбәтнең шаһиты булып кайттым.

Ә 3 ноябрьдә яңа сезон башлана. Ул үзебезнең театр коллективы әзерләгән концерт-тамаша белән ачыла. Артистларыбыз җырга да, биюгә дә сәләтле. Халык соравы-үтенече белән айга бер концерт бирәчәкбез.

Кәрим Тинчурин театры тамашачыларын музыкаль очрашулар, ноябрь ахырында «Игълан буенча өйләнү» дигән яңа спектакль көтә.

Быел театр сезонын соңга калдыруыбызның сәбәбе бар. Моннан ай ярым элек Төмән, Сургут шәһәрләренең мәдәният оешмалары җитәкчеләреннән чакыру алган идек. Сургут шәһәренең 400 еллыгын бәйрәм итү һәм шул уңайдан Себердә яшәүчеләргә татар спектакльләре куярга чакыру иде ул. Мәскәү театрлары, танылган җырчылар А.Пугачева һәм Ф.Киркоров бу якларда булып киткәннәр инде. Хәзер бирердә татар-башкорт тамашачысы өчен декада үткәрелә. Без ерактагы милләттәшләребезгә өч спектакль, концерт алып барабыз. Сургуттагы тантанада Татарстанның танылган җырчылары Зөһрә Сәхәбиева, Хәйдәр Бигичев, Рафаэль Ильясов катнаша һәм чыгышларыбыз бергә узачак.

Себер якларында профессиональ театр беренче тапкыр спектакльләр куячак. Дөрес, анда эстрада артистлары булгалап торган. Ә халыкның театр сәнгате белән дә танышасы килә. Без анда тугыз көн булабыз һәм шушы кыска гына арада ерактагы мөселман кардәшләребезнең игътибарын театр сәнгатенә җәлеп итәрбез дигән уй-теләк белән яшибез.

14 октябрьдә 35 кеше самолет белән Себергә сәяхәт-гастрольгә, тантанага оча. Әгәр Татарстан хөкүмәте бу яктан самолет белән декорацияләрне һәм артистларны озатуны, ә теге яктан кайтуны Төмән өлкәсе үз өстенә алмаса, театр җитәкчесе ике башлы кеше булса да, моңа тәвәккәллеге җитмәс иде.

Чит җирләрдә яшәүче кардәшләребез-милләттәшләребез турында күп язып, күп сөйләсәк тә, ул сүздә генә кала. Баргач, күргәч, безнең үз казаныбызда, аларның үз казаннарында кайнавын беләсең. Сәнгатькә талымсызлар һәркайда алдан өлгерәләр, халтура алга чыга. Профессионалларга күбрәк йөрергә кирәк. Мәсәлән, әлеге сәяхәт безнең коллективка Сургут белән дуслык элемтәләре урнаштыру мөмкинлеге бирә. Без, бер-ике ел саен барып, яңа спектакльләребезне андагы тамашачыларга да күрсәтергә исәп тотабыз. Шулай итеп, Татарстандагы театр сәнгате белән ерακта яшәүче татарлар да танышып барачак. Ул якларда яшәүче үзешчәннәргә ярдәм дә сорала. Алар, беренче чиратта, драма әсәрләренә мохтаҗ. Ә спектакльне тапкан, сайлап алган очракта, аны сәхнәләштерүдә профессиональ белгеч киңәше, ярдәме таләп ителә. Без шушы нәрсәләрне дә истә тотабыз һәм үзара хезмәттәшлеккә әзербез.

Театрларга авыр чор килде. Әмма бүгенге көндә бик тырышып эшләгән, иҗат иткән коллективка аерым караш, мөнәсәбәт булырга тиеш. Тигезләү чоры үтте, алай бара алмый ул. Тамашачыны үз залына китерә, җыя алучы коллектив чын мәгънәсендә яшәргә, иҗат итәргә хокуклы, дип саныйм мин.

Ә без үз чиратыбызда тәвәккәлләп ерак Себер якларына юл тоткан театрыбызга яңадан-яңа иҗат уңышлары һәм хәерле сәфәр теләп калабыз.

Әңгәмәне Сәрмәдия **СӨЛӘЙМАН** оештырды.

Тинчурин театры Себерне җылытырга бара



● «Итил суы ака торур» спектакленнән күренеш.
● «Мәкәрҗәгә барган идек» дигән спектакль. Артистлар Зөфәр Харисов һәм Люция Галләмова.

Әлеге дә баягы

Тамаша дип шаярмыйк...
яки Минсез мине өйләндерү

Русия Дәүләт Думасына сайлауларга кадәр әле шактый вакыт бар. Белеп-сизенеп торам: гаять ыгы-зыгылы һәм шау-шулы сәяси тамаша көтелә. Хәер, ул тамашага хәзерлек инде башланды да булса кирәк. Күп белгән атлы булып ясалган сәяси чыгышлар, фараз-гөманлаулар сәгать саен кабатланып тора. Яңабаштан «демократия» һәм «кеше хокуклары» дигән төшенчәләр искәртелә, хәтергә төшерелә башлады. Сайлауны гади хезмәт ияләре күз алдында дискредитацияләү, кадерсезләү максатыннан чыгып, әллә ниткән партияләр һәм хәрәкәтләр булдырылды. Һәммәсе халыкны кайгырта. Ә халык ярым ач һәм ялангач. Сайлаулар якыная төшкәч, әле икмәк һәм аракы бәяләренең дә очсызланып куюы бар, хәтта бушка азык-төлек өләшүгә кадәр тәвәккәллек итүләре бик ихтимал. Ялангачлар өстенә төрле игълан һәм мактау кәгазьләреннән күлмәк-ыштан өтмәлләп кидерерләр. Әмма болар һәммәсе сайлаулар узганның икенче көнендә үк туктатылачак, онытылачак. Хезмәт ияләрен — эшчене, игенчене һәм дә интеллигенцияне кычкыртып талауның соңгы һәм хәлиткеч өлеше башланып китәчәк аннан соң...

Партияләр һәм хәрәкәтләрнең күплеге — халыкны саташтыру өчен. Чынлыкта бүгенге Русиядә ике партия бар. Беренчесе, хакимият партиясе — хуҗалар (өй хуҗалары), үз парламентын һәм үз халкын, үз шәһәр һәм авылларын утка тотучы, кеше гомерен берническә санамаган канәгатьләр, туклар партиясе. Икенчесе — шуларга каршы хәрәкәт, аерым кеше һәм гамәлләрнең генә түгел, бөтен илнең бөлгенлеккә, коллыкка төшә баруына кискен каршы чыгучылар. Әмма аларның зур кимчелеге — таркаулык һәм Крылов бабай мәсәлләреннән хәбәрдар булмавуда.

Русиянең Дәүләт Думасына булачак сайлауларга битараф түгел мин һәм битарафларны да уянырга чакырам. Без — бәйсез, без — мөстәкыйль, дип инанган якташларымны да уйланырга чакырам. Бәйсезлеккә битарафлык белән ирешү мөмкин түгел. Телибезме, юкмы, әлегә без Русия гражданнары, Русия кануннары белән яшибез. Һәм Мәскәү вакыты белән уянабыз, йокларга ятабыз. Бу — хакыйкать.

Минем Русия Дәүләт Думасына кандидат итеп капма-каршы ике хәрәкәттән күрсәтелүем гаҗәп тоелган күпләргә. Принципсызлыкта гаепләү өчен нигез бар. Дөресен әйтим, «Наш дом — Россия»нең исемлегендә фамилиямне күргәч, мин үзем дә хәйран калдым, нигә юрарга белмәдем. Чөнки берничә хәрәкәт һәм партиядән чакыру алсам да, миңа бу хәрәкәттән чыгучы, шалтыратып кына булса да ризалыгымны сораучы булмады. Ике ел гына әүвәл Русия Югары Советы бинасында үземә төбәп танклардан атучы, бәйсез яшиселәре килгән өчен генә Чечен Республикасын җимерүче, дистә меңләгән гаепсез кешеләрне үтертүче, икътисади реформаларны сылтау итеп илне күтәрәмгә калдыручылар белән минем һичкайчан уртак эшем булганы юк. Ә ул исемлеккә ничек эләккәнмен — һич аңламыйм. Ирекле сайлау хокукларын бозып, кешенең үз фикерен сорап-нитеп тормый гына теркәп кую кемгә кирәк булган һәм ни өчен? Бу сорауга Үзәк сайлау комиссиясе һәм «Наш дом — Россия»нең Татарстан бүлекчәсе тиз арада җавап бирер һәм гафу үтенер дип өметләнәм. Юкса, бу фактка тирән уйланылган көлү һәм мыскыл итү төсмере салынганлыгы да күзгә бәрелеп тора. Региональ исемлеккә, соңгы, бишенче кеше итеп кертелүне башкача кабул итеп булмый. Чөнки Дәүләт Думасын бары тик шул хәрәкәт вәкилләреннән генә туплаганда да, ул урынга куелган кешенең депутат булып узу ихтималы нульгә тиң.

Бу көнгә кадәр дә авыр сүз, торлечә рәнҗетергә маташуларны аз очратмадым. Бусы инде бигрәк тә, чамадан артып киткән түгелме?! Нигә һәм кемгә кирәк булды бу, әфәнделәр! Минсез мине өйләндергән кебек булып чыккан түгелме?

Ринат МӨХӘММӘДИЕВ,
Татарстан Язучылар берлеге идарәсе рәисе.

ХЫЯЛЫЙЛАР ИЛЕ,

яки Коммунизм кыры нигә кысыр?

(Ахыры. Башы 2 нче биттә).

ителде» Билгеле ки «социализм — коммунизмның беренче фазасы». 1864 елда Эрфурт шәһәрендә (Германия) коммунист марксистлар съездында «коммунизм төзү программасы» кабул ителә Коммунистларның оппонентлары — социал демократлар «Әйе коммунистлар халыкка тигезлек бирә алырлар әмма ул тигезлек нигезендә хөерчелек ятачак», — дигәннәр Коммунистларның моңа күпме генә ачуы килмәсен, дөреслек социал-демократлар ягында булып чыкты

Сталиннан (аның вакытында ГУЛАГта 67,4 миллион кеше юк ителә) соң властька Н.Хрущев килде Ул «25 ел эчендә СССРда коммунизм тулысынча җиңәчәк», — дип бөтен дөньяга чаң сукты «Төп бурычыбыз — 2-3 ел эчендә (!) Американы куып җитү һәм узып китү» дип партия съезды мөнбәреннән белдерү ясады Совет пропагандасы көн-төн шул юнәлештәге «уңышлар», «капитал илләрендәге мескен ачлар» турында сөйләде Миллионнарча гектар иң уңдырышлы җирләрдә кукуруз чәчәргә керештеләр Билгеле булганча, үз флотын булдыру өчен Петр Беренче Голландия верфьләрендә корабль төзүче булып эшләгән Хрущев та Америкага барып кукуруз игү серләрен «өйрәнеп» йөрде Шуннан соң тундрада да кукуруз чәчә башладык Янәсе, кукуруз ашатып бик күп мал үрчетәбез дә, Американы узып китәбез Шул хакта әллә күпме партия съездлары, пленумнары үткәрелде «Партгеносселар» — партиянең край өлкә комитеты җитәкчеләре һ б. бер-берсеннән уздырып «Американы куып җитеп, узып китү рецептларын» тәкъдим иттеләр

Утопистлар үзләре тудырган хыялый дөньяда яшиләр Ә кукуруз үч иткәндәй җылыны ярата, салкында үсми Шулай итеп миллионнарча гектар иң яхшы җирләр буш торып калды Менә-менә «коммунизмга керәбез», дигәндә 70 нче еллар башында икмәккә моңа кадәр күрелмәгән дәрәҗәдә чиратлар тезелә башлады Ак икмәкне табиб язуы белән генә бирделәр Башка ашамлыклар да юкка чыкты Партиянең «коммунизм төзү программасы» нәтиҗәсе икенче төрле әйткәндә утопия иде бу... Әмма ни генә кыланмадылар ул чакта...Рязань өлкәсенең хуҗасы Ларионов «дәүләткә ит тапшыруның өч еллык планын бер елда үтәү өчен» өлкәдәге күршеләрдәге мал-туарны (сатып алып) суеп бетерде һәм, соң булса да, ялгыш юлдан китүен аңлап, үз-үзен юк итте .. Бөтенсоюз авыл хуҗалыгы академиясе президенты Т.Лысенко күз дә йоммый «Тармаклы бодай (ветвистая пшеница) уйлап таптым, бөтен Җир шарын бодай белән күмәчәкмен», дип белдерү ясады һәм күкрәгенә икенче Алтын Йолдызны такты Бу да утопия иде .. Тянь-Шань тауларыннан кечкенә буйлы үгезләр (ул яктагы сыерларның сөте куе була) китереп, Холмогор сыерларын каплаттылар Янәсе, Холмогор сыеры кукуруз ашап бик күп куе сөт бирәчәк (әйе Канада сыеры елына 10 мең килограмм куе сөт бирә Әмма анда аларга «гәзит укытмыйлар», туклыклы азык бирәләр Нәселләре дә әйбәт) Әмма бу юлы да урысча килеп чыкты сөт тә, ит тә булмады

— 70 нче еллар башында туган авылыма кайттым Урамда ниндидер мылтыктан ату тавышы ишетелде «Авылда да эт аталар икән», — дип уйладым Әмма алай булып чыкмады Райком кушуы (димәк Мәскәү) буенча кәҗәләрне аталар икән Кәҗә бит ул сарык түгел тоттырмый кача Ә Мәскәүдән күрсәтмә бар мал-туар тотуны нык чикләргә! Шул елларда халыкның бәрәңге бакчасын да кистеләр Алмагач өчен салым салдылар Халык моңа җавап итеп алма бакчаларын бетерде Хрущев үзенең туган авылы Калиновкада шәһәр тибындагы биш катлы йортлар салдырды Авыл кешесен мал-туар тотмаска, бакча-фәлән белән баш ватмаска чакырды Янәсе халык ит, сөт май икмәк җиләк-җимешне юнь генә хак белән дәүләттән алачак Ә коммунизмга күчкәч (80 нче еллар ахырында) бөтен нәрсә бушлай биреләчәк Туган авылым Нәсибашта ул чакта 500 хуҗалык (димәк 500 сыер 1000 сарык) бар иде Ә совхозның сыерлар саны 200гә дә тулмый Дәүләт планын да үти алмый иде ул Халык сыерларын чалып бетергәч ни булачагын беркем дә уйламады Дөресрәге, уйларга рөхсәт юк иде М Салтыков-Щедринның башсыз градоначальниклар турында гаҗәеп эчтәлекле китабы бар Минемчә үзен коммунист дип атаган Мәскәү түрәләре ахмаклыкта урыс градоначальникларыннан һич тә аерылып тормыйлар иде

Урыс илен гомер буе аеруча ике нәрсә интектерде Беренчесе — дәүләт белән талантлы кешеләр җитәкчелек итмәде Тарихчылар фикеренә караганда Русиядә акыллы алга карап эшли торган ике генә патша — Борис Годунов һәм Павел Беренче генә булган Әмма аларны урыс түрәләре яратмаган һәм икесе дә фаҗигале үлем белән үлгән Икенчесе — Русия гомер буе искиткеч зур армия тотты бу туктаусыз сугыш алып бару өчен кирәк иде Совет чорында икътисадчыларның әйтүенә караганда һәр сум акчаның 90 тиене «сугыш уены» өчен тотылган Бүген дә дөньяда иң зур армия — Русиянеке Әле дә бюджетның өчтән бер өлешен армия ашый Әмма Дәүләт Думасын бу да канәгатьләндермәде һәм армия тоту өчен ул өстәмә акча бүлеп бирде Сугыш басып алу талау кочләү урлашу эшләмәү — сан ягыннан олы бер халыкның менталитетына әверелгән һәм моңа халык түгел аны, утопия дөньясында яшәтүче җитәкчеләре гаепле .. Ләкин бу фактны искә төшерүдән беркемгә дә җиңел түгел Әгәр татар халкының иле бүгенге Дания Швейцария Финляндия (халык саны территория ягыннан безгә якыннар) урынында булса нинди югарылыкларга күтәрелер идек без!

Кызганыч бүген дә урыс дәүләте башында шул ук утопистлар утыра Алар халык турында уйлап та карамыйлар Әйтик Русиядә 1990 ел белән чагыштырганда 1995 елның апреленә тормыш-көнкүреш азык төлек коммуналь ихтыяҗлар бәясе 5470 мәртәбә арткан! Ә хезмәт хакы 1220 мәртәбә генә үсте Шул еллар эчендә халыкның яртысыннан күбесе туры мәгънәсендә хөерчегә әйләнде 5 ел эчендә уртача гомер озынлыгы 5 елга кимеде Ә бит минераль байлыклар урман сулар иң уңдырышлы кара туфраклы җирләр буенча дөньяда Русиягә тиң ил юк! Шул илне аякка бастырасы иде дә бит әмма моның өчен хыялый карашлардан ваз кичәргә кирәк Ләкин моңа әзерлекле җитәкчеләр юк Русия хуҗалары базар мөнәсәбәтләре һәммәсен дә үз урынына куяр ач булгач халык эшли башлар дип өмет итәләр Шул хакта ачыктан-ачык белдерүләр ясыйлар Урыс менталитетын истә тотканда, бу — шулай ук буш хыял «Без ретуши» тапшыруында бөтен дөньяга билгеле академик С Лихачев «Минем айлык хезмәт хакым 65 доллар» — диде Ә менә Берләшкән Гарәп Әмирлекләрендә яшәүче һәркем аена 1500 доллар ала... Бу ил гарәпләренең төп байлыгы — нефть Хәлбуки республикабызда нефтьне гарәпләрдән ким чыгармыйлар әмма безнең өчен файдасы гына юк Хыялыйлар иленнән котылыр чагыбыз булыр микән?

Үзәкне үз итәләр

1991 елның көзендә, Татарстан Министрлар кабинеты карары белән, «Казан» милли мәдәният үзәге оештырылган иде Шушы өч ел эчендә ул, чынлап та, халкыбызның катлаулы тарихын, аның мәдәниятен өйрәнүче татар зыялыларын бергә туплап, аларның яңа хезмәтләре белән таныштырып торучы, күп тамашачыларда популярлык казанган «Сандугач», «Кышкы моңнар» фестивальләрен, төрле концертлар, кичәләр, татар яшьләре дискотекаларын оештыручы бер үзәк буларак танылды

Халкыбызның мәшһүр уллары Мирсәет Солтангалиевкә, Гаяз Исхакыйга багышлап уздырылган күргәзмәләр, милләтебезнең иң мәртәбәле уллары һәм кызларының шәҗәрәләреннән торган күргәзмә ачу халыкның, бигрәк тә яшьләрнең игътибарын җәлеп итте Бу күргәзмәне караган күп кенә мәктәпләр үзләрендә «Үз шәҗәрәңне беләсеңме?» дигән смотрлар оештырдылар

Иҗат кешеләренә багышланган кичәләр дә матур бер традициягә әйләнеп бара Чит илләрдә яшәүче милләттәшләребез дә милли мәдәният үзәге белән тыгыз элемтәдә тора Бөтентатар Лигасы Президенты Гали Акыш белән очрашу тамашачылар күңелендә онытылмаслык хатирә булып калды Төркиядән килгән кунагыбыз җырчы һәм композитор Барыш Манчо иҗаты белән дә тамашачылар милли мәдәният үзәге ярдәмендә таныштылар Безнең үзебездә дә чит илдән килгән кунаклар алдында мактанып күрсәтерлек экспонатларыбыз бар икән Биредә соңгы өч ел эчендә генә дә рәссамнарыбызның, скульпторларыбызның 60лап күргәзмәсе оештырылды

Күргәзмәләргә йөрүчеләрнең күпчелек өлешен яшьләр укучылар студентлар тәшкил итә Бу әлбәттә, бик куанычлы хәл Тагын шунысын да әйтергә кирәк яңа ачылган күргәзмәләрне калдырмыйча рәссамнарыбызның иҗаты белән даими кызыксынып торучыларның берсе. — Президентыбыз М Шәймиев

Күргәзмә заллары беркайчан да буш тормый Шушы араларда Казаннан Н Индюховның, Мәскәүдән Э Шаһиевнең һәм Х Якупов җитәкчелегендәге рәссамнар остаханәсенең күргәзмәләре булачак

Әлеге күргәзмәләрдә куелган картиналарның иң яхшыларыннан төзеләчәк экспозиция тиздән милли мәдәният музееның төп өлешен тәшкил итәчәк Музейга куелачак экспонатлар инде бүгеннән үк җентекләп өйрәнелә, тәртипкә салына Монда милләтебезнең горурлыгы булган Кол Гали, Сөембикә, Ш Мәрҗани, Г Тукай кебек бөек шәхесләребезнең тормыш юлын яктырткан документлар да, Алтын Урда дәүләте тарихы да, Казан ханлыгыннан сакланып калган ядкарьләр дә бар Кыскасы, биредә татарның тарихын күпкырлы яктырткан әйберләр тупланачак

Бездә яңа танылып килүче иҗат кешеләренә ярдәм итәргә һәрвакыт әзер торалар Рәссамнарның күргәзмәләрен уздырыр өчен күргәзмә заллары бушлай бирелә Моңа өстәп тагын шунысын да әйтергә кирәк тиздән «Чулпан» кинотеатры милли мәдәният үзәгенең филиалы булып 750 урынлы концерт залына әйләнәчәк Димәк Казан шәһәрендә концертлар уздыру өчен бөтен уңайлыклары булган заман таләпләренә җавап бирерлек бина сафка басачак

Аллага шөкер җыр өлкәсендә яңадан-яңа исемнәр калкып чыга Моның өчен мөмкинлекләр дә бар Тик кызганыч ки бию сәнгатенә игътибар җитеп бетмәгән Шушы хатаны төзәтү нияте белән милли мәдәният үзәге 50 кешедән торган махсус профессиональ бию ансамбле оештыра Әлеге яңалык белән кызыксынучылар бүгеннән үк милли мәдәният үзәгенә мөрәҗәгать итә алалар

Китап сөючеләрнең соравы буенча бүген 6 октябрьдә Г Тукай исемендәге Дәүләт бүләге иясе язучы Фәнис Яруллинның иҗат кичәсе була

Кичләрен бездә татар яшьләре өчен «Аулак өй» дип аталган уен-көлкеле заманча дискотекалар 25 яшьтән узганнар өчен «Син кайларда йөрисең икән?» дигән таныштыру кичәләре уздырыла . Таныш-белешләр дус-ишләр генә түгел хәтта бертуганнар да очрашып сөйләшер өчен вакыт таба алмаган бу заманда татар яшьләрен бергә җыйнап аларның буш вакытларын күңелле итеп үткәрүнең әһәмияте бик зур Яшьләр милли мәдәният үзәген үз итеп яратып йөриләр

«Казан» милли мәдәният үзәгенең ишекләре һәркемгә дә ачык Биредә сез үзегезне кызыксындырган барлык сорауларга да җавап табарсыз

Рәхим итегез!

Халисә ИСМӘГЫЙЛЕВА,
«Казан» милли мәдәният үзәгенең
директор урынбасары

Өмир КАМАЛИЕВ,
режиссер

● Күргәзмә залында.

Тик фәкать милләткә хезмәткә
мөхәббәт бәндә бар,
Банча, бунда ямь дә бар, ләззәт тә
бардыр, тәм дә бар!

Г.ТУКАЙ.

«Туран» фонды 1992 елда оешты. Аның максаты — татар халкының сәнгатен пропагандалау, борынгы традицияләрне торгызу, яшь рәссамнарның күргәзмәләрен оештыру, аларга матди ярдәм күрсәтү, милли сәнгатьнең иң яхшы үрнәкләрен дөньяга таныту.

«Туран» фонды узган ел татар тарихында беренче тапкыр «Сәнаигы нәфисә» дигән сәнгати журнал чыгара башлады. «Төрк дөньясы» һәм Бөтендөнья Ислам мәдәни үзәге (Истанбул) белән хезмәттәшлек итә, Будапешт, Истанбул, Исламабад һәм Әбу Даби шәһәрләрендә күргәзмәләр оештырды. Фондның президенты — Суфия Хәйбрахманова, идарә әгъзалары — Әнкара университеты профессоры Фәрит Хәкимҗанов һәм Татарстан Фәннәр академиясе аспиранты Әнифә Әхмәтшина.

Татарстан дәүләт музеена 100 ел тулуга багышланган фәнни-гамәли конференция барганда «Туран» фонды Габдулла Тукай музее белән берләлеп (директоры — Фәрит Яхин) «Түгәрәк өстәл» янында татар сәнгатен саклау һәм яңадан торгызу, дәүләт оешмалары һәм иҗат берләшмәләре белән бәйләнешләр турында зур сөйләшү үткәрде. Анда музей хезмәткәрләре, галимнәр, язучылар, журналистлар һәм төрле өлкәләрдән килгән кунаклар катнашты.

Бүген шушы сөйләшүдә катнашучыларның фикерләре белән таныштырабыз.

Дөнья фани,

Нияз ХАЛИТОВ, архитектура фәннәре докторы: Хәзерге вакытта авылларда да, шәһәрләрдә дә мәчетләр төзү нык җанланды. Әмма аларның архитектура бизәлеше һич тә канәгатьләнерлек түгел Бу бигрәк тә авылларда шулай Кирпечтән йә агачтан зур бина төзиләр дә манара утыртып куялар Ә бит алар бездән соң да берничә гасыр дәвамында яшәячәк архитектура истәлекләре булырга тиеш Күптән түгел без Кол шәриф мәчете ансамбле проектын тикшердек Ләкин ул уңышлы чыкмаган. Димәк, без мәчетләр төзү культурасын җуйганбыз.

Казанда иң матуры Мәрҗани мәчете, дибез. Әмма 120-130 кешегә исәпләнгән бу мәчет бер мәхәллә мәчете генә Мәчетләрне биш төргә бүләргә мөмкин мәхәллә, җәмигъ, әл-җәмигъ-әл-кәбир, мусалла һәм төрбә-мәчетләр. Гарәп илләрендә, Төркиядә мәчетләр тулы бер кварталны били, ә манаралары шәһәр силуэтына кабатланмас матурлык өсти Борынгы болгар һәм татар мәчетләре дә архитектура ягыннан Ислам дөньясында билгеле булганнар. Алар җирле материаллардан һәм мөмкинлекләрдән чыгып эшләнгәннәр Ә урыслар. Казан ханлыгын яулап алгач мәчетләрне җимергәннәр йә чиркәү иткәннәр. Яңалары исә урыс архитекторлары тарафыннан патша хәзрәтләре рөхсәт иткән рамкаларда гына эшләнгән Безгә эчке тыелудан котылып, мәхәллә мәчете рамкаларыннан киңрәк масштабка чыгарга кирәк. Аурупа дәрәҗәсе безне кызыксындырмый, безгә гарәп илләреннән, Һиндстаннан өйрәнергә кирәк.

Мәчетләр төзелеше архитектурасын карасак, аның үрнәкләре безгә Багдад солтанлыгыннан килгән Алтын Урда чорында Болгар иле зур мәдәни үзәккә әйләнгән, шулай да ул — провинция генә, Алтын Урданың башкаласы Түбән Иделдә булган Гранада солтанлыгы (14-15 нче йөзләр) бу җәһәттән дөньякүләм җәүһәрләр биргән

Мин күп еллар буе «кәгазь архитектура» белән шөгыльләндем, ягъни укыдым, өйрәндем һәм архитекторларыбызның мәчетләр төзүдә җибәргән методик хаталарын табарга тырыштым Һәм безгә, киләчәктә ул хаталарны төзәтеп, элекке даныбызны кайтарырга, дөньякүләм казаныш булырдай мәчетләр салырга кирәк.

Равия СИМАШОВА, «Болгар» тыюлыгы хезмәткәре: Мин дә үзебезнең Болгарга кагылышлы берничә сүз әйтим әле. Тыюлыкның үз вазифалары, үз проблемалары Безгә бик күп кунаклар килә кайвакыт көненә өчәр-дүртәр теплоход белән килгән туристларны кабул итәбез Без, әлбәттә, аларның килүенә шат, әмма шул туристларны кабул итәрлек шартлар әлегә тудырылмаган. Күмәк чараларны ничек оештырырга? Аларны үткәрсәң дә начар, үткәрмичә дә ярамый Әйтик, туристлар һәм гыйбадәт кылучылар бергә туры килгәндә нишләргә? Туристларның үз кануннары алар музыка уйната, җәен ярымшәрә диярлек йөриләр, төрле милләт кешеләренең эсседә су яки башка төрле эчемлек эчәселәре килә Аларга изге җиргә аяк басканнарын, биредә алай ярамаганлыгын, изгеләр рухына зиярәт кылучыларга илаһи тынлык кирәген ничек аңлатырга? Узган ел Болгар тыюлыгына 25 ел тулуны бәйрәм иткәндә театраль тамаша оештырдык. Анда «Ибн Фадлан» да, сәхабәләр дә, «Петр I» дә бар иде. Күмәк чараларны инглиз телендә дә үткәрдек Шунысы аяныч, Болгарда ни татар мәктәбе, ни татар класслары, ни балалар бакчасы юк. Узган ел яшьләр корылтаена килгән кунакларны «хан» белән «ханбикә» каршылады, зур концерт булды. Ә бит изге урында күңел ачулар бик үк урынлы түгел Кеше сөякләре өстендә, яшел үләнлектә футбол уйнау килешәме?! Алла Пугачева белән Филипп Киркоров килергә һәм футбол ярышлары да оештырырга ниятләгәннәр иде; Аллаһыга шөкер, тегеләре килмәде, футбол ярышы да булмый калды ..

Без, әлбәттә, уңай чишелеш табарбыз, әмма бу җирле хакимият вәкилләре катнашында табылган иң дөрес чишелеш булырга тиеш.

Нәҗип ИСМӘГЫЙЛЕВ (Нәккаш), Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты галиме: Татар халкы, көлдән терелгән феникс кошы кебек, исән калды, сәнгатен дә бетермәде. Ә бит безгә татарның милли мәдәнияте дә, сәнгате дә юк, дип һәрдаим тукып килделәр Карагыз сез татар каллиграфиясе сәнгатенә: шәмаилләр, ләүхәләр, тугралар XX йөзгә кадәр сокланырлык, гүзәл килеш сакланган. Шәмаилләр юк ителсәләр дә, аларның күп өлеше исән-имин калган. Типографик шәмаилләр, Татарстан дәүләт музеенда профессор Покровский коллекциясендә сакланып, безнең көннәргә килеп җиткән. мөһерләр коллекциясе дә исән-сау. Пыялага язылган шәмаилләр Розалия Шаһиева тырышлыгы белән яңа буын вәкилләренә дә барып ирешер, иншалла. Литографик шәмаилләр Казан дәүләт университеты музееның сирәк китаплар бүлегендә тупланган. Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтында, шулай ук республика Милли китапханәсендә дә, Чаллы картиналар галереясы фондында да, шөкер, шәмаилләр бар.

Шунысы аяныч, сакланып калган шәмаилләрнең әлегә каталоглары юк, аларны башка илләргә дә күрсәтергә кирәк бит. Каллиграфия сәнгатенең үткәнен, хәзергесен бәян итеп, альбомнар, коллекцияләр чыгарырга, пропагандаларга кирәк. Мондый югары сәнгатьле әсәрләргә ихтыяҗ зур. Шәмаил сәнгате буенча махсус белгечләр әзерләү дә сорала Бу турыда музей хезмәткәрләре дә, сәнгать белгечләре дә уйлансын иде.

Мин үзем Татар дәүләт коллиятендә (колледж) дүртенче ел укытам. Студентлар башта кириллица нигезендә матур итеп язарга өйрәнәләр, аннары гарәп каллиграфиясенә күчәләр Шушы традицияне дәвам итәрдәй сәләтле студентларыбыз бар, беренче күргәзмәбезне оештырдык инде. Димәк, каллиграфия сәнгатенең киләчәге бар.

Динә ВӘЛИЕВА, Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты өлкән фәнни хезмәткәре: Безнең институт 1939 елда СССР Фәннәр академиясенең филиалы булып ачыла. 1968 елда Баян Гыйззәт тырышлыгы һәм ярдәме белән сәнгать бүлеге ачыла һәм өч юнәлештә эшли башлый Безнең хезмәткәрләр хәзер бу өлкәдә ниләр башкара соң? Галимнәребез төрле музейларда консультант вазифаларын үтиләр. Гарәп һәм фарсы телләре белгечләре борынгы кулъязмалар белән эшлиләр, борынгы татар телен хәзерге телгә күчерәләр. Дәүләт күләмендәге мәдәни программаларны тикшерү, төзәтмәләр кертү дә безнең галимнәр катнашында башкарыла Институт хезмәткәрләре бик күп төрле экспедицияләргә йөриләр Галимнәребез иҗади берләшмәләр белән тыгыз элемтәдә торалар, тарихи музейлар ачуда турыдан-туры катнашалар, методик һәм гыйльми ярдәм күрсәтәләр. Күптән түгел Биләрдә Альфред Халиков музее ачылды Анда аның археологик материалларын системага китерүдә галимнәребез турыдан-туры ярдәм итте. Геннадий Макаров борынгы халык уен коралларын эзләп таба, реконструкция ясый һәм яңадан халыкка кайтара. Борынгы халык җырларын, онытылган көйләрне дә эзләп табып танылган җырчыларга өйрәтәбез.

Шул еллар эчендә Татарстан Фәннәр академиясе уникаль архив туплады. Бу документлар, бу материаллар чын-чынлап халкыбызның хәзинәсен тәшкил итәләр.

Фирсинә САФИНА, Тел, әдәбият һәм тарих институты өлкән хезмәткәре, тарих фәннәре кандидаты: Мин 27 ел экспедицияләрдә йөрдем, татар яшәгән төбәкләрдә аяк басмаган җирләр бик аз калгандыр. Йөри-йөри «чулак» сүзенең мәгънәсен бөтен тирәнлеге белән аңладым Элгәре «чулак» дип начар бирнә әзерләгән кыз балага әйткәннәр Шуңа 6 яшьлек кызларны җеп эрләргә өйрәткәннәр, 8 яшьтән туку станогы янына утыртканнар. 12 яшендә инде ул үзенә бирнә әзерләгән. Кыз баланың уңганлыгын ул чакта бирнәсенә карап бәяләгәннәр. Һәр авылда оста чигүче, бәйләүче, тукучы булган, кызлар шулардан өйрәнгәннәр. Матур намазлыклар, сөлгеләр чигүче, чүпләмле сөлгеләр тукучы кызлар бармы бүген? Юк. Чөнки буыннар чылбыры өзелгән.

Казанда Сафьян урамы бар. Элек анда тирәчеләр яисә читек тегүчеләр яшәгәндер. Читек — бик уникаль аяк киеме, һәм мин бу аяк киемен болгарлар гына кигән дип саныйм Көҗә тиресеннән тегелгән мамык кебек йомшак читекләрне сафьян читек дигәннәр. Дәүләт Советы Рәисе Василий Лихачев Америкага бүләк итеп читекләр алып барды, американнар аларны күреп ах иткәннәр. Әмма бу уникаль милли аяк киемнәрен күпләп эшләү хәзер юк диярлек. Арча милли аяк киемнәре фабрикасына «Спартак» начар көннәр җибәрә, җепләренең дә сыйфаты ташка үлчим, җитмәсә, төсләре дә туры килми, ә безгә чиккән чүәкләрне, каюлы читекләрне эшләү алымнарын югалтырга һич ярамый, чөнки киләчәк буыннар гафу итмәс.

Оста үз һөнәренең серен балаларына яисә якын туганнарына гына өйрәтеп калдырган. Хәзер дә алар эш серләрен теләсә кемгә ачмыйлар. Моннан берничә ел элек Чаллыда һәм ЭВМ заводында хатын-кызлар өчен бизәнү әйберләре эшләргә керештеләр. Барып чыкмады Ә бервакыт сәнгать салонында шулкадәр матур бизәнү әйберләре сата башладылар. Кыйммәт, шулай да кешеләр кырылып алалар. Йөри торгач, эзләнә торгач, таптым бит осталарны дүрт рәссам берләшкәннәр дә менә дигән камил әйберләр эшли башлаганнар Сәнгать әйберләрен күпләп җитештерергә ярамый, чөнки аларда останың кул җылысы калырга, күз нуры түгелергә тиеш. Кулдан эшләнгән сувенирларның кыйммәте дә шунда.

Татарстанда иң әйбәт кызыл балчык — Питрәч районында. Җирле министрлык аны Казанга ташып, биредә цех ачмакчы иде Барып чыкмады, чөнки юлда килгәндә балчыкның сыйфаты югала

икән Димәк, тегә яки бу һөнәрчелек кайда барлыкка килгән, шунда гына дәвам ителергә тиеш

Үзебезнең гамәли сәнгатьне башка халыкларга, дөньяга танытырдай сувенирлар юк бүген Каян килсен соң алар! Күпме еллар дин әзәрлекләнде, күп эшләре белән шөгыльләнү бетте түбәтәйләр, калфаклар «искелек калдыгы», дип бәяләнде Хәзер буыннар чылбырын ялгарга кирәк Миңа калса, туку, чигү бәйләү кебек һөнәрләрне авылларда өйрәтү кулай булыр иде чөнки хәзер анда да эшсезлек хөкем сөрә бит

Хохлома хәзер дөнья базарына чыкты, ә без нишлибез? Бусы — үзебездән тора Мин шундый цехларның берсен Питрәч районының Шәле авылында ачарга хыялланам Анда яшьләр күп, уңганнар Мин үзем чупләмле сөлгеләр тукый беләм, шуңа башкаларны өйрәтә дә алам Бу турыда ныклап уйланасы иде Авыр заман бер узар ул Сәнгатебезне саклап калу өчен заман рәтләнгәнне көтеп ятарга ярамый, соңга калуыбыз бар.

Җәүдәт МИҢНУЛЛИН, Казан дәүләт университеты укытучысы, тарих фәннәре кандидаты: XIX йөз ахырында, XX йөз башында татар байлары, сәүдәгәрләр химаячелек-булышлык итү белән байтак шөгыльләнгәннәр Менә безнең бүген сөйләшә торган Туалалар Ырынбур губернасында хәйрия акчалары милли китапханә салуга тотыла Игелекле башлангыч башка төбәкләргә дә киң җәелә Бакы Алматы Ташкент, Омск Томск, Пржевальск һ б шәһәрләрдә дә шундый милли китапханәләр төзелә

Беренче Бөтендөнья сугышында татар меценатлары солдатларга, аларның гаиләләренә госпитальләрдәге яралыларга ярдәм оештыралар 1914 елда «Җәмгыяте хәйрия» оешмаларының корылтае уздырыла Петербургта хәтта комитет та төзелә Кыскасы бу оешмалар бүгенге мәгариф мәдәният һәм социаль-тәэминат министрлыклары вазифаларын өлешчә башкаралар Әмма революциядән соң коммунистлар режимы бу оешманы юкка чыгара 1921 елгы ачлыкта аларның берсе дә булмый Бу оешмалар бетерелмәсә Идел буендагы коточкыч фаҗига шулкадәр масштаблы булмас та иде Кызганыч ки, бүгенге икътисади кыенлык андый хәйрия җәмгыятьләренең кирәклеген тагын көн тәртибенә китереп бастырды

Сорау: Җәүдәт әфәнде, чыгышыгызда бу проблеманы бик дөрес кузгаттыгыз. Хәзер тагын шундый заман җитте, безнең күңелләрдә шәфкатьлелек орлыкларын шыттырырга бик вакыт. Янәшәбездә хәерчеләр, эшсезләр, дөнният ни дә музей ни аңа мәчет тә чиркәү дә кирәкми Ә бит хәзер татарлар да бала тууны да көшә үлүне дә аракы белән билгеләп үтә Шушы афәттән котылу юлларын эзләргә кирәк безгә ә аның юлы бер генә — рухыбызны яңарту

Быел изге Болгар җиренә 5 мең бала алып бардык Алар борынгы бабаларыбызның изге рухын тоеп җан төннәре белән чистарынып кайттылар Питрәч районының Пановка зонасында җинаятьчеләр өчен мәчет ачтык дөресрәге намаз уку тәртипләрен өйрәтеп гыйбадәт кылу өчен мөмкинлекләр тудырдык Хәзер анда 30-40 тоткын өлкәннәргә ияреп, башларына түбәтәй киеп, җомга намазына йөри Аларның берсе дә эчми наркотиклар кулланмый, эчке тәртипләрне бозмый Хәзер алардан күрмәкчә, христианнар да гыйбадәт кыла башлады Тоткыннарны реабилитацияләү үзәге оештыру да зарур булыр иде чөнки коточкыч лагерь тәртипләреннән соң кеше тиз генә үз асылына кайта алмый яңадан рәшәткә артына керергә мәҗбүр була

Әлфия НУРИЕВА, Казандагы 40 нчы профессиональ училище директоры: Безнең училище элек сатучы һөнәренә өйрәтә иде хәзер декоратив-гамәли сәнгать белән шөгыльләнүче белгечләр әзерлибез Моннан өч ел элек татарнчы училище чит ил кешеләренә бүләкләр әзерләү өчен генә махсус ачылган икән дигән фикер калмасын иде Бу яшьләр аларның белемнәре алтын куллары үзебездә кала бит Училищены тәмамлагач ирекле диплом алып, кайсы кая китә Аларны бер урынга җыючы татар халкының гамәли сәнгатен торгызуда җиң сызганып эшләүче үзәк кирәк

Һөнүз МӘХМҮТОВ, театр һәм сәнгать белгече. Конференциядә мин үзем бик күп мәгълүмат алдым һәм тулаем уңай фикердә калдым Әмма күңелне тырнаган фикерләремне дә әйтми кала алмыйм Татарстан дәүләт музеена 100 ел тулуга багышланган Бөтенроссия фәнни гамәли конференциясенең темасы — «Россия һәм Татарстан музейларында Көнбатыш һәм Шәрыкның гуманистик традицияләре» дип атала ул үзе дә «Россия» сүзе дә артык монда Бу бит Татарстан җире конференция темасын болай кую безнен мөстәкыйльлеккә каршы килә Шуңа күрә мин аның тематикасын кабул итеп бетерә алмадым Пленар утырышта бу хакта тарихчы Булат Солтанбеков та әйтеп узды Төп докладта музейның татар эшләкләләренә игътибар аз булды төгәлрәк әйтсәк татар зыялыларының музей төзүдәге хезмәтләре

хакыйкать бакый

кай музее бинасын да чечен имамы Шамилнең улы генерал Мөхәммәтшәфи салдырган Мөэмин-мөселман өчен 5 фарыз бар намаз уку, ураза тоту корбан чалу, хаҗга бару һәм садака бирү Шуңа күрә XIX гасыр азагында ук хәйрия җәмгыяте институты эшли башлый Гасыр башында оешкан төрле татар җәмгыятьләре, шул исәптән «Җәмгыяте хәйрия» оешмасы да тирәнтен өйрәнүне сорый. «Җәмгыяте хәйрия»нең беренче оешмасы Казанда 1891, калганнары 1897 елда ачыла. Бу оешмалар Русия Эчке эшләр министрлыгына карый, һәм аларның уставы да төзелә. Моңа күпмедер дәрәҗәдә Исмәгыйль Гаспралы этәргеч бирә Ул үзе чыгара торган «Тәрҗеман» газетасында «Җәмгыяте хәйрия»ләр турында еш яза Йөзләп шундый зур шәфкать оешмасы барлыкка килә 1913 елда да аларның саны 87 була әле Казанда гына түгел, Петербург, Ырынбур, Әстерхан, Түбән Новгород, Касыйм, Чиләбе кебек татарлар күп яшәгән шәһәрләрдә, хәтта Вологда, Ростов-Дон, Архангельск кебек урыс шәһәрләрендә дә, Кытайда, Урта Азия, Казахстан, Төркия Финляндиядә шундый татар җәмгыятьләре оеша Шәфкатьле татар байлары кулларыннан килгәнчә халыкка ярдәм кулы сузалар «Җәмгыяте хәйрия»ләр беренче чиратта мәгарифне үстерүгә ярдәм итәләр, мәчетләр салдыралар (Күрәсез «урыс баеса — чиркәү сала, татар баеса — хатын ала» дигән әйтем бик үк дөреслеккә туры килми) «Җәмгыяте хәйрия» оешмалары татар мәктәпләре, гимназияләр кызлар мәктәпләре ачарга булыша, ярлы студентларга матди ярдәм күрсәтә Уфа, Петербург, Ырынбурда бу җәмгыятьләр бик актив эшли Пермь земствосы 1911 елда столярлык мәктәбе оештыра, соңрак аның укучылары Омскида күргәзмәдә катнашып, көмеш медаль

бәхетсезләр күп. Алар чарасызлыктан интегә. Татар байлары бүген дә аз түгел, ә химаячелек белән шөгыльләнүчеләр унга да тулмый... Бүгенге Апанаевлар, Юнысовлар, Рәмиевләр, Акчуриннар кайда? Әллә алар барыс тик үз кесәләрен генә калынайтамы?

Җәүдәт МИҢНУЛЛИН: Аз булса да бар андый меценатлар Хәзер шуларның берсе сезнең алда чыгыш ясар

Рәфис КАШАПОВ, Чаллы эшкуары: Бу — бик әйбәт очрашу Әмма безнең әдәбият-сәнгать әһелләренә ярдәм итүне күпләр дөрес аңламый Кашаповлар үзләрен рекламалау өчен тырыша, диләр Без «эшкуар» исеменә лаек булганчы бөтен пычраклыкны уздык хәзер дә шул халәттә яшибез Чаллы шәһәре төзелә башлагач илнең төрле якларыннан бик күп зимагурлар, бичлар килеп тулды Авылдан шәһәр тормышына кызыгып килгән егет-кызлар кагнаш никах кордылар Гореф-гадәтләребез телебез мәдәниятебез бетү куркынычы туды Шул чагында бездә милләттәшләребезгә булышу теләге уянды Баштарак без өч бертуган гына башлап йөрдек, хәзер Алабугадан да Чаллыдан да башкалар кушылды Без халкыбызның тарихын мәдәниятен чагылдырган 15 китап чыгарырга булыштык аларның тиражы өч миллионга якын Моннан тыш татар тарихын чагылдырган ике фильм безнең матди ярдәм белән төшерелде инде өченчесе әзер дияргә була Күптән түгел Уфада Жириновский белән очрашуда булырга туры килде Ул анда «Жириновский» аракысы алып килгән, президент булып сайланган очракта бушлай аракы эчечәксез дип вәгъдә итте «Татарларны чиркәүләргә куып кертергә катнаш никахта торучыларга чиратсыз факир бирергә кирәк», — дип өчынна-очына сөйләде Исереккә мәларның Бөтендөнья конгрессы булды. Шунда безнең бөтен чатаклыклар күренде дә инде бүгенге көндә кунакларга бүләк итеп бирердәй милли сувенирларыбыз да юк икән бит! Калфак түбәтәй намазлык читек кебек милли әйберләрне чигү-тегү белән санаулы һөнәрчеләр генә шөгыльләнә Җырларда җырланган Казан сөлгеләрен чигүчеләр юк бүгенге көндә Әбиләр сандыгында кадерле ядкарь итеп саклаганнары да сүсәреп беткән Кыскасы шушы һөнәрләрне халыкка кайтару юнәлешендә эшли башладык Без хәзер сәнгатьле чигүче һәм тегүчеләр әзерлибез киләчәктә тукучылар өйрәтергә дә ниятебез бар Кызларыбыз бүген түбәтәйләр калфаклар чигәргә өйрәнәләр халкыбызның рухи җәүһәрләре белән танышалар

Күн мозаика сәнгате сүнеп бара Арча фабрикасы гына чуәк читеккә каюлы чигү үрнәкләрен халыкка ирештереп бетерә алмый Без Казан җое белән күн мендәрләр паннолар сумкалар тегәбез Агачтан кисеп эшләү нечкәлекләренә укучылар 10 ай эчендә өйрәнәләр арада бик әйбәт осталар бар Бу эшләрдә безгә Татарстан Фәннәр академиясе һәм «Казан» милли мәдәни үзәге ярдәм итә «Туран» фонды белән хезмәттәшлек итәбез Хәзер безгә чит илләргә баручы бик күп кешеләр мөрәҗәгать итә дөньяга күрсәтә алырдай бүләкләр әзерләү өчен галимнәрнең киңәше ярдәме кирәк Халыкара бизнес институты каршында да гамәли сәнгать бүлеге эшли Шулай да татар сувенирларына ихтыяҗ зур Без балаларны милли сәнгатькә өйрәтүче белгечләргә дә мохтаҗ Сәйләнтезеп, алтын көмеш җеп белән чигә белүче осталар кирәк Моннан тыш керамика һәм металл белән эшләргә өйрәтергә дә исәбебез бар

Хөрмәтле кунаклар! Сездә 40 бик аз күрсәтелде юбилейның театраль тамашасында татар мохите, татар рухы чагылмады дисәң дә хата булмастыр

Конференция дәвамында татар әдәбияты теле тарихы сәнгате аның яшәеше бүгенге хәле киләчәктәге язмышы турында күбрәк ишетергә теләгән идем Мине куандырган хәбәр шул булды — татар китаплары музее булачак язучы Вакыйф Нуруллин аның концепциясен эшләгән икән Музейның татар хезмәткәрләре һаман читтә кала бирә Ә бит аларның актив эшчәнлеге бик тә кирәк Чөнки 1937-38 нче еллар террорында татар зыялыларының күбесе кырылды Бөек Ватан сугышы башлангач татар язучылары артистлар композиторлар көнбатышка фронтка китте ә украин язучылары киресенчә Башкортстанга урыс язучылары Татарстанга килеп урнаштылар Аларга музейлар ачтык ә Фатих Кәрим Нур Баян сугышта һәлак булган башка татар язучыларына дәүләт музеенда урын табылыр микән?

Бүгенге сөйләшүне алыйк Тукай музеенда урыс телендә доклад тыңлап утырабыз үзе исән булса Тукай моңа ничек карар иде икән? Шагыйрь рухы рәнҗер дип тә борчылмыйбыз Сүз уңаеннан шуны да әйтим конференциядә мин тыңлаган 32 докладның нибары 10 проценты туган телебездә укылды Ике тел дә дәүләт теле ләбаса аңламаганнар үзләренә үпкәләсен дияргә генә кала да бит!

Хәзерге дәүләт музее безнең өчен ят рухлы Безнең тарихыбыз бик озын һәм катлаулы Аның борынгы очы Алтын Урдага ук барып тоташа Безгә татар милли дәүләт музее кирәк

«Түгәрәк өстәл» янындагы сөйләшүне укучыларга
Рәсимә СИБГАТУЛЛИНА
җиткерде

Ике сугышның бер хурлыгы

«Сугыш хәрәкәтләренең Аурупа театры» дигән гыйбарә 1945 елның маенда телебездә торып калды, дисәк, дөрес булмас. Ул сүзләр бүген — XX гасыр ахырында да безнең колакка ярып керә Заманында, Аурупа жандармы. дигән яманат алган Русиянең бүген дә Аурупада барган кан коюларда төп рольне уйнавын, оят булса да, танырга туры килә. Сулар ага, заманалар үзгәрә, тик Русиянең генә империалистик. колониаль асылы тамчы да үзгәрми. ул һаман халыкара мөнәсәбәтләрдә имперacheл сәясәт тота.

Югославия җирендә — сугышлар күптән тынган Аурупада дүртенче ел инде туплар шартлый. кешеләр һәлак була. Алар арасында күпчелеге картлар, хатын-кызлар, балалар.. Кайчандыр гөрләп чәчәк атып утырган Балкан җире хәрабәгә әйләндерелгән. гомере өзелгәннәрнең саны дистә меңнәр белән исәпләнә, йөзләрчә мең кешә, гомер иткән туфрагын, яшәгән йорт-җирен ташлап, качаклар булып Аурупа буйлап сибелгән. Хәрбиләр һәм сәясәтчеләр һәрвакыттагыча дөньяны болгата, аның бөтен афәте халыклар өстенә төшә.

Бүген, Балкандагы хәл кискен үзгәргән, сербларда хәрби җиңүгә өмет сүнеп барган бер чорда, Русиянең сүз алып барырга мөмкинлек бирә. Бүген бөтен дөньяда дәүләтчелек төзүдә «Татарстан моделе» дип телгә кергән күренешнең беренче чалымнары элегрәк Босния һәм Герцеговинада да күренгән иде, бу илнең суверенитеты этник мотивларсыз — бөтен халык исеменнән (Татарстандагычарак) игълан ителгән һәм бу хәл халыкара мөнәсәбәтләрнең активлашуына китергән иде. Шулай итеп, яшь, бәйсез Босния һәм Герцеговина дәүләтләренең тыныч тәрәккыятенә нигез салынган иде.

Этник низагларның сәбәпчесе — серб ягы, бу — тарихи хакыйкать, чынлыкта сугыш хәрәкәтләрен нәкъ серб ягы башлап җибәрде. Кан коюлы сугышларның башында ачыктан-ачык һәм яшерен, астан ут йөртүче рәсми

кайбер хөкүмәт тирәсендә чуалган төркемнәре, ачыктан-ачык шовинизм сәясәтенә күчеп, халык аңына куркыныч орлыклар салалар. Күптән түгел генә Аллага да, Иблискә дә ышанмаган кешеләр бер иртәдә кинәт православный булып уяндылар һәм, шулкадәр диндар кешеләргә әйләнделәр ки, сәҗдә вакытында менә-менә маңгайларын ярырлар кебек Мондый диндарлык куркыта да, шикләндерә дә. Дингә ихлас ышанучы кешеләр гадәттә тыйнак була. Дин тоту — бик нечкә тойгылар белән бәйле Артык диндар булып күренергә тырышкан кешенең ялганы-рыясы тиз беленә. Ә бит Русиядән башка илләрдә, шөрран яра диндар булып кыланып мөгез чыгармыйлар. Шул ук Греция, Болгария, Румыния, Украинада да күпчелек халык носара динен тота, алай да Босниядәге хәлләргә бу илләр тотнаклы, аек позициядә торалар. Ни өчен соң әле Русия гадел эш йөртмәгән Босния серблары ягында? Ни өчен Русия, үзендә дистәләрчә миллион мөселманнар яшәүгә карамастан, асылда ачыктан-ачык мөселманнарга каршы позициядә тора?

Босния һәм Герцеговина күпмилләтле Югославиянең этник яктан иң чуар республикасы иде. Әле күптән түгел генә биредә милләтара толерантлык, диннәргә тигез караш хөкем сөрә иде. Балканны өйрәнүче галимнәр, сәясәтчеләр дә моны инкарь итми. Мөселманнарга килгәндә, озак дәверләр православие (носара) динендәге кешеләр белән аралашып яшәү аларда, башка мөселман дөньясыңа хас булмаганча, чит диндәгеләргә карата ихтирам һәм сабырлык сыйфатлары тәрбияләгән. Бу яктан караганда, боснияләләр һәм татарлар арасында зур охшашлык бар. Ә бу исә гомумислам дөньясында үзенчәлекле Аурупа ислам дөньясы оешкан булуы турында

Белград һәм серб президенты С.Милошевич тора. Босния сербларыннан исәпләнгән сугыш чукмарлары — генерал Р.Младич һәм Р.Караджичның чыгышлары белән Босния һәм Герцеговинага бернинди мөнәсәбәтләре юк. Бу инде күптән аксиомага әйләнгән — моноэтник тирәлектә үскән һәм яшәгән кешеләрнең милләтара мөнәсәбәтләрдә аеруча килешмәүчән булулары турындагы хакыйкатьне тагын бер кабат раслый. Бу Татарстан мисалында да ачык күренә: республикада бернинди милләтара низаглар күзәтелми. Танылган татар социологы Я.Гарипов моннан берничә ел элек Чаллы шәһәрендә тикшерүләр алып бара һәм шундый нәтиҗәгә килә. Татарстанда туып-үскән урыслар, читтән килгәннәр белән чагыштырганда, милләтара мөнәсәбәтләрдә түземлерәк, башка милләт вәкилләренә карата ихтирамлырак икән.

Босния сербларының фаҗигасе үз язмышларын Р.Караджич һәм Р.Младич кебек җинаятьчеләр кулына тапшырганнан соң башланды. Бу хәлләр турында уйланганда К.Маркның мәгълүм сүзләре искә төшә: ныклыгын бер минутка гына онытып тору да хатын-кызны бәхетсезлеккә китергән кебек, бер минутлык йомшаклык та аерым бер халык өчен һәлакәткә сәбәп булырга мөмкин. Босния һәм Герцеговинадагы халык та хәрби җинаятьчеләр гаебе белән бәхетсезлеккә төште. Республикадагы халыкның 30 процентын гына тәшкил иткән серблар хәрби авантюристлар җитәкчелегендә сугыш гарасатына ташланды һәм аз гына вакыт эчендә үзләре яшәгән төбәкнең 70 процентын яулап алды. Сербларның кансызлыгы дөньяны тетрәтте: этник чистарту, әсир мөселманнар өчен концлагерьлар, хатын-кызларны көчләүләр, гади халыкны күпләп үтерүләр гадәти хәлгә әверелде. Мисаллар — хисапсыз. Берсен генә исегезгә төшерик: БМО күзәтчеләрен серблар урамдагы фонарь баганаларына, күперләргә, диварларга бәйләп куйганнар, янәсе, БМО самолетлары ут ачса, башта үз кешеләрен һәлак итсеннәр. Сербларның вәхшилеген, кешеләрне күпләп үтерү кебек хәрби җинаятьләрне хөкем итү өчен Босния һәм Герцеговинада халыкара трибунал оештырылган иде. Хөтерем ялгышмаса, бу трибунал җинаятьче хәрби җитәкчеләргә зур гаепләр ташлады.

Соңгы вакытта Русия мәгълүмат чараларында — радио һәм телевидениедә, клирикаль гәзитләрдә мөселманнарга каршы юнәлдерелгән һәм аларны кыргыйлар, вәхшиләр итеп күрсәтергә тырышкан чыгышларны аеруча күп ишетергә һәм укырга туры килә. Ә бит шушы чыгышлар күләгәсендә мөселманнарга каршы иң вәхши җинаятьләр эшләнә! Шулай әйтергә ярса, «Сугыш хәрәкәтләренең Аурупа хәрби театрында» хәзер «икенче фронт» ачылып китте Русия Кавказда үз мөселманнарына каршы кан коюлы сугыш башлап җибәрде Сугыш ике «фронт»та да — Балканда да, Кавказда да мөселманнарга каршы алып барыла Шулай итеп, мөселман динен тоткан Аурупаның ике халкы — боснияләләр һәм чеченнар бер канлы җепкә бәйләнгән булып чыкты Бу инде Русиянең хәзерге халыкара мөнәсәбәтләренә һәм үз эчендә барган хәйләле сәясәтенә игътибар беләнрәк карауны таләп итә

Босниядәге фаҗигале хәлләр бүгенгә кадәр халыкара берлекләр тарафыннан үзагымына куелган сәясәтне тулаем чагылдыра иде Бөтен хикмәтә шунда. халыкара җавапсызлык, халыклар язмышына карата битарафлык БМО, Аурупа берлеге, НАТО башлангычларына Русиянең актив басым ясавы аркасында килеп чыкты. Русия бөтен дөнья каршында, һич оялмыйча, серб ягына дипломатик ярдәм күрсәтә торды. Ләкин... Алла бар! Ниһаять, һич көтмәгәндә бу эшләргә чик куелды Хәтерләсәгез, шушы уңайдан Русия Президенты Босниядәге уңышсызлыклары өчен Тышкы эшләр министрлыгын кырыс сүзләр әйтеп тәнкыйтьләгән иде. Русиянең чит илләр белән алып барган сәясәте бернинди кысаларга да сыймый. Бу сәясәткә, Ичкериягә корал белән бәреп кереп, сугыш башлап, Президент Ельцин үзе нигез салды Православие динен тоткан сугыш чукмарларының Кавказдагы вәхшилеге Балкандагы сербларныкыннан һич тә ким түгел һәм аларның «язу рәвешләре»дә охшаш. Шуңа күрә бүген Мәскәү Балкан вакыйгаларына борын тыга башласа, шундук Ичкерия вакыйгаларын искә төшерәләр: ник әле Мәскәү сәясәтчеләре Балканда безгә акыл сата, ә үзләре Русиянең үз халыкларын изүен, аз санлы милләтләрне канга батыруын оныталар, диләр алар.

Күргәнебезчә, сугыш туктаганга 50 ел үткәч, Аурупа дәүләтләре үз кыйтгаларында сугыш театры турында сүз алып барырга мәҗбүр, һәм хәзер дә сугыш ялкыны берьюлы ике фронтта — войнахлар республикасында һәм Балканда дөрли. Әлбәттә, Мәскәү, чечен халкы болай ук нык каршылык күрсәтер, дип көтмәгән иде Чечен халкы, шулай итеп, боснияләләрнең азатлык көрәшенә (Русия хәрби көчләренең күп өлешен үз өстенә алып) — «Икенче фронтка» ярдәм итә.

Балкандагы соңгы вакыйгалар андагы халыкларның гаделлек белән төзелгән солыхка өметен арттыра, ә Русиянең Кавказдагы һәм Балкандагы кара эшләре аның намусына кара буяу белән ягыла.

Төлгать БАРИЕВ.
Казан.

Кансызлыкның соңгы чиге

Укучылар игътибарына Босния фаҗигасен ачып бирә торган кайбер саннар тәкъдим итәм. Алар беренче тапкыр төрек матбугатында басылды. Бу мәгълүматлар Босния фаҗигасен күзәтеп, тикшереп барган халыкара Кызыл хач тәшкилатенең Загребтагы үзәге тарафыннан әзерләнгән һәм БМО Генераль секретаренең баш ярдәмчесе Христофер Сунрихт имзасы белән яшерен рәвештә БМОга җибәрелгән булган. Мин аларны Бонnda кулыма төшерә алдым. Түбәндә китерелгән саннар сугыш башланганнан бирле Босниядәге фаҗигане ачык итеп күз алдына китерә.

ҮЛГӘННӘР

Гомуми саны — 312420.
Ирләр — 184327 — 59 процент.
Хатын-кызлар — 90601 — 29 процент.
Бала-чагалар — 37490 — 12 процент.

ҮЛГӘННӘРНЕҢ МИЛЛӘТЕ

Мөселманнар — 253060 — 81 процент.
Хорват (католик) — 56235 — 18 процент
Серб (православ) — 3214 — 1 процент.

МЫСКЫЛ ИТЕЛГӘН ХАТЫННАР

Гомуми саны — 21744.
Мөселманнар — 16090 — 74 процент.
Хорватлар — 5634 — 26 процент.

ҮТЕРЕЛГӘН БАЛАЛАР САНЫ

Гомуми саны — 37490.
7-12 яшь арасы — 26061 — 71 процент.
7 яшьтән кечеләр — 14055 — 29 процент.

ГАРИП КАЛГАННАР

Гомуми саны — 49170.
Ирләр — 34910 — 71 процент.
Хатын-кызлар — 13767 — 29 процент.

ЙОРТ-ҖИРСЕЗ КАЛГАННАР

Җимерелгән йортлар саны — 48016.
Сербларга бирелгән өйләр — 29325.

КУЛЛАНЫЛГАН РИЗЫК (уртача)

Икмәк — бер кешегә бер көнгә — 41 грамм.
Ит — бер кешегә бер көнгә — 16 грамм.
Май — бер кешегә бер көнгә — 9 грамм.

ҖИМЕРЕЛГӘН ГЫЙБАДӘТХАНӘЛӘР

Мәчетләр, дәрвишләр йорты — 284.
Чиркәү һәм монастырьлар — 61

Халыкара ярдәм фондының 86 проценты сербларга җибәрелгән.

Илхан БАРДАКЧЫ.
(«Заман»).

P.S. Югарыда китерелгән чәчләрне үрә торгызырлык саннар геноцид сәясәтенең кайсы халыкка каршы алып барылуын бик ачык күрсәтеп тора. Ә менә үзебездәге Ичкерия фаҗигасе турында чын дөреслекне кайчан белербез икән? Һәм, кайчан да булса, белеп булыр микән?

ӘДӘБИЯТ МӘЗӘКЛӘРЕ

Татар әдипләре әсәрләреннән чүпләп алынган мәзәкләрдән бер жыйнама, Тукай сүзләре белән әйтсәк, бер көлтә итеп мин «Ватаным Татарстан» гәзитәсендә чыгарган идем. Мондый жыйнамаларның укучыны елмайту, күңелен күтәрүдән тыш, туган әдәбиятыбызны пропагандалаулагы әһәмиятен күздә тотып, мин «Әдәбият мәзәкләре»нең тагын бер жыйнамасын газетага гәкъдим итәргә булдым...

Ибраһим НУРУЛЛИН.

...бдулла Тукайның «Егет ...ыз» исемле шаян шигыре ...мена диген мәзәк.

...әям чүмеч кеби борныңны,
жаным,
...к булдым,
тәмам бетте мәжалым*

...ашым, аһ,
иләк аузыңны үпсәм!
...гы,
...инде мин шул чакта үлсәм.

...әхәббәтсез!
...лыгырдый шунда жукны,
...илмәгән жир
бер дә жукмы?

...чуланмасана,
Гайниҗамалым,
...ин кимсетеп әйтмим лә,
жаным.

...ең тесле матур
кызлар сирәк бит,
...алсаң,
иләк, чүмеч кирәк бит.

...е алсам,
чүмечле һәм иләкле
...ич —
... акча туздырмак кирәкми.

...яз Исхакыйның «Башкорт ...» хикәясеннән.

...яне сөйләүче «мин» (автор дисәк тә ярый) күрше авылга барыр өчен атлы кеше эзләгәндә, бер башкорт агае «Атым яхшы, арбам тимерле», дип үзен тәкъдим итә. Чыгып китәләр Башкортның аты өшенгән, арбасының тәгәрмәчләре квадрат ук булып җитмәсәләр дә, түгәрәклекләрен күптән инде югалтканнар Барып җиткәч, автор башкортны шелтәләп алудан тыелып кала алмый:

— Атым яхшы. арбам тимерле, дигән идең ич, ник алдадың?

Башкорт агае бик үк коелып төшмичә генә җавап бирә.

— Ник алдаем? Тимерле шул, күрмисеңмени? — дип, кешә киемен ерту хезмәтен үти торган кечкенә генә кабык кадагына төртеп күрсәтте.

3. Шәриф Камалның «Матур туганда» романыннан.

Коммунарлар җөйлектә Үрге әрәмәлек дигән гаҗәеп матур урынга күчеп, алачыклар корып торырга карар итәләр

Менә бер көнне алар, атларга төяләп, юлга чыгалар Арттагы арбага утырган Нәсимә бөтен авыл ишетерлек дәрәҗәдә тиргәнеп, сукранып бара. «Бу каһәр суккан Мостафа башларыбызны әллә кая илтеп адаштыра инде... Әй, Ходаем. үземнең җылы өемә кайтып керер көнем булыр микән?»

Улы Закир аны туктатырга тырыша

— Җитәр инде, әнкәй, (...) күчәсең килми икән, өйдә генә калу кирәк иде

— Ай. Алла! Синең белән сөйләшмиләр ич! (...) Әллә инде эчемнең ярсуларын бушатудан аталы-уллы тыймакчы буласыз! (...)

— Бушат, бушат анасы, — диде Халикъ. — эчеңне бушатып бетер, атка да җиңелрәк булыр

4. Салих Батталның «Балаң булса бик иркә, бу аны кая илтә» исемле көлкеле шигыреннән.

Бер ир белән хатын, уллары тугач, аңа Тансык дигән исем кушып, чамадан тыш иркәләп үстерәләр Менә бер вакыт солдатка китәсе малайны атасы мунчага алып бара, башын юа. Үзе кайгыра:

— Кем күлмәк кидерер анда,
Кем юар башын... —
Һәм тазга су урынына карт
агызды яшен.
— Улама! — диде Тансыгы, —
Тукта, дидемме,
акырма! Юкса юдыртмам
башка җиремне.

*Мәжал — көч, тәкать.

Матбугатка
Розалина НУРУЛЛИНА
әзерләде.

● — «Мәдәни җомга»га язылсак, ел буе тамагыбыз тук булыр, иншалла. Үзе арзан, үзе калын вә туклыклы дип сөйлиләр ич аны...

Көлсәң — көл, көлмәсәң — ела!

Кайда син, назлы ярым?..

Пасквиль

...гыйлдә тормыш: буйдак ...ирсез хатыннар үзләре те...назлы ярларын, өйләрен...нга кырын ятып, урынна... кузгалмыйча да таба ... Моның өчен гәҗитләргә ...шлау да җитә. Анда хәзер ... таныштыру белдерүләре ... Аларның кайбер үрнәк...без сезнең игътибарга тә...итәргә булдык, кем белә, ...ярап куярлар.

...техник белемле, торагы бар, ... хатын (47-167-70) исерткеч ...ергә битараф карый торган ...ькә кадәрге, буе 170 сантиме... булмаган әдәпле ир белән ...гә тели.

...ы чиксез зыялы, үтә кеше...агатьле ир белән, буе 169 ...ртына икән, танышырга телә... чыга.

• • •

...ст күзле, зифа буйлы, кыска ...гары белемле, сөйкемле чи... (37-178-55)...

... яше инде кырыкка якынла... 180 сантиметр чамасы, кыс...колга, сөйкемле булса да, ...кемне генә кызыктырыр ...е озын, акылы кыска, ди...ән Әмма кыска чәчле хатын...ыллары белән әлләни мак...лар бит.

• • •

...ек, буе 175 сантиметрлы ...лыгы, зифалыгы белән үзе...итә торган кызны очратырга ... Аның турында кайбер мәгъ... Көнчыгыш көрәшләре һәм ...ән кызыксына, киногa, теат...ркка йөри, чит телләр өй...әктә ниндидер музыка ко...йнарга өйрәнгәч, үз җырла...рга исәп тота.

... шундый шәп, перспектива...әлектәрә алсагыз, үкенмәс...белә, бәлки, Алла кушып, ... чит телләр дә өйрәнерсез, ... дә, җырларсыз да, егет ...улып чыкса, алдануыгызга гарьләнеп, еларга да вакытыгыз калыр.

• • •

Үземә кордаш, фатирлы, ялгыз мөселман хатыны эзлим. Мин (48-163-67) — Көҗәмәгез, югары белемле, матди хәлем бирүгә дә бәйле түгел, күчеп китәргә дә риза.

Кыскасы, ярты гасыр чамасы гомер сөреп, тамыр җибәрергә өлгермәдем, җил кайсы якка өрсә, шул якка бөгелергә әзер бәндә мин; дигән сүзләр генә юк бу белдерүдә.

• • •

Ахирәтемнең яше 30дан чак кына өстә. Ул — югары белемле педагог, ирдән аерылган, кызына 8 яшь. Бәлки, алар сезгә бүгенге көндә иң кирәкле кешеләрдер? Ахирәтемә хат языгыз, ул сезне кызыксындырган барлык сорауларга үзе җавап бирер.

Кызык һәм тыйнак белдерү бу Юк, белдерү түгел, табышмак. Дус хатыны ахирәтенең буен да, авырлыгын да әйтмәгән; чәченең нинди төстә икәнен дә, чибәрлеген дә телгә алмаган. Әйбәт белдерү, аның күпләрнең игътибарын җәлеп итүе мөмкин.

• • •

Мин югары белемле тол хатын (50-162-70), игелекле, тыныч холыклымын, тормышка реаль карыйм, кышын чаңгыда йөрергә яратам, җәем дачада үтә. 65 яшьләрдәге эчми торган әдәпле ир белән танышырга телим. Өйләнешүебез дә ихтимал.

Бу ханымга кышын чаңгыда йөрергә иптәш, җәен дачасында эшләргә хезмәтче кирәк. күрәсең...

• • •

Холкым шәфкатьле, йомшак, балалар яратам, спортчы, кыяфәтем кемгәдә ошарлык, 25тә, әмма яшьрәк күренәм, буем 165 сантиметр. Төрмәдә утырам, ирекә фатирым бар. Минә аңларга сәләтле хатын-кызның хатын һәм фоторәсемен көтәм.

Ирекдәге фатирының күпме ятим торасын йомшак холыклы бу бәндә язуны кирәк тапмаган, фатирсыз уразыны кирәк тапмаган... фатирсыз ура-язуны кирәк тапмаган, фатирсыз уразаклар йөргән берәр чибәр, күпме генә утырса да, үзен көтәр дигәндер инде Алла йоклаганда шайтан күпме телисә шулкадәр шуклана, диләр бит Җибәрегез аңа, кызлар, фотогызны, бәлки, ошатыр

• • •

Үгезбозау (27-168), татар, матур да, ямьсез дә түгелмен, тартмыйм, эчмим, кинә тотучан түгел, югары белемле квалификацияле эшче, өйдә утырырга, китаплар актарырга яратам 30 яшьләр тирәсендәге (физик кимчелексез, 2 яшьлек баласы булуга да каршы түгел), фатирлы, әдәпле, тугры хатын белән гаилә корырга телим

Бу югары белемле, өйдә утырырга яратучы, кинә тотмаучы иптәшнең нияте изге күренә Эчми дә, тартмый да, фәрештә дә фәрештә — ул да. Тик фатиры гына юк Төсе-бите әллә кем түгел икән түгелен. Зарар юк, төс-бит су эчәр өчен түгел, диләр бугай.

• • •

Офицер намусын, гыйшык-гыйшрәтне, тугрылыкны изге санасагыз, яшегез 25-30 тирәләрә булса һәм гаиләгә ышанычлы терәк хезмәте үтәргә хәзер торсагыз, сезне 2 яшьлек кызы белән рәхим-шәфкатьле, киң күңелле, мөлаем парыгыз көтә. Безне тормыш мәшәкатьләре куркытмый, бары кабахәтлекне, хәсислекне яңадан да очратасыбыз килми Безнең мал-мөлкәтебез юк, авыр минутларны да, шатлыклы мизгелләрне дә уртаклашырлык рухи байлыгыбыз гына бар.

Гади белдерү-чакыру гына түгел, авызны яңадан пешермәс өчен салкын суны да өреп кабарга омтылу бу

• • •

Акылы камил 78 яшьлек хуҗабикә бөтен калган гомерен иңгә-иң торып үткәрерлек ир очратырга хыяллана.

Бик хуп, бер яшьлектә, бер картлыкта, дип тикмәгә әйтмәгәннәр Уңыш телик әбигә, бирсен Ходай Бәхетсезләр бәхет, парсызлар пар эзли, бәхетлеләр бәхетеннән бизми, тормыш тукталмый, дәвам итә.

Гурий ТАВЛИН.

Мәгъсүм НАСЫЙБУЛЛИН

Төпсез кое

(Маҗаралы кыйсса)

Көннәрнең берендә тикшерүче бүлмәсенә сөмсере коелган бер егет килеп керде. Паспортын күрсәтеп, үзен Николай Заволжин дип таныштырды.

— Әнине югалттык, — дип башлады ул сүзен. — Галина Заволжинаны.

— Ничек? — дидем мин, аптырап. — Аңлап җиткермим.

— Үзебез дә белмибез. Мин өйдә юк идем. Күршебез Анна Александрова кереп: «Галя, сыерымны карап чыкмассыңмы? Бу арада нишләптер сөте кимеде», — дигән. Күрше чакыргач, ничек кермисең инде. Күрше хакы — Тәңре хакы, диләр бит. Мал-туарга ул-бу булганда гына түгел, бала-чага, хатын-кыз чирләгәндә дә әнине чакыралар. Төрле үлән белән дәвалый белә ул. Бу юлы да, иңенә бушлат салып, башына шәл бөркәнгән дә Анна Александроваларга кереп киткән.

Бераздан Анна Александрова кабаттан әйләнеп кергән:

— Галя кайда? — дип сораган.

— Бая гына синең белән чыгып китте ич. Нигә миннән сорыйсың аны? — дигән үги әтием.

— Бездән шундук кире чыгып китте ул. Ун минут та үтмәгәндер, — дигән күршебез. — Басуга, шифалы үләннәр алып кайтырга барам дигән иде...

— Бетмәде инде шул үләннәрегез, — дип ачуланган әти. — Урам саен — даруханә, чирле кеше саен — бер табиб. Ә сезгә — үлән дә үлән..

Көн кичкә авышкач, мин кайттым. Әтигә эшкә китәргә кирәк иде. Ул күршеләргә дә кереп чыкты... Ә әни юк та юк. Төн узды. Таң атты. Икенче көн дә үтеп китте. Әни һаман кайтмады. Аптырагач, таныш-белешләрне, больница-вокзалларны йөреп чыктым. «Әтинең кулы уйнамады микән?» — дип тә шикләнә башладым. Әнинең зарланганы булмады булуын. Шулай да кем белә? Кеше күңеле кешегә караңгы. Җитмәсә, әти эчүгә сабышты. Шигем көчәя төште. Менә аптырап килдем инде...

Яңа «эш» шулай башланып китте.

Күрше район хастаханәләреннән, тимер юл станцияләреннән, аэропортлардан белешмә алынды. Дружиначылар аякка басты. Алар урамнарны әйләнделәр, елга-күлләрне тикшерделәр.

Тора-бара Чувашстаннан: «Бер хатын-кыз мәете табылды», — дигән хәбәр килде. Шуннан соң ук: «Мәетнең кем булуы ачыкланды», — дип икенче телеграмма суктылар... Без эзләгән кеше түгел иде.

«Галина Заволжина кулга алынмаганмы?» дигән сорауга да, «Юк» дигән җавап алынды.

Бәлки, кая да булса киткәндер? Тик аның кая китүе мөмкин?

— Әни Ульян өлкәсенең Мәләкәс районында туган. Китсә, шунда китәр, — диде Николай. — Самара өлкәсендә дә туганнарыбыз бар.

— Тагын?

— Башка барыр җире юк.

— Үз әтиегез кайда?

— Әти вафат. Әни белән бер авылдан алар.

— Ә үги әтиегез?

— Үги әтинең беренчесе үлде. Шушы Сиртмәле кешесе иде. Монысы — икенчесе. Василий Зорин. Мин армиядә чакны тора башлаганнар. Кайтканыма күп түгел, аның нинди кеше икәнен юньләп белмим. Мари республикасыннан булса кирәк.

Нәрсә генә уйламыйсың мондый чакта! Эзләүнең яңа юнәлешләре чыгып торды:

— Заволжиннарның да, Александровларның да бөтен җирен тикшерергә кирәк. Йорт, сарай, чардак, баз, бакча — барысын да карагыз. Берни калмасын! Кеше тиклем кешенең эзсез юкка чыгуы мөмкин түгел. Мичләрен, көл түккән урыннарын тикшерегез. Тоймәдер, сояктер, кием-салымдыр... Шуларның калдыгы юкмы? — дип фәрман бирдем.

Тикшереп кайттылар.

— Шикләнерлек бернәрсә дә табылмады, — диде Заволжиннарда тентү үткәргән милиция офицеры.

— Бездә дә игътибарга алырдай берни юк, — диде Александровлар ихатасын тикшергән инспектор.

Бистәдәге, күрше авыллардагы зиратларны карадык. Җавап һаман бер төрле иде — юк.

Мәет юк, бармак белән тотардай җеп очы да юк. Җир упкан диярсең!

Беркөнне мине прокурор чакырып алды.

— Нинди уңышлар белән котларга кушасыз? — дип каршылады ул.

— Яшерен-батырын түгел, эш комга терәлде, — дидем мин.

— Сездән мондый сүзне ишетергә туры килгәне юк иде әле.

— Юк иде дә, нишлисең бит! Адәм баласы бернинди эзсез юкка чыккан дип әйтсәләр, үзем дә ышанмас идем.

— Бер генә төпле юрама да юкмыни? Бер ай вакыт үтте бит инде. — Күрәм, прокурор борчыла.

— Әгәр мәете табылса... — дидем, теләр-теләмәс кенә.

— Заволжинаны үле дип уйлыйсызмыни? — дип эләктереп алды прокурор. — Дәлилләрегез кайда?

— Алай дип әйтә алмыйм, күп нәрсә ачык түгел әле.

— Заволжина яшәгән мохитне җентекләп өйрәнергә, ул аралашкан кешеләр белән яңабаштан танышырга кирәк.

Эзе-мазары күренмәгән серле «эш» тәгәлмәсе калыная барды. Җинаятьме, түгелме — һаман билгесез. Бәлки, җинаятьтер. Ләкин эзе калмаган бер генә җинаятьнең дә булуы мөмкин түгел бит. Медицинаның хирургия, рентгенологиясе булган кебек юстициянең дә криминалистикасы бар. «Эз калырга һәм булырга тиеш!» — дип өйрәтә ул фән. Бөтен хикмәт — аны таба белүдә, табуда. Кайда соң ул эз? Ничек яшерелгән? Аның яшерелүе — бәхәссез. Димәк, ул табылырга тиеш! Моңа кадәр табылмаган икән, эзләүдә ниндидер җитди җитешсезлек бар. Димәк, тагын да уйланырга, фәнгә таянып шул ялгыш йомшак урынны табарга кирәк. Кайчак тикшерү эшендә вакыйганың үзе белән мавыгып, җинаятьчене онытып җибәрү гадәте бар. Ә җинаятьче тикшерүчеләрне бер генә минутка да онытмый. Ул һәрвакыт уяу, һәрвакыт хәрәкәттә. Үз эзен тагын да ныграк яшерергә, тизрәк җуярга ашыга. Тикшерүче югалткан һәр көн җинаятьчегә көч бирә, уйлап эш итәргә мөмкинлек тудыра. Тикшерүче «Куян эзе дә аю өненә алып бара» дигән мәкаль белән эш итсә, җинаятьче исә эзне эз белән бутамакчы, чуалтмакчы була. Тикшерүне юлдан яздыру өчен төрле хәйлә кора, чын дәлилләрне юкка чыгарып, ялганнарын булдыра. Ләкин бер дәлилне бетерәм дип, үзе дә сизмәстән, икенчесен өстәп куя. Иске эзен себергәндә яңасын калдыра.

Монда да шулай булды. Көтмәгәндә-уйламаганда җинаятьче үзен сиздермәсенме! Рухы, нервлары түзмәгән, күрәсең. Мондый яшертен алышта да сабырлык саклый белергә кирәк икән шул. Көндәлек почта белән милициягә берничә хат китергәннәр. Шуның берсе бик сәер тоелган. Шунысын миңа бирделәр.

— Менә, Гайнан Ибраһимович, карагыз әле.

Ак конверт. Сул ягында рәсем: ромашка белән күкчәчәк бәйләме. Уң як яртысында адрес: «Сиртмәле бистәсе. Милиция». Аста: «Сектадан» диелгән. Адресы да, хаттагы сүзләр дә бик үзенчәлекле: «Заволжинаны безнең секта алды. Башкаларны куркытмагыз», — дип, басма хәрефләрне кисеп, келәй белән дәфтәр битенә ябыштырганнар.

Конвертны җентекләп карап чыктым. Хатның Сиртмәле бистәсеннән салынганлыгы мәгълүм булды.

Икенче көнне тагын бер хат килде. Яңа елга карата чыгарылган рәсемле конверт: кечкенә малай, өлмәеп, чыршы белән бүләкләр күтәреп килә. Бу хатның эчтәлеге беренчесен тулыландыра төште: «Заволжинаны безнең секта алды. Гәүдәсен күмдек. Бәйрәм итте. Кан кирәк булды. Моны старостa Прокоп хәбәр итә. Моңа беркем дә гаепле түгел. Безнең сектабызның дине шундый». Хатның монысы Ульян өлкәсе Мәләкәс шәһәреннән җибәрелгән иде.

Хатлар Заволжинаның үтерелгәнен хәбәр итә.

Яңа юрама, яңа бурычлар калкып чыкты. Милиция хезмәткәрләренә дә, миңа да кабаттан җиң сызганырга туры килде. Үземә дә, ярдәмчеләремә дә эш бүлеп, пүнәтәйләр ияртеп, Заволжиннар йортына киттем. Тентү башладык һәм, озак та үтми, өстәл тартмасыннан беренче хатныкы төсле үк конверт таптык. Сул ягында — шул ук ромашка белән күкчәчәк.

— Мондый конвертны сатып алганым да, күргәнем дә юк, — дип аптырашка калды Николай Заволжин.

— Беренче күрүем, — дип, аның сүзен Василий Зорин да җөпләде. — Бәлки, Галя күршеләрдән алып чыккандыр.

— Булмас, өткәй! — дип каршы килде Николай. — Кая язсын ди ул! Белеме дә җиде сыйныф кына иде. Кичке мәктәптә укыялында — техникум, ин... Әнисе һәм үги атасы белән а... ры яхшы булган.

— Әнинең юк-барга ыш... белә идем, — дип сөйләде у... ңа. — Гадәттә, безгә хать... карчык-корчыклар еш кил... Әни им-том белән кайнашт... катнашмадым.

— Беләсезме, юк-барга ы... чылар турында инглиз фило... Джон Толанд нәрсә дигән?

— Белмим, укырга туры к... де.

— Кызганыч. Югыйсә, се... егезнең им-том белән шөгь... нүенә битараф калмас иде...

— Нәрсә дигән соң ул?

— «Юк-барга ышанучыга ... дә дә, төшендә дә тынгы ю... бәхетле түгел, тыныч кына у... мый», — дигән.

— Шәп әйтелгән, — диде ... лай. — Соңгы сүзләрен исәп... маганда... Хәер, безнең әни... анысы да хактыр...

— Анысын тикшерербез...

Василий Зорин Сиртмәлег... ел элек килгән, фабрикага ... урнашкан, башта абыйлар... яшәгән. Алты айдан соң, Г... Заволжинага йортка кергән ... надан ун яшькә кече. Ләкин ... аермасына карап, мөнәсәбә... бозылмаган булса кирәк ... — дүрт сыйныф белемле, т... те белән тыныч холыклы, аз с... кеше. Тавыш күтәрсә дә, с... кан чагы булмаган.

бит аның.

— Берни дә әйтә алмыйм, — дип гаҗәпләнде күршеләре Анна Александрова да. — Бездә мондый конвертның булганы юк.

Ул хаклы иде. Александровларда икенче тапкыр тентү үткәргән ярдәмчеләр дә кайтып җитте.

— Шикләнерлек бер нәрсә дә юк, — дип беркетмә суздылар.

«Сиртмәле бистәсеннән милициягә җибәрелгән хатның конверты белән Заволжиннардан табылган буш конверт бер үк клишедан басылган» — фән белгечләре — экспертларның сүзе катгый иде.

Хакыйкать — якында гына, сер менә-менә ачылыр кебек. Мин тагын хөкем экспертизасы билгеләдем. Бу юлы Василий Зорин белән Николай Заволжинның, ирле-хатынлы Александровларның кулъязма үрнәкләре алынды. Хәлбуки, имзасыз хатлар кулдан язылмаганлыктан, экспертиза бернинди нәтиҗә ясый алмады.

Шулай итеп, бу җеп тә өзелде. Бер сүстән аркан ишеп булмаган шикелле, ике имзасыз хат белән генә серле вакыйганы ачып булмады. Тик шулай да тикшерүченең ярты юлда тукталып, кыенлык алдында чигенергә хакы юк. Заволжина яшәгән, аралашкан кешеләрне биш бармагым кебек белмичә торып, алга атлау мөмкин түгел иде.

Аларның беренчесе — Заволжинаның улы Николай. Аңа егерме дүрт яшь. Армиядән кайткач, ремонт төзелеш оешмасына балта остасы булып урнашкан. Әйбәт

— Әйбәт яшәдек, — диде у... дә. — Ләкин яшермим, бер та... суктым. Әлеге шул гадәте ар... нда булды: китә дә бата, б... дөньясын оныта, вакытында ... рмын-эчәрмен димә. Им-том ... дип йөрде дә йөрде. Шуннан ... мәдем...

— Ә нишләп болай кинәт ю... ды соң ул?

— Үзем дә аптырыйм.

— Эчәсезме?

— Кайгыңнан эчү түгел, ... нишләрсең. Кешеләр бүре ши... ле карый, арттан пышылда... калалар. Бер очы чыксын иде... де. Туйдым бу хәлдән. Никола... читләшә башлады...

— Күрше Александровлар... лән ничек яшәдегез?

— Әйбәт яшәдек. Пешкен-... көне бергә булды. Анна хәзе... бездән чыкмый. Безнең к... — аның кайгысы.

— Тамактан аш үтми башла... инде, — дип зарланды минем ... шыда утырган Александро... — Авыр шул ахирәт дусыңны ... лтулары...

— Ә ничек булды соң ул? — ... бүлдердем үзен.

— Кешеләргә сөт сатка... идем. Зарлана башладылар, ... натсаң, эри, диләр. Аптыра... моны бер карчыкка әйттем. «Г... ха алдыннан мин дә Заволжи... сөт биргән идем, икенче көнн... сыерымның сөте зәп-зәңгәр ... ды, каймагы качты», — дип ... ләде. Шуннан ул карчык ике... бер таныш хатыны янына ба... Ул танышы Заволжина белән ... авылдан икән. «Галя янына б...

...егыл, каймагыңны кайтар-
...оны ул гына эшли ала»,
...ен теге хатын Шуннан соң
...булган дисезме? Килгән те-
...рчык Галя янына, ялын-
...арган. Галя. аларга барып,
...арын өшкергән Икенче
...ук сыерның сөте куерган
...е Заволжинага сөт биргән
...Күрше бит, бирдем Минем
...ым бозылды Аптырый ка-
...Кылт итеп теге карчыкның
...ске төште Галяга йөгереп
...м, аның эшедер, дип уйла-
...Кердә Тозлы су өзерләде,
...ер укыды, шуннан сыерга
...де «Сөте җил белән киткән,
...уы кыен, изге үлән кирәк».
...е Шуны эзләп кырга китте
...Хәзер кайда соң ул? — дип
...ым мин туп-туры.
...ер Ходай белә, — диде Ан-
...үвәлгечә тып-тыныч кына.
...сәң дә гөнаһ, әйтмәсәң дә
...Василий Зориндыр дигән
...и. Көн саен эчә. Юкка түге-
...ля югалганның икенче кө-
...ни гене сөйләп бетермәде!
...п исерек иде. Әллә сөйлә-
...икән?
...Сөйләгез, Анна апа, сөйлә-
...

...Сүгенүе гене бер хәл әле.
...анына олаксын,— ди,— бү-
...екккән икән, иртәгә икен-
...ләнәм», ди Шундый сүзне
...ер икән ир кеше! Денсез
...й иде мескенне... Күреп то-
...хатын кешә мин, нишли
...Сизеп йөрсәм дә, түздем

Өенә кайтса, сараенда яисә бакчасында эшләп төм таба. Мул яши

Анна, егерме ике яшендә Александровка кияүгә чыккач, эшен ташлаган. Һәм менә унөч ел инде бөтен күңеле үз йорт-җирендә генә Бөтен уй-хәсрәте белән сөйләгәне — сыер да дуңгыз, тавык та бакча Ул да, Галина Заволжина кебек, им-том белән шөгыльләнгән Күршесеннән аермалы буларак, Анна Александрова кешеләрне «дәвалаган»...

«Күршеләре берәр нәрсә күрмәгәнме?» — дигән сорау туды

— Заволжина югалган көнне Александровларга ике мәртәбә кердем — диде бер күршесе — Өйләре йозаклы, этләре сарай ягына карап өрә иде Мин кычкырганны ишеткәч, Анна абзар тәрәзәсеннән башын тыгып, соңрак керерсең дигәнне аңлатып ымлады Тагын кердем Бу юлы да өйдә юк иде Аптырап калдым Башка вакытта алай булганы юк иде

Менә шулай, берәмтекләп-бөртекләп Заволжина югалган көннең вакыйгаларын яңадан гәүдәләндердем. Нигәдер Александрова борчулы булган, үзен гадәттәгечә тотмаган. Икесе дә имче, шул сәбәпле алар арасында яшертен дошманлык, көнчелек яшәп килмәде микән? Боларны исәпкә алмый мөмкин түгел, ләкин моның өчен тагын да тикшерергә, эзләнергә, кире каккысыз дәлилләр табарга кирәк иде «Кара аны,

...Галя да түзде
...сыерыгызны дәвалаганда
...өйдә идемә? — дип тагын
...у кыстырдым. Әйбәт кенә
...ән әңгәмәне төки боздым
...ага сорау ошамады.
...к, эште иде, — диде ул
...ына. Һәм әңгәмәгә нокта

...чакыртырга туры килде.
...сәгать дүрттән соң гына
...,— диде Александров.
...шлый икмәк алдым Кап-
...рүем булды, Анна йөге-
...ы да пыр тузына башла-
...ап кына тор Ачуланып,
...ып киттем. Абыйларда
...Заволжина турында бер-
...елмим Хатыннар эшенә
...торган гадәтем юк Болай
...кать баштан ашкан.
...минем каршымда хәстәр-
...р утыра иде Үзләренең
...ары бар Биек коймалы
...ихата, сарай-абзарлар,
...җимеш бакчасы Сыер,
...гыз асрыйлар, кош-корт
...р Усал эт тоталар
...к-муллык ташып торса
...шлары китек. Ходай Тә-
...ра бала бирмәгән Сирт-
...Аннаның әнисе, бер сең-
...е ир туганы яши Сирәк,
...н бәйрәмгә генә очраша-
...е белән артык аралаш-
...ләренчә бертөрле тор-
...ләр. Өйләрендә телеви-
...радио да, китап та юк.
...ә православие диненә
...

...андров — шофер, бергә
...иптәшләре белән очра-
...л ачуларга катнашмый.

Гайнан! Кеше язмышы белән шаярма!» — дип кисәтеп куйдым үземнә

Тагын тентү үткәрергәме?.. Ике тапкыр үткәрдек бит инде Бер генә кан табы да, бер генә чәч бөртеге дә табылмады...

Келт итеп, башыма яңа уй килде

Ун минуттан Александровларда тентү ясаган лейтенант минем алда утыра иде

— Тентүне сез үткәргән идегез бит? — дип ягымлы каршыладым егетне.

— Әйе, — диде лейтенант, яшьләргә хас тәвәккәллек белән. — Икесен дә...

— Җентекләпме?

— Җентекләп, әлбәттә

— Бар җирне дә тентедегезме?

— Идән асларын, базларын, абзарларын, бакчаларын казып бетердек, — диде лейтенант — Тикшермәгән җир калмады.

— Шулай булса да, тагын бер барып әйләник әле, — дип, лейтенантны үзем белән алып киттем Үзем атлыйм, ә күңелдә — тирән борчылу Аркага чыбыркы белән суккан кебек «Кешеләрне җәберлисең бит! Күрше булган өчен генә — өченче тентү! Закон синең өчен дә бар бит! Үз өстеңә нинди җаваплылык аласың бит Борыл кире, Гайнан, борыл!» Күңел шулай ди, ә аякларым, чылбырдан ычкынган кебек, буйсынмый, һаман атлый да атлый

Милиция лейтенанты — күптән түгел махсус мәктәп бетереп килгән егет — ул да миннән калышмый Үз өстенә төшкән бурычны намус белән үтәгән кеше бераз аптырый булса кирәк «Нинди ышанмас кеше булды бу тикшерүче?» — дип уйлыйдыр мөгаен

Пүнәтәйләр ияртеп Александровлар капкасыннан кердек Капка ачык, этләре бәйдә иде Иркен, яңа йорт Керү белән, уң якта — җимеш бакчасы

Өй баскычына чибәр генә хатын чыгып басты Мин шаһит итеп сорау алган Анна иде бу Ул оялгандай булды безне күргәч, битләренә алсулык йөгерде

— Өйгә үтегез! — диде ул безгә, мөлаем гына елмаеп

— Рәхмәт! Без ишек алларын, бакчаларны карап чыгарга уйлаган идек

— Ярар — диде ул һәм теләр-теләмәс кенә баскычтан төште

Сарайларны, абзарларны карап, бәрәңге бакчасына кердек. Өелеп куйган тирес янына тукталуым булды, лейтенант аңлап алды

— Җентекләп карадык, — дип пышылдады ул миңа якынаеп.

— Афәрин ә мунчаны карадыгызмы? — дидем алдагы өр-яңа корылмага ымлап

— Кереп чыктык, — диде лейтенант

— Идәнен алдыгызмы, астагы җирен казыдыгызмы? — Тикшерү өчен болар да зарур иде

— Юк, — диде егет ачыктан-ачык

«Белемне тәҗрибә белән дә тулыландырырга кирәк шул Мунчаны яңадан тикшерергә!» — дип күңелемә беркеттем

Зур иркен җимеш бакчасы Эче тулы алмагач карлыган кура җиләге чия агачы иде Әйләнәсе биек койма Алмагачлар арасына кереп киттем дә күршеләрнең коймасына терәлеп торган коё янына килеп туктадым

— Карадыгызмы?

— Юк беренче күрүем. — дип лейтенант кызарына төште

Кешеләр барында «ачык авыз», «йоклаган карга» икәнлегеңне әйтмәдем инде Тикшерү чемоданыннан кирәк әйберләрне чыгарып, чиләк чылбырына тотындым Тиз генә үлчәп алдык коеның тирәнлеге җиде метр суы ике метр иде.

— Суын эчәсезме? — дип янымда басып торган хуҗабикәдән сорадым

— Менә тагын! — Анна Александрова аптырап калды — Әлбәттә, эчәбез

— Суыгыз тәмле микән? — дип, мин коедан су ала башладым

Тулы чиләкнең коедан күренүе булды, Анна Александрова кулындагы кружкасын чумдырып алды да, голт-голт итеп күз ачып йомганчы эчеп тә бетерде Ком чүлләрендә сусаган диярсең.

— Мин дә сусаган идем, — дип әйтергә өлгермәдем, лейтенант кружканы миңа сузды

Борынга ниндидер ис килеп бәрелде Кружканы якынайтканда көчәя ераклатсаң — кими Лейтенант бернәрсә дә аңламый Тәмәке тарткан кешенең борынына дегет чиләге ассаң да сизми торгандыр инде ул Димәк, су сасы таныш булмаган сасы ис.

Миңа бу яңалык җепнең очы булып тоелды Мин аңа ике куллап ябыштым

Ике шешә сорап, чиләктәге суны тутырдым. бөкеләп, сургучлап, мөһеремне салдым Биологик экспертизага кирәк булачагын яхшы беләм Александрованың исе китми Элеккечә янымда күбәләктәй бөтерелеп йөри Йә йөгереп буш шешә китерә йә аркан алып килә Берни дә булмаган, берни дә юк — тентү дә юк, су да сасымаган, — кара болыт кебек, өстенә төшкән шик тә көефен кыра алмый иде «Нәрсә кирәк?» — дип. авыздан чыгачак сүзне тартып алырга әзер тора.

Арканга тотынып, чиләккә атланып утырдым да, әкрен генә коега төшеп киттем Кулымда — багор Сасы ис монда да бар Карангы — бернәрсә юк Коеның дүрт стенасы көзге кебек тыныч суы, баш өстендә дүрт почмаклы кысада зәңгәр һавасы Багор белән төрткәлим Ташка гына бәрелеп

чыңлыи

«Күтәрегез!» дигән сигналны белдерәм

«Суын суыртырга, ташларын чыгарырга», — дигән карарга килем

Тиздән ике янгын машинасының моторлары гүләргә тотынды Насостан тынчыган болганчык су агыла башлады...

Коеның суы беткәч аска лейтенант төшеп китте Өскә таш тутырган капчыклар күтәрелә башлады Коеның чыгыры елыймыни — шыгыр-шыгыр килә Капчык артыннан капчык Барысы уналты капчык таш чыгарылып, коё янында кечерәк тау хасил булды

Унҗиденче булып коедан мәет килеп чыкты Гәүдәсе иске капчыкка төрелгән биленә сигез килограммлы гер бәйләнгән иде Шаһитлар һәм пүнәтәйләр мәетнең Галина Заволжина икәнен әйттеләр

Медицина белгечләренең сүзе кыска булды «Мәрхүмә берничә тапкыр арттан башына сугу нәтиҗәсендә үлгән Суга үлгәннән соң салынган»

Анна Александрова, тотылуына карамастан ачылырга теләмәде

— Үзе гаепле — диде — Сыерны караганнан. соң, стрихинлы шприц сорап алды да үзенә укол ясады Агуланып үлде ул ..

Экспертиза бу сүзләрнең ялган булуын исбат итте

— Сугыштык, — дип башта әйткәннәрен ул тагын үзгәртте — Беренче булып Галя үзе ташланды

Гаепле кешене тыштан нинди батыр күренергә тырышмасын һәрвакыт курку биләгән була. Бу аның тынычлыгын җуя үзенең каршылыклы сүзләре аркасында буталып калырга мәҗбүр итә Бу хәлгә төшкән җинаятьчегә эчке җиңеллек китергән бердәнбер нәрсә — кылган эше турында дөресен сөйләп бирү

Кире каккысыз дәлилләр белән уратып алгач Александрова гаебен танымый булдыра алмады Таныды һәм өстеннән тау төшкән шикелле җиңел сулап туганнарына хат язар өчен миннән кәгазь, каләм сорап алды

«Мин дөресен сөйләп бирдем — дип башлады ул хатны — Шулай карар иттем Ялганлап үз хурлыгыма түзәргә башкача көчем җитми Ни булса да булыр күңелемне ачып салдым ..»

Эшне төгәлләп прокурорга тапшырганга кадәр бөтен нәрсәне яңадан карап чыктым һәм булган хәлләрне күздән үткәрдем

Ә хәл болай булган Александроваларга кергәч ике имче икәүләшеп тозлы су ясаганнар аны сыер абзарына алып кергәннәр Заволжина бушлатын шәлен салып элеп куйган чәчләрен маңгаена төшереп нәрсәдер пышылдарга тотынган Су «изгеләнеп» җиткәч сыерны «дәвалый» башлаган. Ике мөгез арасына, бөтен гәүдәсенә тозлы су бөркегән Соңыннан сыртына, кабыргаларына тәре сызгалаган

— Анна. җилененнә төер бар Сыерыңны бозганнар Бозауламыйча сөт бирмәс, сатыгыз булмаса, — дигән

— Юк! Сатаммы соң! Үзең бозгансың, үзең төрелт! Үткән атнада кем безнең сыерның йонын йолкып кисәсенә салды? Син бит!..

Заволжина, сыерның уң ягына чыгып. җилененә массаж ясый башлаган Кинәт чыккан ачудан акылы томаланган Анна. тимер кендек алып Заволжинаның башына суккан Төн җиткәч мәетне коега ташлаган Икенче көнне коега таш тутырган Ә киемнәрен бистә читенә чыгарып күмгән Тикшерү органнарын ялгыш юлга юнәлтү ~~өчен аноним~~ хатлар язып җибәргән

Авыр җинаять! Ә сәбәбе — юк-барга, хорафатларга ышанудан килеп чыккан

Башта шундый серле булып күренгән вакыйга хәзер көн кебек ачык — төпсез коеның төбе кебек ..

Гомәр САТТАРОВ-МУЛИЛЛЕ

Ялгызлык исемнәре һә…

(Очерк-эссе)

(Ахыры. Башы 9, 10, 11 нче саннарда).

3.ӘНӘК

Мәкаләмнең «Әнәк» дип аталган бу өлешен язарга тарих фәннәре кандидаты Таһир Кәрим Бакалының башта «Идел» журналының 1994 елгы 12 нче санында аннан соң «Ватаным Татарстан» газетенең 1995 елгы 3 февраль санында басылган «Президент авылы» дигән язмасы этәрде. Язманың Актаныш районындагы Әнәк авылының тарихын һәм андагы нәселләр шәҗәрәләрен шул исәптән Татарстан Республикасының беренче Президенты Минтимер Шәймиевнең нәсел шәҗәрәсен өйрәнүгә багышланган булуы хуплауга лаек. Әмма Әнәк авылы исеменең мәгънәсен этимологиясен) аңлатуда автор ялгыш караштa тора

Әнәк авылы исеме аның мәгънәсе хакында Таһир Кәрим-Бакалы болай дип яза «Картлар хәтерендә сакланган риваятьләр бу авылга Әнәк карт нигез салуын сөйли Архив чыганаклары да моның шулай икәнен раслый Әнәк — хәзер безнең өчен ятрак. гадәти булмаганрак исем Г Саттаровның «Татар исемнәре сүзлеге»ндә дә ул телгә алынмаган Ә шулай да мондый исемле кеше булган һәм берәү генә дә түгел. Минем фаразымча. «Әнәк» дигән сүз кеше исеме буларак туган телебезгә гарәпләрдән кергән. Аларда ул хәзер дә «матур», «күркәм булу» дигән мәгънәдә кулланыла сүзлекләрдә «анака» дип күрсәтелә Х К Баранов. Арабско-русский словарь Изд. 5-ое. перераб. и дополнен — М.. 1977 с 47).

Тарихчы-тарихчы инде кеше исемнәре белгече телче-антропонимист галим түгел Әнәк исеменең асылында безгә гарәпләрдән кергән **анака** («матур». «күркәм булу») сүзе ятмый. Анака — анака инде ул. әнәк түгел **Анака** — калын әйтелешле. биш аваздан гыйбарәт сүз. әнәк исә нечкә әйтелешкә ия дүрт аваздан гына тора Димәк. «анака»ның «әнәк»кә ничек әверелүен фонетик яссылыкта дәлилләү сорала Бу очракта моны дәлилләп булмый. Чөнки төрки халыкларда. шул исәптән татарларда да. гарәби чыгышлы Анака дигән ирләр исеме кулланылышта йөрмәгән.

Әнәк — «эт. эт баласы көчек» мәгънәсенә ия булган борынгы гомумтөрки сүз Шул сүздән Әнәк исеме ясалган «Эт». «көчек» төшенчәсен белдерә торган сүзләрнең кеше исеменә әверелүенең үзенчәлекле тарихи-лингвистик сер-хикмәте. йола-гадәте бар әлбәттә.

Минем «Исемең матур кемнәр куйган?» (Татарстан китап нәшрияты. 1989) һәм «Татар антропонимикасы» (Казан университеты нәшрияты. 1990) дигән монографияләремдә Әнәк исеме турында да сүз алып барыла. Тарихчы Таһир Кәрим Бакалы әлеге хезмәтләр белән таныш түгел. күрәсең.

Әнәк сүзенең «эт». «көчек» мәгънәсендә кулланылышы хәзерге татар әдәби телендә урын алмаса да. (телебезнең кайбер сөйләшләрендә **эт әнәге** «эт баласы». чагыштырыгыз: сарык бәрәне кәҗә бәтие каз бәбкәсе үрдәк бәбкәсе һ б әнәк эте тәгъбире кулланылышта йөри). байтак кына төрки телләрдә һәм шивәләрдә бу сүз шул мәгънәсендә сакланган төрек. тува телләрендә эник. әнәк. әзәрбәйҗан шивәләрендә әних. төрек шивәләрендә әнүк, әнәк. енек. алтай телендә «унак» (үнәк) — «яшь эт». «көчек» (Э В Севортян. «Этимологический словарь тюркских языков». — Изд. «Наука». М . 1974 ел. 281 бит). Татар теленең тау ягы сөйләшләрендәге әнчек. чуваш телендәге һәм шивәләрендәге анчак «яшь ана эт», «көчек» сүзе дә гомумтөрки әнәк («эт яшь эт», «эт баласы. көчек») сүзе белән тамырдаш. Минем карашымча бу сүзләрнең тамырында **ән** «җан» **әни** «җан тудыручы». «җан табучы» мать) сүзе ята.

Ни өчен нинди антропонимик йола-ышанулар аркасында әнәк сүзе Әнәк дигән ир-ат исеме булып киткән кеше исеменә әверелгән соң?

Борынгы төрки халыкларның күбесендә эт культы да гамәлдә була Дунай болгарлары, Идел болгарлары хазарлар чувашлар Казан татарлары этне усал-яман көчләрдән саклый торган изге хайван итеп санаганнар. аңа аерым хөрмәт күрсәткәннәр Кешене күмгәндә, йорт нигезләгәндә. борынгы төрки мәҗүси йола-гадәт буенча. этне корбан итеп чалганнар. Эт бинаны усал көчләрдән саклый, аларны куып җибәрә дип ышанып. Идел болгарлары йорт салганда аның нигезенә эт күмеп калдыра торган булганнар Болгар дәүләте чорында салынган күп кенә ташпулат нигезеннән археологларның эт сөякләре яки эт рәсеме төшерелгән амулетлар табулары өнә шул турыда сөйли (А П Смирнов Волжские булгары, — М . 1951 144-145 битләр) Казан шәһәрен салганда беренче йорт нигезенә тере эт күмеп калдыру турындагы риваять тә болгар бабаларыбыздан ук килә торган борынгы мәҗүси йоланы чагылдыра Танылган археолог А Халиков бу турыда болай дип яза «Болгарларда... эткә табыну да бик нык таралган булган. Этнең болгарча атамасы «куче» хәзерге болгар телендә үзгәрешсез саклана. ә Казан татарларында «көчек» формасында әле булса да яшәвен дәвам итә Идел буендагы. борынгы каберлекләрдән (Тархан. Танкеево. шулай ук Нови-Пазар — Дунай Болгариясе — Г С) табылган эт сөякләре мәет күмү ритуалында этнең үзенә бер төрле урын тотканлыгын раслап тора Идел буе болгарлары эт улавын яхшыга юрый торган булганнар моны без Ибне Фадлан язмалары буенча беләбез. Эткә табыну йоласы Казанның салынуы турындагы риваятьтә дә чагылып үтә Казан стеналары астына тереләй эт күмеп калдырганнар. имеш Казан татарларында әле соңгы вакытларгача шундый бер кызыклы гадәт яшәп килгәнлеге билгеле бала тугач аңа «көчек күлмәге» кидерә торган булганнар».

Күренекле тарихчы М Худяков эт һәм бүре тотемының Идел буенда бик борынгы тотем булуын. каберлекләрдән бик күп эт һәм бүре сыны. аларның рәсемнәре төшерелгән савытлар табылуын әйтә. бигрәк тә Әгерҗе. Алабуга. Воткински шәһәрләре тирәсендә мондый каберлекләрнең күп булуын яза. шулар белән бәйле ырымнарны санап китә («Мирас», № 3, 1995 ел. 146 бит).

Болгар-татарларда эт культы. эт тотемына нисбәтле рәвештә һәм. ир бала талымсыз, авыруларга бирешми торган булсын дигән теләктән чыгып. «эт» мәгънәсенә ия булган сүзләрне кеше исеме итеп бирү йоласы булган. Шушы йола аркасында иске татар телендә «эт» төшенчәсен белдерә торган көчек-коцок, канчык әнчек. ногай. әнәк. әгер. йыт. барак, көпәк-күбәк дүләп-түләп сүзләре кеше исеме булып та йөргәннәр.

Тарихи антропонимикабызда Күбәк исеме урын ала Татарстан дәүләт музеенда Казан ханы Мөхәммәтәминнең (1487 1496 һәм 1501-1518 елларда патшалык иткән) гаскәр башлыгы Күбәккә моннан 500 еллар элек бакыр эшләре остасы Насыйр бүләк иткән җиз савыт саклана. Аңа чокып язылган текстта Күбәк исеме ике мәртәбә кабатлана. Димәк, Казан ханлыгы чорында болгар-татарларда Күбәк — «эт» исеме кулланылышта йөргән. Күбәк исеменнән татарлардагы Кубяков, Кибяков фамилияләре ясалган. Урысларда Кобяков, белоруcларда Кабяк фамилияләре бар. Татарстанның Мөслим районында Күбәк дигән татар Питрәч районында Күбәк Иле исемле урыс авылы бар Түмән өлкәсе Вагай районындагы Себер татарларының бер авылы да Күбәк исемен йөртә Әгер Азнакай районында Әгер дигән татар авылы бар). Әнәк Актаныш районыннан тыш. Сарман районында да Әнәк исемен йөртүче бер татар авылы бар). Көчек, Барак. Әнчек, Түләп исемнәре синонимдаш булганнар Борынгы төрки телдә. мәсәлән. Күчүк Күчүк тимур исемнәре кулланылышта йөргән (Древнетюркский словарь Л , 1969 ел, 324 бит).

Казан өязенең 1602-1603 елларда сан алу кенәгәсендә Көчек Атагечев Көчек Карачаров Көчек Тегишев, Көчек Тохтамышев, Көчек Тлятиков исем фамилияләре белән очрашабыз. Болгар татарлардан марилар Кочек, Кочекбай удмуртлар Кучук шуннан аларда Кучуков Кучугов фамилияләре ясалган) исемнәрен кулланылышка алынганнар Көчек исеменнән Казан татарларында Кучуков фамилиясе ясалган Кучуков фамилиясе урысларда да бар Республикабызның Кукмара һәм Әгерҗе районнарындагы Көчек диген т…
лары атамасының нигезендә дә б…
ларның Көчек исеме ята Казан …
рында Арча юлында Көчек исемле…
лы булган Борынгы Көчекбай исе…
тарларында Кучукбаев, Көчекбае…
сендә сакланган

Каюм Насыйри «Зөя өязе авыл…
ле тарихи-ономастик хезмәтендә «…
Бәчек авылына Болгар яки Биләр …
рафыннан өч кеше килеп утырга…
Бәчек баба. Әнчек баба. Яньчек ба…
булганнар Олугсын Бәчек баба ди…
Бәбчек авылы аның исеме белән а…
— дип яза К Насыйри Сайлан…
— 2 т. Казан. 1975 ел. 25-26 бит…
Әнчекнең кеше исеме булуы яхшы…
Урта диалектның тау ягы сөйләш…
чек (Урал татарларында канчык, …
апеллятивы бүгенге көндә дә «эт» …
дә кулланылышта йөри Чувашла…
Анчик исеменнән Анчиков фамили…
ка килгән

Кыпчакларда «эт» мәгънәсенә ия …
бяк һәм Барак исемнәре кулланы…
гән (Полное собрание русских лет…
395-396 битләр) Барак исеменнән т…
рләрдәге һәм урыслардагы Барак…
ясе ясалган Башкортларда Күбәк …
дә кулланылышта йөри (Т Кусимова …
исемдәре» Өфө. 1982 ел 51 бит)

Тарихи антропонимикабызда мо…
нән кергән Ногай монголча нокай…
исеме дә булган Борынгы төрки …
телләрендә нокай ил («эт елы») — …
циклына нигезләнгән ел исәбенең …
елы Шушы елда туган ир балаларга…
Ногай (Нугай) исеме бирелгән Төрде…
гай, Нагай исемнәре Казан тат…
XYI-XYIII йөзләрдә шактый актив ку…
Болардан Нугаев. Нагаев фамилия…
ган.

Күрәбез ки, Президентыбызның …
лы Әнәкнең исеме — халкыбызны…
йола-ышануларына нисбәтле рәвеш…
ка килгән шактый серле һәм кызык…

4.МИНТИМЕР

Мәкаләмнең бу өлешен язарга ми…
гия фәннәре кандидаты, өлкән …
РСФСРның атказанган укытучысы Ф…
Ибраһимовның «Ике йөз елдан соң …
булырмы яки урыс-татар мөнәсәбәтл…
рата» («КУ», № 12, 1994) дигән пу…
мәкаләсенең «Исемең ничек, улым?…
лияң?» дип аталган бүлекчәсе мә…
Фатыйх ага Ибраһимов анда: «... кыз…
исемнәребезнең тарихы өйрәнелмәг…
Саттаровның бер-ике мәкаләсеннән …
гаҗәеп әһәмиятле өлкәдә фәнни-т…
эшләре бөтенләй юк. Димәк, бөтен з…
мына куелган. Әһәмият бирүче дә …
бирүче дә юк», — дип яза (158 бит)

Нинди зур гаеп ташлый Фатыйх а…
нең һәм дистәләгән шәкертләремнең…
безне татар исемнәре тарихы…
исем-фамилияләрен, тулаем татар а…
миясен, татарныкын гына түгел, төр…
лардан үзбәк, казакъ, шор һ б антр…
ясен өйрәнүгә. гомумән, төрки-татар о…
касын фәнни өйрәнүгә, гыйльми тикш…
гышлап та, минем «бер-ике мәкалә…
ка, бу гаҗәеп әһәмиятле өлкәдә ф…
шеренү эшләре бөтенләй юк» икән …
мә! «Исем атамаларыбыз» дип гомер …
атып, шуларга багышлап дистәләгән …
тап-монографияләр, биш йөзгә якын …
ләр язып бастырып чыгарып, «исем-…
атаманы»на әверелеп тә бер-ике мәк…
ры гына булып кал әле

Фатыйх ага, минем татар исем-фа…
рен, кушаматларын өйрәнүгә багы…
югарыда телгә алынган һәм башка су…
монографияләрем белән тиешенчә т…
са, болай «кимсетеп» язарга җөр…
иде

Фатыйх аганың «Димәк, бөтен эш у…
на куелган Әһәмият бирүче дә, юнәл…
че дә юк», — дигән гаеп ташлавы да …
чынбарлыкка бөтенләй туры килми

...безнең хәят

...ер тамчы диңгез суында диңгез суының ...лык хасият-сыйфатлары да чагылганга, ба... ...к исемнәребезнең дә барлыкка килү тари..., бирелү йола-мотивларын бәян итү бер ...-мәкаләдә мөмкин булмаганга, моны бер ...м, бу очракта Минтимер исеме (Президен...ызның туган авылы Әнәк исеме турында ...ч. Минтимер исеме хакында сүз алып бару ...нлы булыр, үзенә күрә бер антропонимик ...ема, түгәрәк тәшкил итәр), мисалында як...ыйк карыйк.

...интимер исеме пикет, демонстрацияләргә ...п чыккан плакатларга язылганча, «Мин-ти... — «Я — железный» мәгънәсен белдер... Ул — **миң** (миң — мин) һәм **тимер** сүзләре ...ылып ясалган кушма исем. Миңлетимер ...скартылган әйтелеш-язылыш варианты ...нтимер) исеме «бәхетле, тимер кебек нык ...бала» дигән мәгънәгә ия.

...иңле (әйтелеше миңле — м...і — ......) ...ушма төзелешле татар исемнәре составы... урын ала торган актив исем компоненты. ...ар антропонимиконында 150дән артык куш... төзелешле ир-ат һәм хатын-кыз исеме миң... (миңне — миң — мин) антрополексемасы ...ылу юлы белән ясалган. Борынгы заман...да миңле бала бәхетле була дип ышанган... һәм яңа туган сабыйга, тәнендә миңе бул... яки соңрак миң чыкса, баштагы исемен ...штырып, аңа миңле (миңне) сүзе кергән ... биргәннәр. **Миң, миңле** сүзе матурлык, ...ерлек, күркәмлек символы булып та сана... Чагыштырыгыз: Миңнулла, Миңнегол, ...гол, Миңзифа, Миңлеруй, Миңлекамәр һ.б. ...сы-таҗик телендә «миң, миңне» мәгънәсе... йөри торган **хол — хал** сүзенең (татарча ...лештә **кал**) татар антропонимиясендә бер ...ем компонентлары кушылу нәтиҗәсендә ... кына кушма төзелешле синонимик пар ...кил итүче ир-ат һәм хатын-кыз исемнәре ...лыкка килгән: а) Миңлебай — Калбай, Ми...бәк — Калбәк; Миңлеморза — Калморза; ...леәхмәт (Минәхмәт) — Каләхмәт; Миңле...әммәт — Калмөхәммәт; Миңлегали — Кал...; Миңлехуҗа — Калхуҗа; Миңлетимер ...нтимер) — Калтимер һ.б.; б) Миңлебану ...албану; Миңлебикә — Калбикә; Миңлеза... — Калзадә; Миңлезөһрә — Калөһрә; Миң...уй — Миңлейөз — Калчәр; Миңлениса ...иниса) — Калниса; Миңлесылу (Миңсылу) ...алсылу һ.б.

...олгар-татарлар бала тимердәй нык, та...аламәт булсын, аның янына усал көчләр, ...улар килмәсен дигән теләктән чыгып, аңа ...р сүзе кергән исемнәр биргәннәр. Бала... тугач та үлеп киткән гаиләләрдә дә яңа ... сабыйга «тимерле» исем кушканнар.

...әкнең Чаптын Шәйшәрип Шәймөхәммәт...ың (Шәрип Шәймиевнең) гаиләсендә дә ... ир балалар, тугач та озак тормастан, ... барган булса кирәк. Шуңа күрә Шәрип ...соңрак дөньяга килгән ир балаларына «ти...ле» исемнәр кушкан: Хантимер (Минтиме... абыйсы), Миңлетимер (Минтимер).

...еге «тимерле» теләк-йола нигезендә та... антропонимиясендә барлыкка килгән Ти... (диалекталь вариантлары Тимри, Тимрәй, ...ш, Тимаш, Тимуш, Тимүк, Тимәк), Алтын..., Тимербай, Байтимер, Тимербикә (ха...кыз исеме), Тимербулат, Булаттимер, Ти...бәк, Таштимер, Иштимер, Тимеркәй, Тиме..., Тимербуга, Тимертай, Тимерташ, Тимер..., Тимермалик, Тимерхуҗа, Тимеркотлык, ...тимер, Тимерсолтан, Солтантимер, Ти...рәй, Тимерхан, Хантимер, Миңлетимер, ...тимер), Тимерша, Шаһтимер, Тимершәех, ...тимер, Тимерҗан, Җантимер, Биктимер, ...ер, Исәнтимер (диалекталь вариантла... Исти, Исәнти: болардан Истиев, Исәнтиев ...лияләре ясалган), Бүләктимер, Чынти... ...б. исемнәр барлыкка килгән һәм күбесе ...дә кулланылышта йөри. Тимер исеменең ...теленә алынган варианты — Тимур. Со...ларда татар гаиләләрендә дә Тимур исе...ктый еш кушыла башлады.

...кыбызда «Исеме җисеменә туры кил...гән тирән эчтәлекле әйтем бар. Бу әй... Татарстан Республикасының беренче Пре...ты Минтимер Шәрип улы Шәймиевкә, ...исеменә карата туры-тап килә. Аның Ми...мер (Минтимер) «бәхетле, тимер кебек ...еше» дигән исеме мәгънәле җисеменә, абруй-дәрәҗәсенә, дәүләт-ил башлыгы буларак ныклыгына, таза-сәламәт тәнле һәм фикерле, зирәк акыллы, прогрессив карашлы хаким булуына тулысынча тәңгәл килсә иде! Шуңа өлегә фикер, уй-теләкләремне ***«Исем һәм җисем»*** дип аталган шигырьгә салып әйтәсем килә:

Илбашыбыз, чордаш Минтимер,
Ике өлештән тора исемең,
Исемеңә туры килүен
Тели халык синең җисемең.
«Мин» дигәне аның «миңле»дән,
Миңле кеше — бәхет иясе;
«Тимер» — ныклык белән чыдамлык —
Саф алтыннан кыйммәт бәясе.
«Бәхет» белән «ныклык» бер булып
Берләшкәннәр синең исемдә.
Шатлык килер, чыдам булсаң син,
Һәрчак илең булса исеңдә.
Иншалла, шулай булсачы. Амин!
Идел йорты илнең хуҗасы,
Ил агасы, илбаш Минтимер,
Республикаң Татарстанга,
Танылу яулап бәтен дөньяда,
Суверенлык һәм ирек китер!
Суверен мәмләкәт, мостәкыйль
Булсын дисәк, гүзәл Татар-ил,
Чәчәк атсын дисәк Татарстан,
Ясыйк дисәк анда гөлбостан,
Илбаш тирәсенә тупланыйк!
Дуслык-бердәмлектә көч тә бит,
Ышанычны акла, Президент,
Татар илен таңга, алга илт!
Тынычлык, татулык шигарең*,
Алтынлап туграга** чигәрең.
Заманалар кыен, болгавыр,
Күбебезгә авыр, бик авыр:
Иң авыр йөк синдә, илбашы,
Күп-күп эшнең зурысы, иң башы.
Эшчән халкың синңа нык таяныч,
Конституция — Төп Закон — юл яргыч:
Халкым рухы, тирән мәгънә исемеңдә,
«Туган ил» дип, яну-көю җисемеңдә.
«Халкым» диеп, халкы өчен янса башлык,
Безгә килер олы җиңү, кат-кат шатлык:
«Татарым» дип, утка керсә, көйсә хаким,
Без булмабыз башкалардан бервакыт ким.

Туган телне яклау һәм саклауның
Асыл үрнәге бул, Минтимер,
Шулай булсаң, илә-Татарстанга
Рухи шатлык килер, дан килер.
Халык улы булып күкрә, яшьнә,
«Телем-җырым, илем», — диеп яшә;
«Халкым», — диеп кояш булып балкы,
Рәхмәт әйтсен халык — татар халкы.
Йә, бер Ходам, барсын кыл кабул,
Татарстанга иңдер пакь, ак юл.
Иншалла, шулай булсачы. Амин!

* Шигар — лозунг, девиз.
** Тугра — герб.

Газета һәм укучы

Тәмле күчтәнәч

Хөрмәтле «Мәдәни җомга»!

Синең беренче саның Әстерхан каласына да килеп ирешге Аны өлкән абый-апаларыбыз гына түгел, без — балалар да бик кызыксынып укыдык Дөрес, безнең өчен бераз катлаулырак гәзит инде ул Шулай да ерак Ватаныбыз Татарстаннан җибәрелгән күчтәнәч кебек кабул иттек без аны

Инде язгач-язгач, сезгә быелның җәендә ничек ял итүем турында да сөйләргә булдым

Мин 10 нчы лицей-мәктәпнең 6 нчы сыйныфында укыйм Икенче ел инде һәркөнне, дәресләрдән соң, Нугай мәчетендәге мәдрәсәгә гарәп теле дәресләренә йөрим

Быелның августында миңа Сарытауда балалар һәм яшүсмерләр өчен оештырылган Ислам лагерендә булу бәхете эләкте Ул лагерь, Сарытаудан автобус белән барганда, чама белән бер сәгатьлек ераклыкта, нарат һәм каен урманы эчендә урнашкан иде. Анда миңгә якын бала ял итте Күбесе Сарытау өлкәсеннән, шулай ук Татарстан, Волгоград, Пинҗә. Ульян якларыннан килгән балалар, егетләр-кызлар да бар иде Без Әстерханнан башта бишәү идек, өчесе лагерьны ошатмыйча кире кайтып китте Ә без дустым Илдар Шәрәфетдинов белән ахыргача булдык. Лагерьда 10 яшьтән алып 20 яшькә кадәрге балалар, егетләр һәм кызлар ял итте Бөтенесе дә татар балалары, арада берничә чәчән һәм башка милләттән булган мөселман егетләре дә бар иде

Без урман эчендәге унбишәр һәм дүрт кешелек бүлмәләрдә яшәдек. Төп бинаның зур бер бүлмәсе намаз уку өчен җайлаштырылган, идәнгә келәмнәр җәелгән.

Мисырдан килгән шәех гарәпчә генә сөйли. Калган укытучыларыбыз — барысы да яшьләр.

Мөгаллимнәребез һәр нәрсәне дә әрләмичә, тыныч кына аңлаттылар. Лагерьда үзебез алып килгән киемнәрдән йөрдек. Түбәтәйләр дә үзебезнеке иде. Тәүлеккә биш тапкыр намаз укыдык. Намаз арасында дәресләр үткәрелә. Ислам дине кануннары, мөселман илләре турында күп нәрсәләр ишеттек. Безне шулай ук гарәп графикасына, тәһарәт алырга һәм башка кагыйдәләргә дә өйрәттеләр.

Монда ял итүчеләрнең яртысыннан күбрәге гарәп хәрефләрен белә иде. Хәер, теләге булганнар бик тиз намаз укырга, хәреф танырга өйрәнделәр. Лагерьда волейбол, футбол уйнарга да мөмкинлекләр тудырылган.

Беркөнне теплоход белән дүрт сәгать буе Идел елгасы буйлап сәяхәт иттек.

Көн тәртибенә, андагы шартларга бик тиз күнектек. Бераздан иртәнге намазга да җиңел тора башладык.

Берничә тапкыр кызыклы викториналар үткәрелде. Җиңүчеләргә төрле сувенирлар, дини китаплар бүләк ителде.

Лагерьда ял итүчеләр үзара бик тату яшәделәр. Гаҗәп бит, арада бер генә тапкыр да тәртип бозучылар очрамады. Бер атнадан кайбер балаларның әти-әниләре килде. Сарытаудан килеп телевидениегә дә төшереп киттеләр.

Аш-су пешерүчеләребез бик яхшы ашаттылар, юллама бушлай, юлга гына акча түләргә кирәк булды Бу җәйге Ислам лагерен тоту өчен, Мәскәүдәге Ибраһим фонды акча бүлеп биргән икән.

Лагерьдан киткәндә, безгә вәгазьләр, Коръән сүрәләре язылган кассеталар, яхшы сыйфатлы күн букчалар бүләк иттеләр. Хәзер мин бу букча белән мәдрәсәгә йөрим. Чөнки ул бик матур! Киләсе елда, Алла теләсә, без өлеге Ислам лагерена дустыбыз Мансурны да алачакбыз.

Тимер БАКАЕВ,
11 яшь.
Әстерхан шәһәре.

● **Ат утлап йөри болында, Хыялларны куертып...**

Эрот ЗАРИПОВ рәсеме.

ҖИДЕ БУЫН ЯДКАРЕ

Соңгы вакытта җәмәгатьчелек һәм татар-мөселманнарның дини идарәсе җитәкчеләре арасында сәйед тә булырга тиеш, дигән фикерләр әйтелә башлады. Аерым алганда, бу фикер Татарстан җөмһүрияте мөселманнарының чираттан тыш корылтае узган көннәрдә күтәрелде. Анда мөфти хәзрәтләренең иң абруйлы ярдәмчеләреннән берсенә сәйед дәрәҗәсе бирергә кирәк, дигән тәкъдим кертелгән иде. Бу хакта татар матбугатында берничә мәкалә дә басылып чыкты.

Сәйедләрнең кемлеге һәм аларның татар тарихында нинди урын биләүләре хакында бүгенге укучыларыбызның күпчелеге хәбәрдар түгелдер дип беләм. Шунлыктан сәйедлек вазифасын булдыру мөһимлеген аңлату өчен тарихи чыганаклар белән танышу кирәктер.

Алтын Урдада, Казан, Кырым, Хаҗи Тархан, Нугай урдасы, Хан Карман ханлыклары тарихларында сәйедләр XIY—XYI гасырларда искә алына башлый. Тарихи чыганаклар сәйедләрне татар ханлыкларында мөселманнарның иң өлкән дини җитәкчеләре итеп күрсәтә.

1524 елларда Казанда булып киткән немец сәяхәтчесе Сигизмунд Герберштейн үзенең юлъязмаларында сәйедне «татарларның баш имамы» дип atый. Сәйед белән хан да хисаплаша торган булган. Казан тарихында түбәндәге сәйедләр булганлыгы мәгълүм:

Бураш сәйед. Ул 1491-1507 елларда искә алына.

1512-1516 елларда Шаһ Хөсәен сәйед Казан белән Мәскәү арасындагы илчелек мөнәсәбәтләрендә катнашып йөри.

Шаһ Хөсәен сәйед Шакуловлар шәҗәрәсендәге егерме сигез, егерме тугыз, утызынчы буыннарда антропонимнары Шаһ компонентына ия булган, XYI гасырның беренче яртысында яшәгән сәйедләрнең кардәше булырга тиеш. Шәҗәрәдә бу исем күрсәтелмәгән, чөнки ул тулы түгел, анда Казанга каршы сугышкан Касыйм татарлары гаскәрендә булган Ак сәйед исеме дә юк.

1546 елда Казанда сәйед булып Беюрган сәйед тора. Казан ханы Сафа Гәрәй тәхеттән төшерелгәч, ул андагы вакытлы хөкүмәтне җитәкли. Беюрган сәйед 1551 елның октябрендә Шаһ Гали хан өмере белән җәзалап үтерелә.

1546 елда Сафа Гәрәй Мансур сәйед (Әстерханнан Казанга килгән була) белән берлектә Казаннан Әстерханга китә. Димәк, Мансур сәйед Казанда күпмедер вакытлар дин башлыгы булып торган. Ул әвакламый вафат була, күрәсең, чөнки бу елдан соң аның исеме чыганакларда күренми.

Казан тарихында исеме сакланып калган янә бер сәйед — Кол Шәриф (Шәриф Хаҗитархани); аның исеме 1550 елдан күренә башлап, 1552 елның 2 октябренә кадәр тарихта язылып килә. Ул шул көнне соңгы тамчы канына кадәр ватанын саклап һәлак була. Казан патшалык башкаласы вакытында, анда Корәеш дигән бистә булуы да мәгълүм. Ихтимал, ул бистә Казан сәйедләре исеме белән бәйле булса кирәк.

Казан ханлыгы сәйедләренең абруйлы булуларын Сәхиб Гәрәй хан тарафыннан 1523 елда бирелгән тарханлык ярлыгы да раслап тора. Ул ярлыкта алар «садати гозам» дип йөртеләләр.

Сәйедләрнең Кырым ханлыгында да олы дин башлыгы булулары 1531 елда Сәгадәт Гәрәй хан биргән ярлык эчтәлегендә дә күренә.

Тарихта Касыйм ханлыгы сәйедләре турында иң тулы мәгълүматлар сакланган. Бу мәгълүматлар чыганагы булып сәйед Шакуловларның нәсел шәҗәрәсе хезмәт итә. Әлеге нәсел шәҗәрәсен 1970 елда сәнгать фәннәре докторы Фоат Вәлиев Касыйм шәһәреннән табып алып кайтты һәм бу юлларның авторына бүләк итте. Шакуловлар шәҗәрәсе XYIII—XIX гасырларда гарәп әлифендәге күчермәләрдән гыйбарәт. Алар өч озын кәгазь битеннән гыйбарәт. Шуларга кыскача гына тасвирлама биреп узабыз.

Беренче текст 112 см озынлыктагы, 21 см киңлектәге, зәңгәрсу төстәге кәгазьгә алсу һәм кара каралар белән XYIII гасыр ахырында язылган. Ахыргы өлеше ертылып югалган. Артык ягында Ф.Вәлиевнең автографы бар. Ул Татарстан Фәннәр академиясе, Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты мирасханәсендә 90 нчы коллекциядә, 1 нче тасвир, 209 нчы эш булып саклана.

Икенче текст 197 см озынлыкта, 18 см киңлектә. Ул XIX гасырның беренче чирегендә эшләнгән яхшы кәгазьгә кара белән гарәп әлифендә язылган. Ул шәҗәрәләр коллекциясендә 264-б эш берәмлеге белән саклана. Бу әлегә иң соңгы текст булып тора.

Өченче текст 143,5 см озынлыкта, 17,5 см киңлектә. Анысы XYIII гасыр кәгазенә кара кара белән гарәп әлифендә язылган (мирасханәдә 264-а эш берәмлеге белән саклана).

Беренче, өченче текстларда беркадәр гарәп телендә язылган искәрмәләр дә бирелгән.

Моннан тыш, Шакуловлар шәҗәрәсенең күчермәләре урыс тарихчысы В.Вельяминов-Зернов (1830-1904) һәм татар галиме Ризаэтдин бине Фәхретдин (1859-1936) кулларында да булганлыгы мәгълүм. Алар кулындагы кулъязма текстлар XIX гасырда күчерелеп, татар телендә язылган байтак тарихи искәрмәләргә дә ия булып торган. В.Вельяминов-Зернов үз кулындагы шәҗәрә текстын өлешчә генә 1863-1887 елларда чыккан «Исследование о касимовских царях и царевичах» исемле дүрт томлык хезмәтендә файдаланган.

Ризаэтдин бине Фәхретдингә Касыймнан җибәрелгән «Шакуловлар шәҗәрәсе» «Шура» журналының 1914 ел, 22 нче саны тышлыгында басылып чыккан. Әлеге шәҗәрә утыз алты буыннан торып, кулъязма текстлардан кыскарак.

Кулъязма текстларның буыннар ягыннан иң тулысы — мирасханәдә 264-б эш берәмлеге булып саклаңучы шәҗәрә. Түбәндә аның текстын тулысынча китерәбез. 209 нчы эш берәмлеге белән саклаңучы беренче кулъязма буыннарны күрсәтү ягыннан кыскарак, ләкин искәрмәләргә баерак. 264-а эш берәмлеге белән саклаңучы текстта гарәп телендәге искәрмәләр бар һәм, утыз алтынчы буыннан башлап, 264-б шифрлы текстта булмаган буыннар чылбыры китерелә.

«Шура» журналында басылган текст 264-б текстына әстәрлек яңалыкка ия түгел, ләкин аны журналга җибәрүче Касыйм шәһәрендә 1914 елда Шакулов фамилиясен йөртүче кешеләрнең күп булуларын яза, тик аларның буыннары, исемнәре шәҗәрәдә күрсәтелмәвенә үкенеч белдерә.

Мәкаләнең күләме зураеп, урын чикләнгән булу сәбәпле, 264-б кулъязмасыннан башкаларының мәгълүматларын кабатламаган урыннарын сайлап кына укучыларга тәкъдим итәбез.

Марсель ӘХМӘТҖАНОВ

Сәйед Шакуловлар



ШАКУЛОВЛАР ШӘҖӘРӘСЕ ТЕКСТЫ

(264-б кулъязма)

Рәхмәт итүче, рәхимле Аллаһ Хакына!*
Бу шәҗәрә Корайеш кабиләсе
Һашим ыруыныкыдыр

Тәртип саны	Буыннар	Атаны белдергән тәртип саны
	Беренче буын	
1	Габделмәннан	?
	Икенче буын	
2.	Һашим	1
	Өченче буын	
3.	Габделмоталлаб	2
	Дүртенче буын	
4.	Абуталиб	3
5.	Габдулла	3
6.	Хәзрәти Габбас разый Аллаһе ганһе	3
7.	Хәзрәти Хәмзә разый Аллаһе ганһе	3
	Бишенче буын	
8.	Хәзрәти Гали кәрәм (юмарт)	4
9.	Сәрвәри әнбийә Мөхәммәд Мостафа Салаллаһу галәйһи вәссәлләм	5
10.	Габдулла разый Аллаһе ганһе	6
	Алтынчы буын	
11.	Хәсән разый Аллаһе ганһе	8
12.	Сәйед Хөсәйен разый Аллаһе ганһе	8
13.	Бинтәи сәйедәи Фатыйма әл-Зәһрәи (Сәйед Хөсәйеннең хатыны)	9
	Җиденче буын	
14.	Сәйед Зәйнелгабидин имам	12
	Сигезенче буын	
15.	Сәйед Мөхәммәдбакый имам	14
	Тугызынчы буын	
16.	Сәйед Җәгъфәр әс-Сыйддыйк имам	15
	Унынчы буын	
17.	Сәйед Идрис	16
18.	Сәйед Муса кязыйм (түзеп торучы) имам	16
19.	Гали ансар (Мәдинәдә яшәүче Мөхәммәд тарафдары) сәйед	16
	Унберенче буын	
20.	Сәйед Мөхәммәдшафигъ	18
21.	Сәйед Муса әр-разый имам	18
22.	Сәйед Җарулла	19
	Уникенче буын	
23.	Сәйед Мөхәммәдтәкый имам	21
	Унөченче буын	
24.	Сәйед Галинәкый	23
	Ундүртенче буын	
25.	Сәйед Хәсән әл-Гаскәри	24
	Унбишенче буын	
26.	Сәйед Мөхәммәд Наһдәмир	25
	Уналтынчы буын	
27.	Сәйед Мир Йуныс	26
28.	Сәйед Мөхәммәд Сәмгани	26
	Унҗиденче буын	
29.	Сәйед Мирбакый	27
30.	Сәйед Йосыф Һәмадани	28
	Унсигезенче буын	
31.	Сәйед Исмәгыйль	30
	Унтугызынчы буын	
32.	Сәйед Моддәвеши	31
	Егерменче буын	

* Гарәп телендәге гыйбарәләр татарчага тәрҗемә итеп бирел…

Сәйед Әхмәд Хисараи ата	32
Егерме беренче буын	
Сәйед Әхмәд Ракенеддин Солтан	33
Егерме икенче буын	
Сәйед Гали хакани	34
Егерме өченче буын	
Сәйед Мостафа	35
Сәйед Мөхәммәд Бохари	35
Сәйед Мөхмүд	35
Егерме дүртенче буын	
Сәйед Йегет Әхмәд	37
Егерме бишенче буын	
Сәйед Шаһи Әхмәд	39
Егерме алтынчы буын	
Сәйед Хилват	40
Егерме җиденче буын	
Сәйед Мөхәммәд	41
Егерме сигезенче буын	
Шаһнур сәйед	42
Сәйед Шаһбай	42
Шаһхан сәйед	42
Шаһҗан сәйед	42
Егерме тугызынчы буын	
Сәйед Шаһмөхәммәд	44
Утызынчы буын	
Сәйед Шаһколый (Шакуловлар фамилиясе моннан киткән. — М.Ә.)	47

шәҗәрәсе

Утыз беренче буын	
Сәйед Борһан сәйед	48
Утыз икенче буын	
Сәйед Кашки	49
Утыз өченче буын	
Сәйед Бүләк сәйед	50
Утыз дүртенче буын	
Акмөхәммәд сәйед	51
Ишмөхәммәд сәйед	51
Утыз бишенче буын	
Тинмөхәммәд сәйед	52
Утыз алтынчы буын	
Әхмәд сәйед	54
Утыз җиденче буын	
Йагъкуб сәйед	55
Утыз сигезенче буын	
Биктимер сәйед	56
Утыз тугызынчы буын	
Әхмәд сәйед	57
Мостафа сәйед	57
Муса сәйед	57
Сәйед Борһан сәйед	57
Акмөхәммәд сәйед	57
Габдулла сәйед	57
Кырыгынчы буын	
Мортаза	59
Солтан Мөхәммәд сәйед	60
Салих сәйед	61
Ибраһим сәйед	62
Йосыф сәйед	62
Сөләйман сәйед	63
Кырык беренче буын	
Сәйфулла сәйед	64
Хәмзә сәйед	66
Кырык икенче буын	
Батыргәрәй сәйед	71
Хосәйен сәйед	71
Кырык өченче буын	
Мөхәммәдҗан сәйед	72
Исмәгыйль сәйед	72
Хәсән сәйед	72
Котлыймөт сәйед	73
Касимхан сәйед	73
Борһан сәйед	73
Ибраһим сәйед	73
Кырык дүртенче буын	
Исмәгыйль сәйед	74

ҮТӘР КӨНЕ АЛДЫННАН

82	Мөхәммәд сәйед	75
83	Батыргәрәй сәйед	75
84	Фәрид сәйед	75
85	Мостафа сәйед	75
86	Исмәгыйль сәйед	76
87.	Сәйед Әхмәд сәйед	78
88.	Мостафа сәйед	78

264-а кулъязма текстыннан өзек

	Утыз өченче буын	
1.	Бүләк сәйед	
	Утыз дүртенче буын	
2.	Ишмөхәммәд сәйед	1
3.	Акмөхәммәд сәйед	1
	Утыз бишенче буын	
4	Пирмөхәммәд сәйед	2
	Утыз алтынчы буын	
5.	Корбанай сәйед	4
	Утыз җиденче буын	
6	Тимерпулат сәйед	5
	Утыз сигезенче буын	
7.	Мостафа сәйед	6
8	Вәлимөхәммәд сәйед	6
9	Әбүбәкер сәйед	6
	Утыз тугызынчы буын	
10.	Мөхәммәдрәхим сәйед	7
11	Сәйетбаттал сәйед	7
12.	Шаһимәрдән сәйед	8
13.	Ибраһим сәйед	8

209 шифрлы кулъязма текстыннан өзекләр

Текст 264-а кулъязмасының утыз алтынчы буыны белән тәңгәл килә 264-б кулъязмасының утыз бишенче буыныннан аерыла башлый һәм утыз алтынчы буын Корбанай сәйед исеме белән туктый Ихтимал, бу нөсхә тагын да дәвам иткән булгандыр, чөнки ахыргы өлеше ертылып-таушалып беткән

209 шифрлы кулъязмада аерым исемнәр янында гарәп телендә язылган берничә искәрмә бар Шулай ук буыннар килешендә аермалар күренә

	Беренче буын	
1.	Габделмоталлаб	
	Икенче буын	
2.	Әбүталиб	1
3.	Габдулла	1
4.	Габбас	1
	Өченче буын	
5.	Гали кәрәм	2
6.	Мөхәммәд Салаллаһу галәйһи вәссәлам	3
7.	Габдулла	4

Тексттагы искәрмәдән: Габдулланың Мөхәммәд пәйгамбәрдән соң халифә Рәшит дәүләте җирләрендә яшәгәнлеге аңлашыла. Хәлифә Һарун әр-Рәшид 785 ел румидә идарә итә башлый Димәк, шәҗәрәне төзүчеләр тарихи дәверләрне бутаганнар

209 нчы шифрлы текстта унбер буын, егерме исем сәйед Мөхәммәдшафигъ нәселенең Шам, Халеб, Багдад һәм башка гарәп җирләрендә таралуы күрсәтелә

Шунда ук унберенче буын, егерме икенче исем янында сәйед Җарулла нәселенең көнбатышта яшәве искәртелә

Егерменче буын сәйед Әхмәд Хисараи ата исеме турысында Бохараи шәрифтә булуы, Хәким ата Сөләйман белән бәйләнеше, Җәйхун (Аму-Дарья) буйларында яшәве языла.

Егерме өченче буын. утыз җиденче исем сәйед Мөхәммәд Бохари исеме турысында аның нәселенең Бохараи шәрифтә. Һиндстанда, Синдстанда (Пакъстан) таралуы языла.

Егерме өченче буын. утыз сигезенче исем сәйед Мөхмүд нәселенең Төркестанда, Коканд, Каши һ.б. урыннарда таралуы күренә

Егерме сигезенче буын. кырык бишенче исем Шаһхан нәселенең Кырым вилаятендә, Кубанда, Дагыстанда таралуы хәбәре бар

Егерме сигезенче буын, кырык дүртенче исем Шаһбай сәйед нәселенең Болгар вилаяте Хан Кирмән, Хаҗи Тархан һәм Идел буйларында таралуы язылган.

Соңгы искәрмә Шакуловлар нәселе шәҗәрәсенең яңарак заманнарда янәдән редакцияләнүен күрсәтә. чөнки анда Алтын Урда дәвере бөтенләй чагылмый Шул ук вакытта андагы төп татар дәүләтләрендә бер үк нәсел вәкилләренең таралышы раслана.

Шакуловлар шәҗәрәсенең тарихи хронологиясен ачыклау өчен В Вельяминов-Зернов файдаланган нөсхәдәге искәрмәләрне монда искә алып китү мөһим.

В.Вельяминов-Зернов язуына караганда. Казанны 1552 елда урыслар алган вакытта, алар ягыннан Ак Сәйед Шәриф сәйед улы катнашканлыгы мәгълүм була.

Касим шәһәрендә 1587 елда Кашки сәйеднең зур дәрәҗәле кеше булуы В Вельяминов-Зернов тарафыннан табылган Федор Иванович патша ярлыгында искә алына

Шулай итеп Шакуловлар шәҗәрәсендәге утыз икенче буын (илленчә исем) Сәйед Кашкиның XYI гасырның икенче яртысында яшәгәнлеге ачыла Касыйм ханнары заманында сәйедләр полклар белән җитәкчелек иткәннәр һәм аларның аерым сарайлары булган

Кашки сәйед улы — Бүләк сәйед була Аның кабере Касимның Иске бистә зиратында сакланган Шәҗәрәдә аның турында «Күзе ачык вә дәлилиге (мантыйгы — М Ә) бар икән Каберләре Иске бистә мазарындадыр» «Сәйед Бүләк сәйед Иске Йортның йадкаре» — дип язылган

Утыз алтынчы буын (илле бишенче исем) Әхмәд сәйед XYII гасырның икенче яртысында яшәгән Касыймның соңгы идарәчесе булган Фатыйма солтанның агасы Тинмөхәммәд сәйеднең (Тинеш сәйед Шакуловның) улы Аның исеме Галикәй аталык васыятьнамәсендә дә искә алына Урыс хөкүмәтенә тәрҗемәче булып хезмәт иткән Ул 1680 елда урыс илчеләре Тяпкин һәм Зотов белән берлектә Кырымга җибәрелә һәм шунда 1681 ел башында үлеп кала

Утыз җиденче буын (илле алтынчы исем) Әхмәт сәйед улы Йагъкуб сәйед XYII йөзнең икенче яртысында яшәгән Аның хакында В Вельяминов-Зернов кулындагы шәҗәрә нөсхәсендә «Йагъкуб сәйед Йалатма кальгасида үлгән Түрә булып торган Бер заманнарда Иске бистәдә (Касыймда — М Ә) Арслан хан (1626-1627 елда үлә) берлән Фатыйма солтанның мазаратында такыя астына кереп. Иске бистәнеке бер хатын солтаннарның кәфеннәрен. гайре әсбапларын угырлап. суеп чыккан Йагъкуб сәйед ул хатынны шул бистә гаганында астырган»

Фатыйма солтан үзе Бүләк Сәйед улы Акмөхәммәд сәйеднең кызы була Аның хакында шәҗәрәдә «Арслан ханны Тубыл-Тура дигән вилаяттән алдырганнар Акмөхәммәд сәйед кызы Фатыйма солтанны алган хәлаллеккә Арслан хан үлгәннән соң, Хан Кирманда (Касыймда — М Ә.) чарича (царица — М Ә) булып торган Фатыйма солтандин соң хан киселгән» — дип язылган

Югарыда китерелгән Шакуловлар шәҗәрәсе күчермәләре шактый кызыклы һәм кыйммәтле тарихи мәгълүматларга ия Аларда сәйедләрнең урта гасырлардан бирле татар иҗтимагый-дини тормышында үзәк фигуралар булып катнашып килүләре күренә

Касыйм сәйедләрнең нәселләре XX гасырга хәтле килеп җиткән Шушы гасырның унынчы елларында Парижда Сарбонна университетын тәмамлап кайткан математик Сара ханым Шакулова (1887-1964) бу нәселдән соңгы күренекле кешеләрнең берсе булып тора. Ихтимал. Шакуловлар нәселеннән бүгенге көндә тагын да вәкилләр бардыр аларны барлау — кирәкле эш

Сәйедләрнең нәселләре бүгенге Русиянең һәм башка дәүләтләрнең шәһәрләрендә яшәгәннәр Мәсәлән. Казан шәһәрендәге Яңа бистә зиратындагы бер кызыклы кабер ташы язмасы шул хакта сөйли Аны фотохәбәрче Ибраһим Галиев 1961 елда фоторәсемгә төшереп алган булган Ибраһим ага 1970 елларда бу ташның фоторәсемен безгә бүләк иткән иде Аның йөзлегендәге язманың хәзерге әлифкә күчермәсен бирәбез

«Мәркадел-гарәб
Корайеш кабиләсе
Һашим ыругының
әш-шәйех Габдулла
бине әш-шәйех Габдессәлам 1280 сәнә
вафат 44 яшендә»

Таш бүгенге руми хисап белән 1874 елда язып куелган Димәк, XIX гасырның икенче яртысында Казан шәһәрендә дә сәйедләр яшәгән булып чыга. Бәлки аның нәселләре бүгенге көндә дә Казанда яки Татарстанда яшиләрдер әле сәйедләр нәселен дәвам итүчеләр бардыр Югарыда китерелгән мәгълүматлар сәйедләрнең Мөхәммәд пәйгамбәр нәселеннән булган дин эшлеклеләреннән булуларын һәм шушы фамилиядән (ырудан) булган берсенең дәүләт яки өлкәләрнең төп дин башлыклары икәнен белдерәләр Сәйед сайланып куела торган урын түгел ә бәлки нәсел буенча килә торган руханиләр дәрәҗәсе

Без Касыйм ханлыгы дәвереннән бирле килгән сәйедләр нәселе шәҗәрәсенә бер тарихи күзәтү ясадык Бу нәсел тарихына кагылышлы тагы да яңа мәгълүматлар табылуы мөмкин Аларны барлау туплау милли тарихыбыз чыганакларын ачыклау юлындагы күркәм эшләрнең берсе булыр иде

«Хуҗа Насретдин китабы»на 150 е...

Хуҗа Насретдин... Торки доньяда аны белмәгән, аның турында ишетмәгән кем генә бар икән? Аның мәзәкләрен һәр җирдә сөйләргә яраталар. Төрекләр исә аның белән горурланалар Хәтта Насретдин фестивальләре үткәрәләр, киенеп-ясанып, бу фестивальләрдә төрле мәзәкләрне тамаша кылалар.

Бу аңлашыла да, чонки Хуҗа Насретдин Кече Азиядә туган дип йөртелә. Аны 1205-1210 еллар арасында хәзерге Төркиянең Сиврихисар районындагы Хорто авылында доньяга килгән. дип исәплиләр. 1284 елда Акшәһәрдә (Аксарай дип тә йөртәләр) вафат булган. диләр Аның тәрҗемәи хәленә бәйле кайбер мәгълүматлар да билгеле Әйтик. Хуҗа укырга-язарга авыл имамы булган әтисе Габдулладан өйрәнгән Малай кече яшьтән үк корьәнхафиз булган. нечкә күңелле. җор телле һәм эш яратучан булып үскән.

Әтисе вафатыннан соң имамлык Хуҗага калган. диләр әмма ул бу вазифаны озакламый дусты Мәхмәткә калдыра. ә үзе исә гыйлем эсти-эсти авылдан-авылга. шәһәрдән-шәһәргә сәфәр чыгып китә. Ул гади халык тормышын күрә. донья барышын үзенчә бәяли, гаделсезлек җимешләрен дә күп татый.

Акшәһәрдә аңа һәйкәл куелган Ишәккә артка карап атланган Хуҗа бүген дә сәфәргә юнәләдер кебек. Каберен күреп кайтучылар бу кабер өстендә мәрмәр таш һәм бер яклы гына чардуган куелганын сөйлиләр Анда бары тик бер капка һәм зур йозак кына бар икән.

Кабереннән ерак түгел тагын бер истәлекле урын бар Бу — Хуҗа Насретдин тарафыннан билгеләнгән «доньяның уртасы», имеш. Ышансаң — хуп, ышанмасаң — тикшереп кара, каршы килүче юк!

Безнең югарыда тасвирланган шәйләргә нисбәтле мәзәкләрне дә ишеткәнебез бар.

Каядыр. Баку ягынамы, поезд белән барганда, бер тау битендә Хуҗаның кабере булуын, кабер ташының тау итәгенә таба авыш икәнен һәм аның, аумасын дип, терәү урынына остән аска таба бастырылып куелуын әйтәләр. Моны күреп һәркем көләргә тиеш, көлмәсәң, авызың чалшая, имеш Хәер, андый манзара тере кешедә елмаю-көлү тудырмыйча калмыйдыр инде.

Хуҗа Насретдин хакында дистәләгән китаплар язылган, кинофильмнар төшерелгән, спектакльләр куелган. Бу хәлләр бүген дә дәвам итә. Аның мәзәкләре тупланган китаплар һәр елны диярлек доньяның кайсы да булса бер почмагында донья күрә. Башта, әлбәттә, ул мәзәкләр кульязма хәлендә йөргәннәр.

Әйтик, 1837 елда Симферополь гимназиясе дирекциясе, татар балалары өчен ачылган сыйныфта укытыр өчен, губернатор аша Рәсәйнең Истанбулдагы илчесенә китаплар җибәрүне үтенеп мөрәҗәгать итә. Илче ике басма һәм ике кульязма китап юллый. Кульязма китаплар арасында «Ләтаифе Хуҗа Насретдин әфәнде» дигәне дә була. Бу, мөгаен, нәкъ шул 1837 елда Истанбулда басылып чыккан китап күчермәсе булгандыр.

Әйе, Хуҗа Насретдин мәзәкләре китап булып беренче мәртәбә Төркиядә төрек телендә басылып чыга. Бу мәзәкләр соңыннан гарәп, француз, инглиз, алман, итальян һәм башка телләргә тәрҗемә ителә.

Татар телендә алар 1845 елда Казанда басылып чыккан һәм аннан соңгы елларда да донья күргән.

Минем китапханәмдә менә шул 1845 елда басылып чыккан «Ләтаифе Хуҗа Насретдин әфәнде» дигән китапның шактый әйбәт кенә сакланган бер нөсхәсе бар. Соңгы би... язмадан аңлашыла... бу китапның иясе Га... Муса кызы Үтәмешева... лган. Күп җирләр узы... лдан-кулга күчеп, бу к... бүгенгәчә сакланып ... гән, шуннан рухына ... тапкан халык аны ка... ләп саклый алган...

Алай гына да түгел ... китапны кешеләр ку... күчереп тә тараткан... Миңа шундый күчерме... нең берсен — 1868 е... Сарманда Габделха... Габделханнан улы т... фыннан күчерелгәнен ... деләр. Басма һәм кул... ма җыентыклар «Ра... өхбар накыйлян» дигән... зләр белән башлана... сүзләр «Башка бер ке... дән ишеткәннәрне ике... кешегә сөйләүче хәбә... ре» дигәнне аңлата.

Әйе, бу мәзәкләр ... менә шулай кешедән ... шегә сөйләнеп, төрле ... ләргә, төрле илләргә т... лган. Аларда тормыш ... чагыла, ә тормышта н... генә булмый...

Хәер, Хуҗа Насретд... турында мәзәкләр бүге... чорда да туа тора. А... 1941-1945 елгы Бөек Ва... сугышында күргәннәре ... рында мәзәкләр ае... бер сәхифә тәшкил итә...

Хуҗа Насретдин кай... та үтә беркатлы б... кайчакта ул — га... акыллы һәм зирәк, ә ... чакта искиткеч тылсы... се дә.

Ни генә булмасын, Ху... Насретдин мәзәкләре б... не гомер буе озатып б... Алар — олыларның да ... челәрнең дә якын ю... шы.

Әйдәгез, бу мәзәк... нең ерак бабаларь... укыганнарының, сө... йөргәннәренең кайбе... ре белән танышып ал... *(Мәзәкләрнең язылы... элеккечә калдырылды)*

Дамир ГАРИФУЛЛ...
Сар...



ТӨРКИЛӘРНЕҢ КӨЛКЕ КАПЧЫГЫ

* * *

Бер көн Акшәһәрнең балалары Хуҗаны мунчага алып бармакчы булдылар вә яңнарына берәр йомырка яшереп алып бардылар. Җөмләсе берьюлы мунчага барып соенеп эчкә кереп утырдыкларында, һәрберемез берәр йомырка салыйк Һәркем ирсә йомырка салмаз исә, мунчаның акчасын ул бирер, дип вәгъдә кылыштылар. Һәрбере тавык кеби кытпап (кытаклап) утырган ташлары үзрә (өстенә) йомыркаларын куйдылар Хуҗа әфәнде буларны күреп һаман әтәч кебек кычкырыр Угъланнар «Хуҗа әфәнде, ни әйләрсең?» — дидекләрендә «Бу кадәр тавыкга бер әтәч кирәк», — димеш.

* * *

Бер көн Хуҗа бер агачка бенеб, бер ботакга утырыб, утырган ботакны кисмәкә башлар. Түбәндин бер кеше үтеб барганда әйтер: «Әй, Хуҗа, ниләрсең, имде ул ботак кискәч еглып төшәрсең», — дир Бу сүзгә Хуҗа һич җаваб бирмәз, һаман кисәр, агач киселеп йиткәч, еглыб дөшәр Андин торыб, ул кешенең артыннан йөкереб йитеб:

Сән төшәремне белдең, үләремне дә беләрсең, — диеб бунын якасына ябышыб, ул кеше, йибәрмәгәч, әйдер:

Әй, адәм, ишәккә бер агыр йок йоклап тауга каршы бар Әүәл усырдыкта җанының яртысы чыкар, икенче усырдыкта барчасы чыкар, җанын калмаз, — димеш.

Хуҗа шулай итеб икенче усырдыкта ушбән булдыгым диб калыр. Халык галәм буның башын үлчәб бер табут китереб, эченә салыб: «Өенә илтәек», — дию юлда барыр икән. Бер балчыклы йиргә йитделәр. «Бундан ничек үтәек?» — диеб сүзләшәләр икән. «Бән саг вакытда шул юлдин китәр идем», — димеш.

* * *

Бер көн Хуҗа йир астына баз казымага теләде. Казый торгач, күршеләрендән беренең абзарына чыгар. Күрер ки, үгезләр бар. Хуҗа сөенеб, өенә килеб:

— Әй, хатын, кафер заманында калган бер абзар үгез табтым. Бәңа сүенеч нә бирерсәң? — димеш.

* * *

Бер көн Хуҗа хатынына әйтер:

— Әй, хатын, үлгән кешене ничек белерсәң?

— Кулы-аягы суык булыр, шундан белермән, — дир.

Бер көн Хуҗа тауга утынга барганда кулы-аягы өшемеш. Хуҗа һаман сәгать: «Мән үлдем», — диеб бер агачның төбендә ятыр. Бүреләр килеб ишәкне ашамага башлар. Хуҗа яткан йирендин бүреләргә:

— Яхшы иясе үлгән ишәкне табуыңыз, — димеш.

* * *

Бер көн Хуҗа бер каз пешереб патшага китерер икән, юлда казны ачар, казның бер ботын кисеб ашар Хозур патшага бардыкда казны алдыга куяр. Тимерләң күрдекдә Хуҗага:

— Буны кем китерде, бунын бер аягы кайда китде? — дидекдә. Хуҗа:

— Безнең йортның казлары берәр аяклы б... лырлар, инанмаз итсәң, әйдә, чишмә башы... торган казларга бак, — димеш.

Фиәлвәкыйг чишмә башында берничә ка... бар, имеш, барчасы бер аяк берлән тора... имеш. Тимершаһ шул сәгать әмер әйдерки:

— Казларга чукмар илән ташка орыб та... итәрләр. Һаман казлар ике аяклы улыр.

Тимер:

— Күрдеңме, икешәр аяклы улдылар, — ... гәч, Хуҗа:

— Ул чукмарны сиңа орсалар, дүрт аяк... булырсәң, — димеш.

* * *

Бер көн Хуҗаның хатыны вәгазь мәҗлес... барып дыңлаб, өенә килдекдә Хуҗа әйдер

— Әй, хатын, вәгазьче нә сүзләде?

Хатын әйдер:

— Бер кемсә хәләле илә бер кичә җом... әйләсә, аңа Хак Тәгалә җәннәтдә бер са... ясар, — диде.

Болар яткан вакыт. Хуҗа әйдер:

— Тор, имде җәннәттә бер өй ясаек, — ... җәмагъ идерләр. Бер замандан соңра хат... янә әйтде:

— Әй, Хуҗа, үзең өчен өй ясадың. тиз б... бәңа да бер өй яса, — дир.

Хуҗа әйдер:

— Сәңа өй ясамак яхшы, әмма куркы... кем, анаң-атаң өчен дәхи соңра кавем-каб... ңез өчен берәр өй сорарсән. Ки... икемәкә ... өй йитәр, — димеш.

СИШӘМБЕ

ЧӘРШӘМБЕ

ПӘНҖЕШӘМБЕ

АТНАЛЫК МАНЗАРА TV

ҮШӘМБЕ

9 ОКТЯБРЬ

«ТАТАРСТАН»

) «Чулпан» информацион програм- ...40 Мультфильм. 18.45 Балалар ...мчы» 19.00 «Татарстан» 19.30 «Те- ...» Тапшырулар анонслары 19.40 ...остал» Реформалар программасы: ...булырга тиеш?. 20.20 «Әлли-бәл- ...20.30 Гашыйклар телеканалы 21.05 ...кан Милләтләр Оешмасы бүгенге ... 2 нче тапшыру 21.40 Хәйдәр Би- ...ярлый 22.05 Татарстан Республика- ...иденты кубогына футбол буенча ха- ...турнирдан репортаж (Чаллы шәһә- ...) Тапшырулар программасы.

«ЭФИР»

...рядкага басыгыз!» 7.10 Мультфильм: ...Муромец» 7.30 «КиноМеню» 8.00 ... музыка яңалыклары 8.15, 11.05 ...уле» Атналык йомгак 8.30, 14.45 ... 8.40 «Сул аяктан!» (MTV). 9.20, ...0х60х90» 9.40 Диск-канал. 10.00 ...бы» Зиновий Гердт янында кунак- ... Сериал «Один к десяти» 5 нче ...20 Атна фаразлары 11.50 «Валюта ...12.00 Нәфис фильм «Мстители» ...я 13.15 Нәфис фильм «Ребро Ада- ...0 Нәфис фильм «Франциск» (Мик- ...17.05 «Минем йолдыз» Людмила ...17.50 Теледискотека «Партия иона- ...) Документаль фильм «Кино наше- ...» 19.30 «Видеомода» 19.50 «Кы- ... матурлар» 20.20, 23.45 «Шәһәр» ...цион программасы 20.45 «Камил- ...5 Телеэкспресс 21.35 Нәфис фильм: ...» (Франция-Германия-Ка- ...10 «Криминаль хроника тележур- ...05 «Войны наркомафии» циклын- ...е фильм. «Кокаиновый картель» ...Микеле Плачидо) 1 нче серия

1 НЧЕ КАНАЛ

... 6.30, 7.00, 7.30, 8.00, 8.30 «Көн ... һава торышы» 6.05, 7.05, 8.05 ...лыклары 6.10 «Иртәнге физик күн- ...7.10 Мультфильм 7.20 «Пресс-экс- ...0 Саламәтлек мониторингы 7.50 ...й двор» 8.10 «Иртә» кунагы 8.40 ...нле» 9.00, 12.00, 15.00, 18.00, 0.00 ...ар» 9.15 Телесериал «Тропикан- ...«Могҗизалар кыры» 10.55 «Кеше ... 11.20 Мультфильм «Добро по- ... 11.30 Телеуен «Көен таны» ... - «Мир» Дәүләтара телеради- ...се тапшырулары 12.50 Сериал: ...ения Шерлока Холмса и доктора ...«Собака Баскервилей» 1 нче се- ...«Кумирлар кумирлар » София ...20 Мультсериал «Виджит спешит ...» 15.40 «Марафон 15» 16.00 «Йо- ...гате» 16.35 Яшьләр сериалы: ...бята» 17.00 «Джем» 17.30, 0.40 ... жиде көне» 18.20 Телесериал: ...» 19.10 «Ыгы-зыгылы сәгать» ... «Көен таны» 20.00 «Без» ...ын авторлык программасы 20.45 ...йокы наниләр» 21.00 «Вакыт» ...стик детектив «Багэ» «Элект- ...» (Бөекбритания) 2 нче серия. ...кадәр һәм аннан соң » В.Мол- ... бара 23.45, 0.10 Сериал «Твин

«РУСИЯ»

